Рәдиф Гаташ
**Сайланма әсәрләр**

**Өч томда**

# 1 том

**Шигырьләр, лирик цикллар,**

**шигъри хатлар**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2009

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г24

**Гаташ, Р.К.**

Сайланма әсәрләр : 3 томда / Рәдиф Гаташ ; кереш сүз авт. Х.Миңнегулов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009.
ISBN 978-5-298-01864-7
1 т. : шигырьләр, лирик цикллар, шигъри хатлар – 2009. – 239 б.
ISBN 978-5-298-01865-4

Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ әсәрләренең бу томына шагыйрьнең төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре, цикл-бәйләмнәре, лирик хатлары туплап бирелде.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01865-4 (1 т.)
ISBN 978-5-298-01864-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Гаташ Р.К., 2009

## ЗАТЛЫ ШИГЪРИЯТ ИЯСЕ

Гавамга хезмәт итү – иҗат әһеленең төп вазифасы. Аның бөтен эшчәнлеге инсанның рухани дөньясына, уй-кичерешләренә юнәлтелгән. Ике арада уртак дулкынга көйләнгән диалог, әңгәмә-сөхбәт барлыкка килә икән, бу иҗат иясе өчен олуг бәхет. Димәк, ул әдәбият һәм сәнгатьнең асыл вазифасына тугры хезмәт итә.

Рәдиф Гаташ та – әнә шундый иҗат әһелләренең берсе. Инде менә ул ярты гасыр буена шигърияткә, аның аркылы гавамга өзлексез хезмәт итә. Аның татар, урыс, башкорт телләрендә дөнья күргән ике дистәдән артык китабы бар; аерым шигырьләре инглиз, төрек, азәрбайҗан һәм кайбер башка телләргә дә тәрҗемә ителгән. Шагыйрьнең 2005 елда «Рухият» нәшриятында «Мәңгелек сусау» исемле күләмле (512 битлек!) китабы дөнья күрде. Анда авторның төрле елларда иҗат ителгән шигъри үрнәкләре тупланган. Әмма төп урынны ике гасыр аралыгында язылган шигырьләр, шул исәптән газәлләр һәм робагыйлар алып тора. Бу китапны Рәдиф Гаташ шигъриятенең таҗы, йөзек кашы дип тә атарга мөмкин. Ул шагыйрь иҗатының асылын, хосусиятләрен, кыйммәтен шактый тулы чагылдыра.

Рәдиф Гаташ – бөтен табигате, барлыгы белән шигъри зат, талант иясе. Иҗадилык аның һәр эш-гамәлендә, һәр шигъри юлында сизелеп тора. Аның бу сыйфатына күп кенә каләмдәшләре, чордашлары да игътибар иткән. Яшь шагыйрьне Язучылар берлегенә тәкъдим иткән тәүсыя-рекомендациясендә Хәсән ага Туфан болай яза: «Мин аның тумыштан талантлы икәнлегенә, димәк, Тукайлар-Такташлар-Җәлилләр васыятен дәвам иттерүчеләрнең берсе булачагына ышанам... Телебезнең әчке гүзәллекләрен, нюансларын, аның мөмкинлекләрен гаҗәп нечкә рәвештә сизә һәм шул хисләрне реаль телгә күчерә, әйтә ала Рәдиф». Хәсән Сарьян яшь әдипне «бөтен күзәнәкләре белән шагыйрь кеше» дип атый. Шунысы мөһим: яшьлегенә, тәүге иҗатына хас бу сыйфатын Рәдиф Гаташ хәзергәчә, өлкән яшенәчә саклап, үстереп килә. Моннан берничә ел элек кенә язылган бер мәкаләсендә Гәрәй Рәхим болай ди: «Аның һәр шигыре «мин – Рәдиф Гаташ шигыре» дип кычкырып тора. Шагыйрьнең үз стиле, үз язу манерасы, үз кулы бар».

Рәдиф Гаташ өчен шигърият шөгыль, профессия генә түгел, ә яшәешнең үзе, тереклегенең төп мәгънәсе. Шуңа күрә дә ул аны изгеләштерә, хәтта илаһилаштыра. Соңгы елларда дөнья күргән бер китабының исемен «Хиссият аятьләре» дип шәрехләве дә юкка гына түгел. Күп кенә әдипләрдән үзгә буларак, Р.Гаташ хикәя-бәяннар да, драма-тамашалар да язмады, гомере буе шигърияткә, аның да үз табигатенә туры килешле лирика тармагына тугры калды.

Р.Гаташ шигырьләрен уку, аеруча аларны авторның үзе башкаруында тыңлау күңелле, рәхәт. Әмма зур шигърият хакында язу, фәнни-тәнкыйди фикер йөртү шактый кыен. Чөнки аның шигырьләрендә, музыкадагы кебек, эмоциональлек, хис-кичерешләр, импульсив тойгылар өстенлек итә; гадәти логиканы еш кына бөтенләй үзгә, көтелмәгән, әмма ышандыра торган хисси мантыйк алыштыра. Мәсәлән, «Төш» шигырендәге лирик герой дустына бер төнгә күзләрен биреп тора. Бу зат исә моның сөйгәненә гашыйк була, шагыйрьгә әйләнә һәм ахыр чиктә сөйгәнен урлап качарга җыена. Шигырь түбәндәге юллар белән тәмамлана:

Мин нишләдем?! Кире алдым, ашыгып,
Дустан күзләремне.

Бер робагыенда шагыйрь үзен моннан мең еллар элек үлеп, кабат терелгән кеше кебек хис итә.

Күргәнебезчә, Р.Гаташ лирикасына романтик фикерләү хас. Реаль чынбарлык, катгый иҗтимагый, социаль мөнәсәбәтләр, яшәешнең рәсми кануннары һәм тарих шагыйрь өчен бары импульс чыганаклары, иҗат өчен чимал, материал гына. Аларның реаль рәвешен, объектив нисбәтен саклау автор өчен мәҗбүри түгел. Шагыйрь инсан табигатенең, эш-гамәленең вакыт белән чикләнмәгән асыл сыйфатларын, яшәешнең хисси-фәлсәфи якларын үзәккә куя, борынгы мифологиядәге кебек, кеше, гамәл, табигать арасындагы тыгыз бәйләнешне, гармонияне эзли һәм булдырырга омтыла. Моңа ирешүдә Р.Гаташ төп һәм хәлиткеч урынны мәхәббәткә бирә. Ул да, Низами, Котб, Хафиз, Харәзми, Кандалый, Сәгыйть Рәмиев кебек, сөю-мәхәббәтне яшәешкә хас гомуми категория, тереклекне хәрәкәтләндерүче көч, рухи камиллекнең һәм комфортның мөһим сыйфаты рәвешендә карый. Шагыйрь, әлбәттә, ир-ат буларак, иң беренче чиратта хатын-кызны зурлый, аның гүзәллеген, яшәешкә ямь һәм мәгънә бирүен данлый. Шуның белән бергә ул хатын-кызларны тасвирлау аша, гомумән, тереклекне, инсанилыкны олылый, яшәешнең мәңгелеген ассызыклый. Шагыйрьнең туган җирне, ата-ананы, сөекле халкын, газиз телен, бөек затларны олы мәхәббәт хисләре белән турыдан-туры тасвирлаган шигырьләре дә бар. Аның уенча, «мәңгелеккә сусау» ул – иң беренче чиратта сөю-мәхәббәткә, аның аркылы тулы канлы яшәешкә, иҗатка сусау дигән сүз.

Рәдиф Гаташ – ярты гасырлык иҗатында кешеләр күңелендәге күп кенә хис-тойгыларны табып, кичереп, аларга исем, лөгати яңгыраш биреп, үз укучыларын сөендергән зат. Роберт Миңнуллин сүзләре белән әйткәндә, «аның шигырьләре һәркемгә кадерле хисләр белән сугарылган».

Р.Гаташ иҗаты – затлы шигъриятнең матур бер үрнәге. Затлылык, татарга хас әдәплелек аның тел-стилендә дә, шәкли корылышында да, мәгънәви эчтәлегендә дә ачык күренеп тора. Шагыйрьнең сүз-сурәтләре ничектер күңелгә ятышлы, рухи ихтыяҗларга авазгаш.

Иҗат иясе өчен иң беренче чиратта табигый сәләт кирәк. Әмма ул гына җитми. Талант тиешенчә ачылсын, үссен өчен, үзеңә кадәрге рухи казанышларны белү, зиһенгә сеңдерү, иҗади үзләштерү зарури. Бу яктан да Р.Гаташ кабатланмас шәхес. Ул татар, башкорт сүз сәнгатен, урыс һәм дөнья классикасын бик яхшы белә. Аның сәгатьләр буе Тукай, Бабич, Такташ шигырьләрен яттан сөйләвен күпләр хәтерлидер. Кирәк булса, ул Хафиз, Байрон, Пушкин, Һейне әсәрләрен дә хәтердән укып җибәрә. Аның эрудициясе, профессиональ әзерлеге шигырьләреннән дә ачык күренә.

Ярты гасырга сузылган иҗатында Р.Гаташ татар шигъриятенең эчке мөмкинлекләрен арттыруга, жанр хәзинәсен баетуга да үзеннән зур өлеш кертте. Ул, бер яктан, татар сүз сәнгатендәге казанышларны, аеруча Тукай традицияләрен уңышлы дәвам иттерде, үстерде, икенче яктан, башка халыкларның эстетик тәҗрибәсен иҗади үзләштерде... Аның бигрәк тә шигырьнең ритмикасы, строфа төзелеше өлкәсендәге эзләнүләре кызыклы булды. Чордашы Равил Фәйзуллин белән бергә Р.Гаташ та ирекле шигырьнең матур гына үрнәкләрен тудырды. Аларның чорга авазгаш интонацион яңгырашны эзләү тәҗрибәсе кайбер башка шагыйрьләр, бигрәк тә яшь авторлар тарафыннан уңышлы файдаланылды. Ике гасыр аралыгында Р.Гаташ иҗади эзләнүләрен тагын да көчәйтте, элеккеге мирас белән кызыксынуын бермә-бер арттырды. Шуның нәтиҗәсе буларак матур-матур газәлләр, робагыйлар иҗат ителде, гаруз системасын торгызу юнәлешендә дә нәтиҗәле адымнар ясалды.

Кыскасы, Р.Гаташ – соңгы дәвер татар сүз сәнгатен үстерүгә, баетуга, шигъри дәвамчанлыкны тәэмин итүгә зур өлеш керткән шагыйрь. Аның иҗатыннан башка хәзерге татар поэзиясен күз алдына да китереп булмый. Шагыйрьнең романтик рухлы лирик шигырьләре укучылар тарафыннан укыла, мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнелә, радио-телевидениедән, сәхнәләрдән еш яңгырый. Аның сүзләренә Сара Садыйкова, Фасил Әхмәтов, Резеда Ахиярова, Марс Макаров һ.б. композиторлар язган җырлар да яратып тыңлана.

Рәдиф Гаташ – шагыйрь буларак шактый бәхетле зат. Аның иҗаты хакында Х.Туфан, С.Хәким, Ф.Хөсни, Н.Арсланов, Н.Нәҗми, И.Юзеев, Ә.Баянов, Р.Батулла, Зөлфәт, Р.Миңнуллин һәм башка күренекле әдипләрнең җылы сүзләре бар. «Рәдиф Гаташның сусаган күзләре тирә-юньнән гел матурлык эзли...» «Ул чын татар шагыйре. Шуның белән ул безгә кадерле дә», – дип яза Ркаил Зәйдулла «Мәңгелек сусау» китабына язган кереш сүзендә. Р.Гаташ иҗатын Й.Нигъмәтуллина, Р.Ганиева, Т.Галиуллин, Р.Мостафин, Р.Сибат, И.Вәлиулла кебек әдәбиятчылар да югары бәяли. Инде 1988 елда ук күренекле галим-тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин Р.Гаташның чирек гасырдан артык «татар поэзия-сендә намус белән хезмәт итүе», «татар поэзиясенең рыцарьларыннан берсе» булуы хакында язган иде. Шагыйрь иҗаты хакында курс һәм диплом эшләре, диссертацияләр язылуы да мәгълүм.

Рәдиф Гаташ – чын мәгънәсендә остаз да. Инде арабыздан киткән Зөлфәт, Наис Гамбәр, Рафаэль Сибат аны, яратып, һәрчак «хәлфәм» дип кенә йөрттеләр. Роберт Миңнуллин, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла һәм бүгенге көннең кайбер башка күренекле шагыйрьләре дә Р.Гаташка ихтирами мөнәсәбәттә. Америкада гомер кичерүче Нурия Измайлова, Төркиядә яшәүче Чулпан Зариф та аны үзләренең остазлары дип саныйлар.

Шагыйрь укучылар, мөгаллимнәр, студентлар белән даими очрашып тора, яшь иҗат көчләрен барлауда, үстерүдә фидакарьләрчә хезмәт итә. Башлап язучыларга ул һәрчак игътибарлы, ярдәмчел: әсәрләрен укый, киңәшләрен бирә, матбугатка тәкъдим итә, кереш сүзләр яза. Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллина, Гөлнур Корбанова, Эльвира Һадиева, Резидә Гобәева һәм башка бик күп яшь шагыйрьләр – болар бар да Рәдиф Гаташ шәкертләре. Р.Гаташ гомумән хәзерге әдәбият белән ныклап танышып бара. Уңышларга балаларча сөенә, кимчелекләргә борчыла. Матбугатта, төрле утырыш-җыелышларда еш кына ялкынланып чыгышлар ясый. Тукайның туган көненә багышлап уздырыла торган традицион шигъри митингларны Рәдиф Гаташтан да оста алып баручы, мөгаен, башка юктыр.

«Казан утлары» – соңгы дәвер татар әдәбиятының көзгесе, әйдәп һәм оештырып баручы мәркәзләрнең берсе. Аның шундый булуында журнал редакциясендә поэзия бүлеген 30 елдан артык җитәкләгән Рәдиф Гаташның да роле зур.

Узган гасырның 60 нчы елларында Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Г.Рәхим, Р.Мингалимовлар белән бергә олы әдәбиятка

аяк баскан Рәдиф Гаташ (ул вакытта әле Гатауллин) үзенең бай иҗаты, нәтиҗәле мәдәни эшчәнлеге белән халкыбызның, Татарстанның рухи алгарышына, әдәбиятыбызның үсешенә, гавамны әхлакый-эстетик яктан тәрбияләүгә зур өлеш кертте. Бүләкләр артыннан кумаган бу талантлы шагыйрьне Һади Такташ, Фатих Кәрим исемендәге дәрәҗәле премияләр үзләре эзләп тапты. 2008 елда ул «Газәлләр» һәм «Мәңгелек сусау» китаплары өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Болар барысы да Рәдиф Гаташның нәтиҗәле иҗади эшчәнлеген, олуг шагыйрь булуын янә бер мәртәбә раслап тора.

*Хатыйп Миңнегулов,*
*филология фәннәре докторы*
*2009*

# *I. Гөлләр су сорый*

### *(1961–1965)*

### ҖИЛКӘН

Җилкәннәрне ефәк җил күтәрде,
Тын ярларны инде калдырам...
Авыр миңа, гүя гомерлеккә
Туган җирдән бүген аерылам.

Тиргәмәгез мине, сөйгән дуслар,
Тиргәмәгез ерак киткәнгә.
Сезгә, бәлки, утрау күбрәк ошый,
Диңгез кирәк ләкин җилкәнгә.

Җилкәннәрне тагын җил күтәрде, –
Җилгә җиңел... Ә соң күңелгә?!
...Бик еракта инде тын яр булып
Малай чагым минем күмелә.

Диңгезләргә илтә хәзер юлым,
Мин күрмәгән ерак җирләргә.
Ярдан һаман ерагайган саен,
Җиңелрәк икән җилкәнгә!

### КЕШЕ – ГАШЫЙК

Җир кешене һәрчак ашыктырган
Гасыр, еллар буе.
Ашыгып сөя кеше, аннан ашыгып
Уза, диләр, туе.

Мин дә ашыгам алга, елларыма,
Йөрәк ачып менә.
Ашыктыра кояш, йолдыз мине,
Җилләр ашыктыра.

Йә суыта дөнья, йә тирләтә,
Яки ачыктыра.
Кузгалырга, алга юл алырга
Форсат ачып тора.

Нинди бәхет! Һәрбер көне белән
Дөнья ашыктыра.
...Яши ала шулай ашыгып җирдә
Бары гашыйк кына.

### ТӨНГЕ РОМАНТИКА

Тәрәзәмне ачкан төнге җилләр,
Әллә үзем өйдә юктамы?!
Йөрәгемә минем тынгы бирми –
Давылмы ул, романтикамы?!

...Һаваларда ак болытлар ага,
Чакыра күк мине юлларга;
Шул болытка тотынып күккә менсәм,
Карар идем төнге дөньяга.

А, юк!
Болытларга карап көнләшмимен,
Көнләшмимен алар биек дип...
Йөрәк, болытлардан биегрәк –
Югарыга меник?! Меник, дим...

Балкып янган күкнең йолдызлары
Җем-җем итә, безне күзлиме?!
Әллә җирне матуррак диме?
Якыная җиргә – түзмиме?!

Юллар!
Алар каян гына үтми,
Үтә җирдән, үтә күк аша.
Ләкин бүген, ахры, юллар башы
Йөрәгемә минем тоташа.

Давылларда – йөрәк. Ә урамда
Кемдер әллә эше юккамы
Кычкыра күк янар бу яшьлеккә
Ят нәрсә дип... романтиканы.

Ә йөрәгем әйтә күк аңа:
– Бөтен төн дөньясын үзеңә бирәм,
Тик кагылма романтикама!

**ДИҢГЕЗГӘ**

Мин диңгездә, дуслар, тумадым.
Озын, йомшак чәчләремне минем
диңгез дулкыннары юмады.
Урал итәгендә туганмын.
Карагайлы Урал урманы,
Агыйделнең көмеш сулары
кочагында мине үстерде;
мин диңгездә әле булмадым.

Яшьлек ярсуында яна-яна
шашып хыял йөргән чакларда,
бик китәсем килә ярларында
кипарислар үскән якларга.
Каршыласым килә нуры белән
диңгезләргә иңгән таңнарны.
Бик күрәсем килә кояш белән
мәңге туган булган ярларны...

Матурлыгы әллә тиңсезгә,
бик барасым килә диңгезгә!

...Бөдрә чәчле бөек Пушкин анда
хисләр тапкан олы йөрәгенә,

басып торган озак ярында.
Ул бит көчле көрәш давын тойган,
диңгез шавын күргәч алдында.

Әллә инде гомере тиңсезгә –
бик охшыйсым килә диңгезгә!

* * *

Яз! –
Каеннарның ямь-яшел
Күлмәген кигән чагы;
Диңгездәй хиснең күңелдә
Тулышып килгән чагы.

Яз! –
Болыннарның чәчәктән
Алъяпкыч япкан чагы;
Яшь күңел кыясын сөю
Дулкыны каккан чагы.

Яз! –
Табигатьнең эшкә дип
Изүен чишкән чагы;
Күңелдә җыр җимешенең
Балланып пешкән чагы.

## СТУДЕНТ ХАТЫ

– Җавабың кая, Кыз бала?
Йөрәкнең янган чагы.
Сөюемне дә беләсең,
ни әйтим сиңа тагы?
Төн кебек кара чәчләрне
башкалар сөйсенмени?
Башкалар сөйсен, студент
янсын да көйсенмени?
Тыңламый каләм, «дәрес»ем
язылмый бүген, кала –
уйларым сине эзли тик,
Кыз бала, күзең кара!
Янганын хисле йөрәкнең
студент сөйли сиңа.
Карашың читкә алганны
студент сизми димә.
Табылган бит: борынгыдан:
«Студент – ярлы», – диләр.
«Мөлкәте – иске чемодан,
анысы да бармы?» – диләр.
Ташыган хисләргә бай мин,
күрмиләр – хыялга бай.
Бар дөнья – минем байлыгым,
киләчәк... барсы минеке! –
белмисең син дә, малай...

Таңнардан таңнарга кадәр
күрмәгәч, көтеп үзен,
студент хат язды янып,

сагынып кара күзен:
– Җавабың кая, Кыз бала?
Йөрәкнең янган чагы.
Сөюемне дә беләсең...
Үрелеп йолдыз тотыйммы?
Ни кирәк сиңа тагы?!
* * *

Таллы алан. Чыклы үлән...
Көмеш бит ул, чыкмыни?
Чыланам дип чыкмый калма,
Чыктан куркыр чакмыни?

Йолдызлар җемелди күктә,
Тиздән сүнәрләр инде;
Алар безне күрде бугай,
Айга сөйләрләр инде.

Сандугач сайрый якында –
Кайчан уянган икән?!
Бөтен нәрсә матур монда –
Бергә булганга микән?

Чыкка чыланамын, дисең,
Көмеш бит ул, чыкмыни?!
Иртәгә дә чык аланга,
Чыктан куркыр чакмыни?!

**КАЙТУ**

*(Юл эскизлары)*

Эх, юллары да юллары! –
Кышкы юл көзге кебек,
Аксакал кышның энҗедән
Калдырган эзе кебек.
Җәелгән ерак-еракка
Юрганнан сырган дала.
Юл ерак. Әй, ярсый йөрәк! –
Җилдереп бара чана!

Кышкы юл! Юырта кашкам
Тын гына, талгын гына.
Яндырып ала битеңне,
Җиле дә салкын гына.
...Җил җырын җырлый далага,
Җырлый да тагын тына.

* * *

Алдымда минем дала да
Юллар да юллар гына;
Юлдашым кашка атым да
Җилләр дә җилләр генә...
Җемелдәп янган йолдызга,
Далада искән җилгә
Онытылмас әкият итеп
Сөйлисем минем килә
Күңелдә булган уйларны,

Җылы хисләргә урап.
Тыңласын дала, тыңласын! –
Юл ерак, ярсый йөрәк.
Сөйлисем бүген килә...

* * *

Әй, юлым! Ак кар өстеннән
Ак тасма булып үтә.
Ак тасма кебек юл мине
Авылыма бүген илтә.
Әй, юлым! Энҗе бөртекләр
Тезелешеп ялт-йолт итә.
Энҗедәй яшьле күз белән
Авылымда әнкәй көтә.

Әй, юлым! Кар да җил генә.
Юл ерак, ерак үтә.
Күңел юлына кар яумый!
Кар кебек ап-ак пәрдәсен
Күтәреп иркәм көтә.

* * *

Юллар белән, җырлар белән
Елмаеп еллар үтә...
(Үткәнгә карамый юллар,
Юл киләчәккә илтә.)
Тын гына яткан далада
Тын гына ага юллар...
Әй күңел, талпына күңел!
Үткәнгә кайтмаса юллар,
Үткәнгә кайтыр уйлар.
Зәңгәр урман, күк болыннар...
Хуш исле яшел печән,
Җитен чәчле чая малай
Шуларда аунап үскән.
Яз көне ап-ак чәчәктән
Шомыртны күмә болыт.
Малайда сипкелләр арта
Яз саен бизәк булып.
Менәргә әзер айга ул,
Бүген үк китәр иде.
Куш кына, бөтен дөньяны
Җәяүләп үтәр иде!
...Зәңгәр диңгез ясап күлдән,
Ташлардан салдым сарай...
Әй, дуслар, мин бит әле дә
Күкләргә ярсып ашкынган
Бер җитен чәчле малай!

* * *

Малайчак! Басканың – туфрак,
Сөйгәнең кояш була.
Энҗеле уйлар тезгене

Күңеленә юлдаш була.
Малайчак! Хыял атында
Куганың җилләр була.
Гел теләми малайчак, ул
Ансыз да чибәр була.
Малайчак! Көн-төн өеңдә
Яңгырар тавышың була.
Тавышың басылмый, басучы
Әткәң каешы була.

* * *

Өч туган без, өч бүз бала,
Өч малай үскән идек.
Киткәндә туган җирдән, без
Шулай дип киткән идек:
– Чакыра ерак-еракка
Яшьлекнең ярсу җыры.
Туган җир, синнән китәбез,
Аерыла гомер юлы.
Чәчкән-урган, иген иккән,
Бабайлар тирен түккән,
Туган җир, синдә үскән ир
Азамат атлы икән.
Әтиләр калдырган юл бар,
Билбаулар билдәдер бит?
Азамат ирнең гомере,
Көч-куәте, йөрәк дәрте
Туган җир, илгәдер бит?!

* * *

Өч туган без, өч бүз бала... –
Өч егет үскән идек.
Киткәндә туган җирдән без
Шулай дип киткән идек.
– Әй, яшьлек! Юлыңа җәймә –
Әнкәмнән теләк – дога.
Төрлесе төрле якларга
Туганнар юлга чыга.
Озату маңгайдан үбеп –
Борынгы һәйбәт йола.
Яулыгы яшькә чылана –
Озата әнкәй юлга.
Әнкәем, яшькә чылана
Яулыгың, шуның өчен
Бөтен нәрсәдән дә кыйммәт,
Кадерле миңа яшеңә
Чыланган яулык очың!

* * *

Чаж да чож! Чана табаны
Җыр белән карны кисә.
Әй дала җиле күңелле!
Озатып мине исә.
Ай үзе дала юлында –

Ашыгып аккан чана,
Болытлар күктә ашыгып,
Акчарлаклардай тезелеп
Чананы узып чаба.
Дала да дала, җил дә җил!
Юлмы бу, әллә җырмы?!
Әй, студент кайта бүген –
Авылына кайта туры.
Тын гына яткан далада
Ашкынып туа уйлар.
Даладан аккан чанадай
Тып-тын гына бармас әле
Яшьлектә үтәр юллар!

* * *

– Якты ай! Нурыңа коенып,
Җырларым көмеш булсын.
Ак булсын, сафтан коелсын,
Яктыңнан өлеш булсын!
Дәшми ай. Нигә бер генә
Моң белән күңеле тулсын!
Алдымда минем дала да
Юллар да юллар гына.
Юлдашым – кашка атым да
Җилләр дә җилләр генә.
Яшьлегем канат каккан чак,
Юлларның нинди киңе!
Бөтен дөнья киңлегенә
Тиңләшә күңел көне.
Сызгырып кына чикләнмәс,
Сыздырып җырлар чагың,
Әй, йөрәк, ашкын әле бер,
Әй, яшьлек, талпын тагын!

* * *

Чәчелгән дә күк йөзенә,
Җем-җем йолдызлар яна.
Эзләнгән күңел, тукталып,
Карый да күккә таба,
Әйтә гүя:
– Йолдызым, мин
Табармын барыбер сине.
Эзлимен. Сине табуым –
Яндырган хыял җиле.
Бүгенге минем кышкы юл
Авылыма гына илтә.
Ә гомер юлы еракка,
Еракка һаман китә.
Мин барам... җыр белән барам
Кыен бәхеткә таба.
Ул бәхет – дөнья бәхете,
Хәтерләтеп миңа шуны,
Күңелемдә йолдыз яна.

* * *

– Йөрәк!
Үзең, «Җир» дип, һәрбер тибүеңдә
Бар дөньяга аваз саласың.
Ләкин нигә күккә омтыласың?
Җирне сөйгәч,
Читләшәсең нигә аннан син?

– Мин – бер матдә. Үсеш юлларымның
Күктән эзлим дәвам-ахырын...
Мин үземне кеше иткән көчне
Җирдә таптым, җирдә таныдым.
Җиргә сөю белән,
Һәр рөхсәте белән аның
Башлыйм
Ай, Кояшка илтер адымым!

## ШАГЫЙРЬ ЯЗМЫШЫ

*(Хәсән Туфанга ода-реквием)*

Ашыга-ашыга акты болытлар... –
Бәлагәме алар юлыккан?
Җил тарады дулкын чәчләрен,
Хәбәр булып яшен яшьнәде,
Һәм, Иделгә коеп яшьләрен,
Ашыга-ашыга акты болытлар.

Дулкыннарда чайкала көймә,
Һәм көймәдә ниндидер көйгә
Җырлап бара ишкәкче егет.
Җыры кайчак ямансу кебек,
Ә кайчакта җилдәй җилкенә...
Дулкыннарны яра җыр, көймә:

– Кая илтә мине язмышым?
Сизенә җан, анда – сагышым,
Идел-йорттан аерып, илемнән,
Аерып мине «нәзкәй билем»нән
Кая чакырасың, язмышым?
Ил гамеме җанны җилкетә,
Язмыш, ни син? Мине ни көтә?

Әйе, язмыш ни соң? Кем әйтә?
Күктән иңгән ул бер тавышмы?
Овидийны сөргән Августның
Ихтыярымы – ир язмышы?
Лирасыннан Пушкин шагыйрьнең
Тетрәп җаны, Александрның
Көньякларга аны кууы
Язмыш исеменнән булдымы?
Юк, ул заман хаким хөкеме
Шагыйрьләргә язмыш китерде!
Нигә Юнан ләкин, Рум миңа?
Минем яңа, гадел Ватаным
Шагыйрем дип ләса атады...
Кайда барсам, кайда йөзсәм дә,
Беләм: илгә кабат кайтамын,
Дулкыныңда, илем, батмамын.

Нигә Юнан, нигә Рум миңа?

...Кайттылар ла, тарих, кайттылар
Вөҗданы пакь, зурга хаклылар.
Исән кайтты исән булганнар
Һәм терелеп кайтты үлгәннәр –
Пакь исемнәр безгә кайттылар.
Без кайтырбыз, йөрәк, якында.
Көтеп, сагынып каршы алырлар,
Бәлки, яшьләр җыр да язарлар:

– Кара чәчләренә кар яуган,
Кай арада шулай агарган?
Бәлки, сафлык төсе аларда,
Хаклык төсе – синең карларда.
Ә йөрәгең, күр, гел яшәрә...
Сабак ла бу безгә – яшьләргә.
Синең кебек язсын яшәргә!
Чал чәчле, яшь җанлы өлкән син,
Бөек ир һәм шагыйрь икәнсең!

...Дулкыннарда чайкала көймә,
Көймә?.. Бәлки, гомер корабы?
Язмышка гел кыю карадың,
Бик еракка кораб барадыр,
Инде күздән югалды көймәң –
Ак җилкәнле гомер корабың.

Кара җилкән анда күрмәдек,
Шатлык төсе һаман эзләдек.
Шатлыгың бит – илең шатлыгы.
Була алгач халкың хаклыгы,
Керләнмәде җилкән аклыгы!

...Җырым ода итеп башладым,
Реквиемың итеп язамын.
Елга кичкән, диңгезләр күргән –
Океанда, бәлки, корабың...
Бөек остаз үткән эзләрдән
Гомер юлын уйлап барамын –
Киләчәккә карап барамын.
Киерегез, җилләр, җилкәнне, –
Минем дә бит юлда корабым!

* * *

Матурлыкны, үзенә тарту көчен
аңа җире үзе бирдеме?
Гомере кешеләргә шатлык иде,
рәнҗетмәде яшәп беркемне.

Үлде. Җеназага килде меңнәр
(үзе белмәгәндер, ахрысы):
шушы булды аның кешеләргә
беренче һәм соңгы кайгысы.

* * *

Урамыннан күпме үткәнем бар,
юк, күренми иркәм көндезен.
Кичен генә чыга, йолдыз кебек, –
кичен генә яна йолдызым!

Йолдыз кебек... Кем белә бит, бәлки,
йолдызларга ул бертугандыр.
Һәм йолдызлар үзләре дә кичен
    сеңелләрен
күрү өчен чыга торгандыр?!

* * *

– Яннарына барма, күрмә, – диләр.
Ә барасы килә, бик килә.
– Янарсың бит, утка кермә, – диләр.
Ә янасы килә. Ник килә?!

Адаштырган утлар булуы бар,
Әй ашкына кая бу йөрәк?!
...Ә йөрәккә барыбер кирәк бугай
Тыелып үзенә тарткан бер теләк.

* * *

Кайчак артык эзләгәнгә бугай
Эзләгәнне тапмый калабыз;
Кайчак аз эзлибез, киресенчә,
Аз эзләп тә, җиңел табабыз.

Кайчак, эзләүләрдән күңел аргач,
Янар хисләр тәмам онытылгач,
Сөю килә, диләр.
Кирәкме ул
Кырау төшкәч, чәчәк коелгач?
Бәхет хисе, сүнеп, онытылгач!

* * *

Үткәннәр белән араны өзәргә! –
Мин сүз бирдем киләчәк көннәргә:
Уйламаска балачакны –
Бәхет белән генә истә калган чакны,
Сагынмаска иң беренче шатлыкларны, –
Иң беренче сөйгән ярны.
Күз алдына китермәскә шул чактагы
Иртә килгән һәм соң киткән язны, җәйне,
Яланаяклы кара бер малайны...

Үткәннәр белән араны өзәргә! –
Мин, ант итеп, имза куйдым
Күңелемдәге ак дәфтәргә.
Ләкин язган чакта аңа нидер тамды,
Таплады да
Имза урынын каплап алды.

Вакыт һәм бетергеч табып,
Бетерәсе бар тап-караны.
Өзәм, сүзсез өзәм аннан
Үткәннәр белән араны!

## ҖИДЕ ТӨН

*(Гарәп мотивлары)*

### Кереш

Мең дә бер кичәне исән
Кичалган Шәһрезадә!
Мин сиңа килдем: сөюдән
Бармы, әйт, берәр чара?
Акылыңа, гүзәллегеңә
Ихтирам саклыйм чиксез:
Күзеңдә – гасырлар сере,
Күңелеңдә – дәрья, диңгез!
Чорлар аша да, очрашып,
Сөйләшү мөмкин, беләм,
Күңелем, тыңла, уянган,
Тулган мең сорау белән!

Мин дә мәхәббәт көченнән
Тетрәнгән бер бүз бала,
Сиңа дәшәм, Шәһрезадә:
Бармы ул мәңгелек көчтән
Коткарыр бер-бер чара?
Җавап бир, Шәһрезадә!

### Беренче төн

Әй, беренче кабат күрү!
Сине очраткан бер төн
Ачты каршымда дөньяның
Тылсымлы, сихри битен.

Төн кара, бик якын ара –
Янымда буй кыз бара:
Болыттай кара чәчләрең,
Күмердәй күзләр кара.
Адаштырды карашың күп
Гасырга әллә мине?
Мин, янып: «Мәҗнүн мин», – дидем,
Син, көлеп: «Ләйлә!» – дидең.

Төн кара... Төн аша һаман
Күмердәй күзләр бага.
Кем әйталыр: якынмы ул,
Еракмы ике ара?
...Янымда Бәхет бара.

### Икенче төн

Тезелде сүзләр кәгазьгә...
Тама да кибә карам...
Җирдә ничәнче ул, буй кыз,
Калдырган бәхет-ярaң?

Кем синең серне ачалган?
Болытмы син йә җилме?
Кагылдың, киттең. Мин калдым,
Тетрәнеп калдым, тиле!

Кем сиңа үпкәли алыр?
Йә ачу саклар сиңа?
Яратылгансың – һәр йөрәк
«Гаебең»не акласынга!

Минме соң беренче гашыйк?
Соңгымы җанда ярам?
Бәлки, яңа шагыйрең мин?
Тагын исмең кабатлана –
Исмеңне пакьли карам!

**Өченче төн**

Зур рәхмәт тапкан анама! –
Мин талант, көчле талант...
Әй, горур гүзәл, син мине
Ярат тик, мәңге ярат!

Тик уйлама: минем көчем
Җыр, иҗат түгел, бүтән...
Мин – гашыйк. Кешеләргә мин,
Кояштай, сөю йөртәм...

Мин сиңа карыйм... Син горур
Илаһи көчләр белән.
Ә мин бүтән... Мин янып һәм
Яндырып сөя беләм.

Сөю илтәм сиңа! Шуңа
Мин – талант, көчле талант...
Әй, горур гүзәл!
Шагыйрьне
Шул талант өчен ярат!

**Дүртенче төн**

Бер йөрәк бу... Күпме яну!
Эзләргә эз ялгана.
...Мин яраттым. Ярат син дә,
Тик уйнама, алдама.

Бу минем дөрләп януым,
Шуңа җан шәрран яра;
Ышан син дә – күзләр аша
Җаныма сынап кара!
Син миңа гүя диңгезче
Табынган диңгез кебек,
Ял алырга дулкынында:
Карашың – чиксез өмет...

Мин исә – дулкын, җил дусы –

Табигать кошы кебек,
Яшьлегем белән хушлашам,
Диңгезгә, эчкә кереп.

Бер йөрәк бу! Күпме яну:
Эзләр тагын ялгана.
Сиңа бу җыр! Мин яраттым,
Син дә сөй. Сөй, алдама!

**Бишенче төн**

Арабызда ничәнче төн!
Гүя бер гасыр ара...
Кара чәчләргә кар төште...
Юк, кара төн агара:

Урамда, күр, карлар ява,
Кар күмә җирнең өстен...
Кайда сез, гөлләр, үләннәр? –
Буранлый бишенче төн.

Язга ерак, ерак... Ник мин
Яз көтәм, Кояш көтәм?
Очрашу вәгъдә ит, миңа
Җылы кирәкми бүтән.

Шундый ак, якты төннәрем! –
Төннәр кардан агара.
Ә хисләрем яшь, саф, кайнар, –
Тагын якты бир аларга! –
Сине уйлап яңара!
**Алтынчы төн**

Сүзләрем яңа түгелдер,
Яңартсын сөйгән йөрәк...
Сүз нәрсә ул? Ирдәй горур
Яшәргә мине өйрәт!

Бардыр ул мәхәббәт өчен
Сүздә утларга кергән,
Һәм бар – чын сөюдән, сүзсез! –
Үлемнең үзен җиңгән!

Һәм беркөн җирдә бәхеттән,
Мәҗнүндәй, өмет кискәч,
Үлем теләгәннәр бардыр,
Шатлык кизләве кипкәч.

Мондый уй нигә? Бу язмыш
Кешегә нигә, йөрәк?
Әй, җиһан! Сөюгә лаек
Горур яшәргә өйрәт!
Мәңге яшәүгә өйрәт!

**Җиденче төн**

Син – айның җиденче киче,
Күзләрең – төннең төсе;
Җиденче кич сине уйлыйм,
Бу җырым – җиденчесе.

Син җиде диңгез артында,
Мин – сине сөйгән егет,
Эзлим сиңа илткән юлны,
Җитмеш җәһәннәм чигеп.
Син – җиденче, кече матур,
Мин дә иң кече – йортта.
Сине сөйгәнгә сихерче
Яндыра мине утта...

Әй, нигә әкият?! Чынлык син,
Күзләрең – төннең төсе;
Ничәнче көн сине уйлыйм!
Бу җырлар синең өчен! –
Сиңа бара җиденчесе!
Күңелдә – ничәнчесе?..

## ПЕЧӘН ӨСТЕ

Аюдай болытлар өстә,
Сүрелеп бара эссе.
Кибәннәр үсә аланда...
(Күңелле печән өсте!)

Яшь кызый кибән башында,
Егеткә күз дә салмый:
Мул итеп алып бирсә дә,
Печәнен аның алмый.

Әй, кызый! Әллә нишләгән,
Гел күккә очынып бара.
Әйтәләр:
– Инде тотынгач,
Кояшка тотынып кара!
...Ә кояш баеп бара!

## БАШАК

Яшел кырда үскән бер башак мин.
Кыр белмидер һәрбер башагын;
Ләкин һәрбер башак кырын белә,
Белә үзенең кайда яшәвен.

Мин – бер башак... Миндә кырның төсе.
Күңел йөртә аның киңлеген;
мин кечкенә, ләкин бәхетем – чиксез,
иркен кырларыма тиң минем.

...Мин – бер башак... ә башакта җырлар,
Орлык кебек җиткән, тулышкан...
Җырлар!
Сезгә сут булсын дип, башак кебек,
Үсеп чыктым җирдән, тормыштан!

## МИН ДӨРЕСЕН СӨЙЛИМ

Мин дөресен сөйлим:
Җирдә күп кешенең ялгышларын күрәм,

Үземнекен белмим.
Ялгышымны күрсәтүчеләргә
Озын гомер телим.

Мин бер матур кызны беләм,
Яшерен сөеп йөрим.
Кара күзе өчен сөям,
Курнос борынын сөймим.

Җирдә күп кешене сөям,
Һәм шулай ук
Мин күпләрне сөймим.
Ләкин дөресен сөйлим:
Мин берәүне –
          мине сөймәгәнгә сөям
Һәм берәүне –
          сөйгән өчен сөймим.

Йолдызларның төнлә януын беләм.
Алар күпме? – Белмим.
Ләкин шул ук йолдызларның
Миннән соңгы гашыйкларга
Калуларын телим.

Мин үземнең ничек тууымны
Хәтерләмим, белмим.
Ләкин беркөн үләсемне беләм,
Мин үлемне сөймим.
Тик үземә җиңел тормыш түгел,
Җиңел үлем телим.
Мин дөресен сөйлим!

## ӘТКӘЙГӘ ХАТ

Әткәй мине бик бай кеше иткән:
Бар дөньяны миңа калдырган;
Якты булсын өчен юлларымда,
Баш очымда кояш яндырган.

– Сакла, – дигән, – җирнең матурлыгын
Һәм матурлык өстә үзеңнән!
Үзеңчә бар алга һәм шулай ук
Өлкәннәрнең чыкма сүзеннән.
Газиз булсын сиңа туган туфрак,
Хәтта аның кара ташы да;
Ташларны бит үзең шомартырсың,
Эш коралым сиңа тапшырам...

Әткәй! Эшегезне дәвам итеп,
Бүген
Елмаябыз килер таңнарга;
Юлда туктап, сагынып искә алу –
Һәйкәл булсын сезнең җаннарга.

Еллар үтәр.
Яңа уллар басар
Заманның алгы постына.
Ышан: исән килеш
Тапшырырбыз Җирне алар кулына!
Һәм мин

Калдырырмын синнән алган урыным
Каны белән синең нәселең – улыма,
Мине дәвам итәр дустыма!

## МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Урманда кыргый алмагач
Ялгызы үсте.
Язын чәчәк койды, көзен
Алмасы пеште.
Яратып ачы алмасын,
Аның янына
Килеп йөрде бер малай, кыз –
Якын авылдан.
Җыр суздылар алма өзгән,
Бүлгән чагында...
Үсеп җиткәч, аерылдылар –
Чор юлларында.
Яңгырый җырлары Ватанның
Төрле ягында...
Кыз беркөнне туган җирен
Төшендә күрде.
Гүя ул иң газиз моңын
Югалткан иде...
Гафу сорап, алмагачы
Янына килде:
Искә төште якын көйләр! –
Шатланды, көлде...
...Шушы ук төш шул ук төндә
Егеткә керде!

## ТӨШ ҺӘМ ӨН

Кайчандыр син үтә салкын идең,
Өрдең салкыныңны...
Сүндерден дә куйдың минем дөрләп
Янган ялкынымны...

Һәм ни гаҗәп! Сүнүемне күргәч,
Яна башладың син.
Ләкин кабат мин кабынгач кына,
Тагын ташладың син.
Мин ант иттем, янмам гомергә, дип...
Ул чак инде ерак.

...Бүген нигә килдең миңа төштә
Киңәш сорап, елап?

Сүзең бүлмәдем, тик тыңлап сүзсез
Мин юаттым сине.
Һәм ни әйтим?
Чынлык катгый сүзен
Күптән әйткән иде...

...Уяныргa кушып, әтәчләр дә
Таңны яра инде!

* * *

Кичәге көн үтеп киткән инде,
Син сизми дә аны калгансың.
Танышкан да синең йөрәк белән,
Китеп барган.
Бүген яңасын
Каршылыйсың көннең. Ул да шулай
Вакытлыча сердәш була да,
Алдакчы дус кебек, хисең урлап,
Әллә кая качып югала.

Нәрсә дисең мең кат авызы пешеп,
Һаман
Өреп капмый торган юләргә?!
Без шуңа да кеше! Ышанабыз
Яңасына:
Дуска,
Мәхәббәткә,
Көннәргә!
Кичәге көн үтеп киткән инде...

* * *

Без – кешеләр,
Туры килә икән,
Шатланабыз,
Шашып көләбез.
Кайгы килгән чакта
Кайгырабыз,
Яшьне түгеп елый беләбез.

Тик язмасын миңа беркайчан да –
Өлешемә тигән көннәрдә –
Кеше көлгән чакта еларга
Һәм
Кеше елаганда көләргә!

* * *

Тиле йөрәк! Аңа ялкын
Сугылганда салкын калды;
Киресенчә, салкыннарда
Яна язып ялкынланды.

Ерактагы йолдыз – якын!
Йөрәк шулай харап булды.
Яратмавы белән бер кыз
Гомерлеккә яраттырды.

* * *

Хәл белергә килеп чыктың безгә,
Озын булган юлың.
– Арыгансың, ял ит, апа, – диеп,
Урын бирде улым.

Без утырдык аннан тып-тын гына,

Сүзләр күптән беткән.
Белдек шуны: тормыш сөюдән күп
Мәшәкатьле икән.

Истәлекләр тавын кузгатмадык,
Кары ишелер төсле!
Таудан түбән төшүе дә авыр,
Тормыш бездән көчле...

Шаулап аккан сулар кебек сүзләр
Әллә кая, тынган...
Кайчак иелеп кенә су аласы
Бик килсә дә шуннан,
Кипкән барысы – күзгә чыкмый яшь тә,
Бирелсәң дә хискә.
...Чишмә тау астында. Сирәк очрый
Менгән саен өскә...
Хәл белергә килгән идең безгә,
Кайтыр юлың ерак.
– Караңгыга калам, китим, – дидең,
Мин озаттым. Авыр истәлеген
Озатып кайтты йөрәк.

* * *

Мин бу юлга ялга тукталдым.
Сәяхәтләр өчен туган күңел!
Ашыкма син, карыйм әле бер:
Нинди матур, уйчан икән бу җир!
Гөлләр җырлый кебек – ишетәсеңме?
Мин бу җиргә ялга тукталдым.

Мин дә җырлый идем,
Бушатырга теләп күңел йөген,
Сезне күреп, туктап, сокландым.
Җыр өзелде... бары бер минутка
Мин бу җиргә ялга тукталдым.

Әй күк!
Син тагын да йөзең ачтың миңа,
Тагын янды йолдыз-утларың.
Син көтәсең мине... беләм, барам!
Мин бу юлга,
Мин бит җиргә ялга тукталдым.

## «ОНЫТЫЛГАН» ИСЕМ

Бик күптәннән мин яратам аны...
Минут саен телгә алмый калмыйм.
Бик күптәннән уйлап йөрим аны,
Исемен генә «хәтеремә төшерә» алмыйм.

Күзләренең күленә төшкән ай да таныш,
Чәчләрендә күчеп йөри дулкын тавы,
Иренендә гөлләр төсе аның –
Бик күптәннән беләм, сөям аны.

Аның өчен күптән инде дөрли учак,

Аның өчен әзер йортым – бергә булсак,
Аның өчен әзер кайгым – аерылышсак;
Минут саен аны искә алмый калмыйм,
Исемен генә «хәтеремә төшерә» алмыйм.

Шул исемне башка берәр кызый
«Исемә төшерә» алса минем,
Үзен генә сөяр идем. –
Бик күптәннән бугай
                беләм аны...

* * *

Йомшаклыгың, назларың өчен яраттым мин сине!
Сын – ныклыгым өчен ярат мине!
Син – озын чәчле сусылу,
Мин – җирнең хыялый улы, –
Серле дөньяңа юнәлт гел, карат мине:
Мин яраттым сине күптән, ярат мине!

Син дөньяныураячак сәяхәтче,
Мин – туган җирен сөюче, мәңгегә...
Син – юл, бәлки, ә мин – үзән,
Син – бер кораб,
    Ә мин – үлән...
Син – тау, ә мин – диңгез,
Син – ялкынсың, мин – боз.
Мин яраттым сине, ярат мине!

Син – Төньяк, мин – Көньяк:
Икебез ике полюс.
Син – минус, мин – плюс...
Йә, тарт мине!
Кыскасы, син – мин түгел,
Мин – син түгел,
Әмма синсез яшәү, беләм,
Мөмкин түгел:
Үзеңә охшамаган өчен
Ярат мине!

## СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВНЕҢ БУНТ-МОНОЛОГЛАРЫ

### 1

Җилләре шаулап истеләр,
Истеләр җилләр бүген.
Кабарды болытлар, кара!
Каплады күңелем күген.

Үпкәсен сөйләр кемнәргә
Яшь күңел, янган күңел?
Ялгызмын, янымда читләр –
Ялгызлык әллә җиңел?

Җилләре... Әлмисактанмы,
Ул җилләр? Шаулап исте...
Бәлки, башка бер йолдызга
Йөрәкне алып китте?! –

Юкса
    ник чит мин гасырга?!
Ник үги улы итте?!

**2**

Талпына яралы аккош,
Талпына – диңгез якын...
Ул төшәр менә егылып,
Ул төшәр – сүнәр саф моң.

Яралы тәнем – минем дә
Аккошым бар йөрәгемдә! –
Китәргә телиме ул? –
Ташлап гүяки күкләргә
(Тукай-җан, синең янгамы?!),
Мәңгегә – азга түгел.
Ул бәргәләнә бүген!
...Юк, ни булса да, җирдә мин, –
Иң зур гаугасына түздем,
Аннан китәчәк түгел, –
Талпынма, Аккош-күңел!

**3**

Җилләре каршы исте лә,
Җилләрме бәхетем кисте?
Сыймады тәнгә, күкләр дә
Кабул итмәсә йөрәкне,
Күтәралмаса хисне?

Табигать, нигә зур иттең
Шагыйрь йөрәген? Ник бирдең
Ул күтәралмас көчне?!
Сиңа – тәңремә бу «аһ»ым!
Ялгыз мин, урын табалмыйм...
Йә, кемнән алыйм үчне?!
Кем шагыйрь бәхетен кисте?!

**4**

Хуш, зәңгәр күзле тәкәббер! –
Бу соңгы җырым сиңа.
Соңгы тапкыр баш иям мин
Матурлык алласына!

Хуш, зәңгәр күзле хаинә,
Алдаучы бөдрә болыт –
Соңгы тапкыр карыйм сиңа
Хыялый малай булып.

Син – зәңгәр күзле горур сын,
Таш һәйкәл, салкын мәрмәр!
Ни үкенеч, мин, алданып,
Эзләдем җанга җәүһәр.

Әй, зәңгәр бушлык! Сиңамы

Хисләрне бирдем, янып?
Ә син көлгәнсең, йөрәккә
Бары агудай тамып!
Хуш, зәңгәр күзле тәкәббер!
Ачылды күзе шагыйрьнең,
Бу соңгы җырым сиңа! –
Соңгы тапкыр баш ию бу
Мәхәббәт алласына!

## ТУГАННАР КАБЕРЛЕГЕНДӘ

Авыр туфраклары җиңел булсын!
Асыл ирләр, матур хатыннар –
Барысы да бергә урын алган:
Уртак монда урын, законнар.

Яшерен тарих үзе күмелгәндер
(Тарихның да шундый кабере бар);
Кеше исеме белән бәйләгәнгә,
Каберләрнең безгә кадере бар.

Күпме башлар үзе өчен туган,
Иле өчен гомерен яндырган, –
Ә үзенә күпне сорамаган:
Баш очына тик таш калдырган.

## КЫЗЛАР БИИ

Кичә җем-җем көлгән гөлләр
Башын игән бүген таңда.
Башка гөлләр үсә хәзер,
Башка кызлар бии тауда.

Миләүшәләр сөя идем,
Бүген – алда резедалар...
Тауда һаман кызлар бии,
Яшьлек белән кочаклашып,
Таңга кадәр бии алар.

Үзгәрәме шулай кеше?
Ошый иде миңа зәңгәр –
Хәзер нинди төскә гашыйк? –
Бии алмыйм таңга кадәр.

Кичен кара иде бу чәч,
Кырау төште әллә таңда?!
Яшьлек үтә. Ләкин анда –
Яшь гөлләрне кочып, япь-яшь
Кызлар мәңге биер тауда.

* * *

Киткәнеңне белеп, азмы җилләр
Шакып үтте минем капканы.
Әйтте күпләр:
– Һәр озаткан көтми,
Киткәннең дә мөмкин кайтмавы...

– Кайтыр! – дидем.
Шушы сүзнең моңы
Колагымны көн-төн чыңлатты.
Кайттың!
...Юллар безне елатып аердылар,
Еллар очраштырып елатты.

* * *

Дусларымның бер дусы мин,
Ә мин үзем мең дуслымын.

Исән чакта, дуслар, бүген
Әйтеп калыйм шушы сүзем:

– Сезнең өчен бер кеше мин.
Минем өчен, дуслар, сез – мең.
Шатлык сезгә минем гомер.
Үлсәм – кайгы, меңгә ул – бер...

Мөмкинме тик, дуслар, үлү?!
Мең дуска мең кайгы бүлү?!
Мең дуска дус булып һаман,
Шатлык белән җирдә калам.

## ВӘГЪДӘ

Кара җирнең кара малае мин:
Ашап үстем кара икмәген...
Ләкин үзем әле туган җирдә,
Чәчеп, урып, иген икмәдем.

Тик кунакка кайтам авылга да,
Ераклаштым мәллә авылдан?
Шуңа әрнү белән йөрәгемдә
Вәгъдә булып сүзләр язылган:

– Гомер атлы зәңгәр бәйге аты!
Син егылсаң, кабат тормам мин;
Ләкин вәгъдә: яшәгәндә Җирдә,
Кайгы игене чәчеп урмам мин.

## УКЫТУЧЫ

Уч төбенә куеп Җирне гүя,
Бүгенгесен аның, үткәнен
Күрсәтте ул безгә... урап кайттык
Күрелмәгән илләр үтәли.

Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
Көрәшергә безне өндәде:
– Яратыгыз Җирне! – диде һаман,
Ләкин:
– Мине яратыгыз! – димәде.

Аңа бүген еллар аша карыйм:
Көлеп басып тора күңелдә...
Ах, хәйләкәр абый!

Җирне, кешеләрне яраттырып,
Яраттырган икән үзен дә!

* * *

Миңа: «Мәңге шат син», – диләр.
Шатлык кемгә кайгы, юләр! –
Еламаган һәркем көләр;
Җир законы шундый ла, дус!

Дөнья матур, матур ласа:
Таң ата да кояш бата,
Йолдыз яна һәм ай калка...
Безнең өчен бит бар да, дус?!

Җирдә тудык, сөеп үстек,
Тауга мендек, дәрья кичтек,
Тормыш нәрсә бирсә – эчтек,
Исермәдек ич бер дә, дус?!

Сөрә-чәчә, ура-суга,
Сизелми дә гомер уза;
Кием түгел, кеше туза,
Үкенечкә түгелдер, дус!

Дөнья бездән матур калсын,
Шат буыннар һаман артсын;
Шатлык сыны булып барсын
Киләчәккә безнең җыр, дус!

## КЕШЕЛӘР

Кайберәүләр үзе көлми – җитди,
Ә көлдерә белә.
Берәүләр һәрчак шаян, ләкин кирәк чакта
Җитди күренә белә.

Яки үзе шаян булган үзен
Һәрчак шаян тота.
Һәм һәрвакыт җитди булган
Башкаларны җитди итә.

Ләкин барлык бу сыйфатлар берүзендә
Булган кешеләр очрый;
Алар тормыш төсле кызык,
Алар миңа ошый!

* * *

Биек камышлы тирән күл.
Үрелеп су эчә атлар,
Ә суда көмеш Ай бар.
Малай чакта куркып йөрдем:
– Йотмасын Айны атлар!

Күңелдә шатлыклар тайдай
Тупырдап йөргән көндә
Сөйгән кызым белән икәү

Чагыла идек күлдә.

Су эчеп, шәүлә тирәли
Атлар да йөри иде.
Ай да исән, атлар аңа,
Без булгач, тими иде.
Кыз тын гына җырлар җырлый,
Учаклар дөрли иде.

Бүген дә күлдә – көмеш ай,
Бүген дә йөри атлар.
Күлдән тыныч күңел белән
Китәбез без: башка парлар
Төн буе Айны саклар!

* * *

Бер яманлык теләмәде ул кыз,
Яратмады гына мине.

*Һ.Һейне*

Малай идем:
Исемемне
«Юаш» диеп тараттылар.
Юаш булган өчен яратмады күпләр,
Күпләр – яраттылар.

Егет булдым:
Инде исемемне
«Усал» диеп тараттылар.
Усал булган өчен яратмады күпләр,
Күпләр – яраттылар.

...Мин сөйгән кыз «усал» йә «юаш» дип
Һичкайчан да
Исемемне таратмады.
Исемемне ул кыз таратмады...
Бары яратмады.

* * *

Ничә тапкыр инде йөрәк мине
Әйдәп гөлбакчага китерде.

Чәчәк атып килгән яшь-яшь гөлләр,
Эсселектән арыган шикелле,
Су сорыйлар... яшь кыз ашыга-ашыга
Су китерә гөлгә сибәргә.

Гөл яраткан уйчан шул чибәргә
Бер серем бар. Ничек сөйләргә?

– Мин дә, мин дә шундый бер гөл, чибәр,
Чәчәк аттым – йөрәк ашкынды...
Синең алда җилдән бөгелгән бер
Чәчәк итеп идем башымны.

Оялчан да, таләпчән дә яшьлек,
Тели шашып-шашып сөяргә.

...Күрәсеңме, гөлләр су сорыйлар,
Су сорыйлар... Кирәк сибәргә.

**АЙНЫ ТАПМАДЫЛАР**

Алар ничә еллар буе инде
Берсен-берсе сөйде.
...Кичә юктан гына күңелләргә
Кара болыт килде.

Төнен йокламады, үртәлде кыз,
Йокламады егет...
Бүген кичен килештеләр алар,
Берни дә юк кебек,
Күңел күгенә килгән шул болытны
Алып ташладылар.

...Ләкин инде күктә элек булган
Айны тапмадылар.

* * *

Янган йөрәк, сузылган кул –
Минеке.
Ике толым, кап-кара күз –
Синеке.
Егерме ике кояш эзе –
Минеке.
Уналты яз, гөлчәчәкләр –
Синеке.

...Ал йөрәгем! Бүгеннән ул
Синеке.
Синең йөрәк булсын ләкин
Минеке.
Ал кулларым! Нык, каты кул –
Синеке!
Язың, ямең синең булсын
Минеке.
Син ризамы? Юк, дисеңме?
Синең эш.
Сөймә мине, оныт! дисең?
Синең эш!
...Тик оныту һәм онытмау –
Минем эш.

* * *

Аның белән көлеп сүз башладым,
Көлеп җавап бирде.
Уйнап кына: «Чыгасыңмы?» – дидем,
Уйнап: «Ярар!» – диде.

Көлеп кенә кичен кочакладым,
Көлеп үптем үзен,
Уйнап кына үпкәләгән булды,
Яшерде дә йөзен...

Көлеп кенә суга төштек икәү,
Утка кердек уйнап.

Аерылышкач кына белдем аны
Сөюемне чынлап!

**РОЛЬ БИРГӘННӘР**

Балачакта уйнап роль бүлештек:
Син – тау кызы, мин – бер көтүче;
Син сөясең, аннан онытасың,
Ә мин – мәңге янып сөюче.

Зурайдык та чынлап сөештек без
(Картлар моны язмыш дигәннәр).
Син ташладың мине...
Ә мин – сөям.
Безгә рольне белеп биргәннәр.

* * *

Башта сине мин сөймәдем әле,
Тик ошадың миңа.
Ятлар: «Син сөясең аны», – диде,
Һәм ышандым моңа.

Бернәрсә дә сиздермәдем сиңа,
Сиздерделәр ятлар.
Һәм синнән дә беркөн «сөям» сүзен
Китерделәр ятлар.

Без беркайчан күрешеп сөйләшмәдек;
Утлар инде янды.
...Ятлар бирде безгә бу сөюне,
Ятлар кире алды.

* * *

Әгәр мәхәббәт эшендә
Шундый кенәгә туса,
...Мактау, жалоба, тәкъдимнәр
Языла торган булса,
Жалоба язган кенәгә
Җирдән зур булыр иде...

Мактау сүзләре җыелса,
Океаннар тулыр иде.
Яңа туфан калкыр иде,
Тәкъдимен язса кеше...

Әллә ниләр булыр иде,
Аллага шөкер, мәхәббәт –
Һәркемнең яшерен эше.

* * *

Еллар буе сөеп, күзләреңә

Туры карамадым.
Үпкәлисең: болай кылануың
Әллә яратмавың?

Шикләнүең нигә инде синең,
Әй, күземнең нуры?!
Мин Кояшны сөймиммени? Ә бит
Карый алмыйм туры.

## КАЙТ КИРЕ!

Син киткәнсең...
Үткән яз кире кайтмый.
Бер өзелгән гөл дә чәчәк атмый,
Елга кире акмый –
Ә син кайт кире!

Мәңгегә киткәннәр кайтмый
(Истәлекләр әле кайта),
Еласаң да хәтта
(Үткән өчен елау, бәлки, хата?),
Яшьлек, иң беренче сөю кайтмый.

Кайтмый үткәннәр –
Кайтмасын, белдереп, әйтеп,
Мәңгегә киткәннәр.
Ә син кайт кире!
Син кайтырга тиешсең:
Киткән чакта син
Китүеңне әйтмәгәнсең;
Кайтып, шуны син әйтергә тиешсең.
Кайт кире!

## СОРАУЛАР

Мин әтигә сораулар бирер идем:
– Ник хатаны төзәтү – авыр,
                    эшләү – җиңел?!
– Юллар күп... ә үз юлыңны табу читен?
– Нигә дошман була кайчак
                    бу – дус диеп белгән кешең?
– Кавышу бар. Ләкин нигә аерылышу?
– Нигә сагыш, үзәк өзелү, эчең пошу?!
– Нигә кирәк нәрсә – ерак,
                    әмма кирәкмәгән – якын?!
(Су кирәктә бирмиләр бит ялкын!)
– Нигә ялган баллы, ә хакыйкать ачы, тәмсез?
– «Нигә» сүзен еш әйтәбез икән ник без?!
...Мин әтигә шундый сораулар бирер идем.
Ләкин ул юк.
Исән булса да, ул җавап бирмәс иде кебек:
Сораулар –
        безгә әтиләрдән мирас – тормыш.
Җавап табу – безнең бурыч.

Улыма да мин,
Ахры, җавап түгел,
            сорау калдырырмын!

## ТАУЛАР ТУРЫНДА УЙЛАР

* * *

Мин Кавказда булдым.
Данлы таулар...
Һәм халыклар монда данлылар.
Таудай горур кешеләр иле Кавказ!
Таулар – кеше кебек, җанлылар.

Киек менгән тауның башларына,
Биек менгән ничек бөркетләр!
Җәйран кебек җитез чая кызлар
Һәм бөркеттәй монда егетләр!
Мин Кавказда булдым...

Бөтенләйгә
Гашыйк итте бугай тау иле...
Биеклекне тойган күңел!
Хәзер
Тауларга тиң сүзләр тап инде!

Мин Иделгә кайттым. Илемдә дә
Сагынам таулар илен,
              Яшермим:
Үзәннәрдә таулар җырын җырлыйм
Мин – ирекле Кавказ әсире!

### Биеклекләр

Мин үзәндә туып, үзәндә үстем,
Биекләргә тартты йөрәгем;
Мин тауларга мендем... Чикләнмәде
Таулар белән генә теләгем.

Һаман биек илтә минем юллар,
Һаман күтәреләм –
Нилектән?
Ә ник биектәге аска төшә,
Атылып йолдыз төшә биектән?

Җир, күк... Ахры, һаман бер-берсенә
Җибәрәдер шулай илчеләр:
Күктән метеорлар төшә җиргә,
Җирдән күккә менә кешеләр.

### Авар шагыйре Мәхмүткә

Синең җырлар миңа шулкадәр дә
Якын булыр икән!
Беләм, сөю бөркет иткән сине,
Сөю харап иткән.

Тауларга тиң текә, горур булган,
Кыю булган җаның...
Тик идергән синең башны гүзәл,

Әмма салкын ярың.

Ул кызны мин һаман уйлап йөрим:
Газап белән бергә
Ул бит сиңа мең елларга җитәр
Үлемсезлек бирә.

Мин үпкәлим аңа: аңламаган,
Сине ташлап киткән.
Һәм аклыйм да: яратмавы белән
Сине шагыйрь иткән...

**Һейне тауларда**

Мин тауларга китәм...

*Һ.Һейне*

Туйдырдылар вак җанлылар аны.
Ачу итеп менә аларга,
Утлар-гамьнәр янган зур йөрәген
Ул күтәрде биек тауларга.

Ә тауларда тын, мәһабәт дөнья,
Тик болытлар яннан агыла.
Әрсез түгел алар, кагылмыйлар
Фамильярлык белән җаныңа.
Таратмыйлар эч сереңне урлап,
Тема итеп дошман телләргә,
Түбәнлекләр түбәндәдер, монда
Чишмәләр саф, уйчан җилләр дә.
Оныттырыр таза тау һавасы
«Дус»лар биргән яла ярасын;
Оныттырыр кыен җырны, бәлки,
Хәтта усал ярның карашын...

Әй, кешеләр, сездән бизмәде ул,
Нәфрәте тик түбән җаннарга.
Сезне көтә, чакыра биеклеккә,
Тик горурлар,
Тик бөркетләр иле – тауларда.

**Мактанма, тау...**

Мактанма, тау, биек дип үзеңне.
Шуны уйла күбрәк:
Горур күрсәтергә сине, янда
Үзән җир дә кирәк.

Матур ярым, син балкыйсың көндәй,
Әмма тыңла мине:
Шигырьләрем белән балкытмасам,
Горур башым имәсәм мин аска,
Күрерләрме сине?
Мин тау иттем сине!

**Бер көн**

Карлыгачтай уяна да
Хыял сәяхәткә китә...

Зәңгәр иртә.
Уйларда – бөтен Җир шары...
Ә йөрәк – иң ерак күктә...
Төш җитә.
Кояш белән бергә байыйм –
Таулардан төштем үзәнгә
Күксел кичтә.

* * *

Таш ватып, тауда үткәнгә
Гомере,
Тау башында тора ташчы
Кабере.
Исән чагында ташларга
Инанган;
Ә табуты таштан түгел,
Имәннән.
Һәм тормый таш басып каберен –
Өстендә –
Дуслары анда һәрчак гөлләр
Үстерә.

**ТӨШ**

Төш күрдем мин:
Дуска тик бер төнгә
Күзләремне бирдем...

Гашыйк булды карап бер күрүдә
Сөйгәнемә минем.

Күккә карап минем күзләр белән,
Үзе йолдыз булды.
Җиргә минем күзләр белән карап,
Зәңгәр диңгез булды.

Аһ, дөньяга нәкъ минемчә карап,
Шагыйрь булды дусым:
Мин сокланган бөтен нәрсә бүген
Алды аның һушын.

Һәм... качарга җыенды ул урлап
Минем сөйгәнемне.

Мин нишләдем?! Кире алдым, ашыгып,
Дустан күзләремне.

* * *

Тагын бер төш: мин үлгәнмен,
Халык мине күмә икән...
Дошманнарым елый никтер,
Ә дусларым көлә икән!
Сөйгән ярым бәхет кошын
Тотканмыни, күр, нишләгән?!
Ә көндәшем тирләп-пешеп
Һәйкәл коя көмешләрдән.
Дуслар, кире чыкмасын! дип,

Авыр таш куйган өстемә...
Ә дошманнар – траурда,
Күз яшьләре гөл үстерә.
Котым чыкты! Менә ничек
Кешеләрдә алдандым, дим.
Һәм... уяндым. Ярый әле
Исәнмен! дип шатландым мин.

* * *

Гөлләр көзен орлык чәчә җиргә –
Һәр ел шуны күрдем.
Ә мин үткән җәйдә мәңгелеккә
Синең
Истәлекне күмдем.

Шытып чыгып, яңа гөлләр үсте.
(Җылы язлар килде!)
Мин бакчага чыктым. Йөрәктә тик
Гөлләр исе инде!

Йөрәк, йөрәк! Тетрәп куйды кинәт
Нидән әле болай?!
...Истәлегең синең гөлләр белән
Терелеп чыкты бугай.

**КОЕ**

Шыгырдап тора чыгыры,
Урамда зәңгәр кое.
Синдә – су алу, ә миндә
Бер күреп калу уе.

Зәңгәр кое – суы тулы,
Хис тулы минем күңел.
Чиләк тутырып алыр идең,
Ник күңел кое түгел?

Әйләнә чыгыр... Су ага,
Чиләгең тула инде.
Әллә түгимме суыңны,
Китми тор, тыңла инде!

...Зәңгәр кое яннарыннан
Синдә тик китү уе;
Минем сыман авыр сулап,
Шыгырдап кала кое.

**КЫЗ ҖАВАБЫ**

И абый, ниләр әйтим соң,
Язасыз: зәңгәр кое,
Янәсе, кое янында
Мине очрату уе.
Шигырьләрегез дә әйбәт,
Сүзем юк аларына.
Ләкин мин сезгә тиңмени,
Мин әле бала гына...

Күземә сөрмә кунмаган,
Якмаган иннек, кызыл.
Мин әле ояла торган,
Кызара торган кызый.
Әнкәй бик шикләнә, абый,
Авылда сүзләр йөри.
Шуңа да мин сезнең белән
Сөйләшми йөрим юри...
И абый, кызык үзегез,
Әйтерсең бала менә...
Шигырьләрегез бик матур,
Сүзем юк аларына.
Кешегә ишеттергәнсез,
Шушымы егет эше?
Простой диләр сезне бик,
Катлырак булыр кеше.
Шулай да моңсу үземә,
Әлеге зәңгәр кое...
Күңелдә шул коега кич
Ешрак чыгу уе!

**БУРАН ХИКӘЯСЕ**

*(Бернсчарак)*

Каерып алган шикелле
Ачылды ишек ничек?! –
Әй, кемне алып кердең син,
Әй, харап иттең, ишек!

Чәчләренә йолдыз сипкән,
Тешләре энҗемени?
Ике бриллиант шикелле
Балкыган – күземени?
Чибәр кыз! Өстен кагынды,
Эх, карлар булсам әгәр,
Ал битендә эрер идем,
Җай гына кунсам әгәр.

Кайда ул әнкәм биргән тел,
Кайда йорт, кайда урам?..
Әйтте кыз: «Өегез җылы».
Мин әйттем: «Тышта буран!..»
Кыз әйтте: «Адаштым, – диде, –
Буранда кайталмамын...
Өегез нигә болай тын?»
Мин әйттем... әйталмадым...

Әй буран, төнката булсаң,
Туктамасаң ни булган?
Китәргә кызый җыена,
Янәсе, буран тынган...
Карышып, сукранып гүя
Ачылды безнең ишек.
Кыз белән бергә, сизмәдем,
Чыктым соң әле ничек?..

Бик артта калды туган йорт,
Утларың калды, урам...

Мәңгегә күңелем юлында
Шул мәлне урап узмам.
...Әй, бу төн өчен рәхмәтем
Мин әйтмим, аңла, буран!

* * *

Бүгенге көн – кичәгенең дәвамы, ул –
Тормыш җыры! Ярат аны!
Кичә дә ул яшьлек-язда
Гөрләп аз яңгырамады!

Таңнар, гөлләр, җырлар булып
Борынгыдан, кичәгедән –
Вакыт, Яшәү, Яшьлек, Сөю
Күчә килгән. Үсә килгән...

Безнең утлар – мирас бәхет
Тауларында янган учак,
Һәм биек, зур агачларда
Безнең урын – яфрак булсак...

Күкләр дә бит шул ук, иске;
Иске, изге – сулар, җир, таш.
Ә без – яңа, без тик үзебез,
Һәм шулай ук
Үткәннәргә гаҗәп охшаш!

* * *

Шулай тиеш идеме, очраклымы? –
Язмыш ике тапкыр очраштырды.

Беренчесе:
– Апрель, – дидем. Ә син Май булгансың.
– Йолдыз, – дидем. Ә син Ай булгансың.
Алмагачлар чәчәк атканда,
Күбәләкләр куып йөри идең
Ак күлмәктән, язгы бакчаңда.

Икенчесе:
– Май, – дидем мин. Ә син Июль икән.
– Яшь Ай, – дидем. Ә син – тулып җиткән.
Алмагачта алма кызара.
Алма кебек нигә кызардың,
Бакчагызга карап узганда?!

Очраклымы, тиеш идеме? –
Ике тапкыр күрдем мин сине.

**КӨТӘ БЕЛӘМ**

Кеше түземле дә...
Табигате бунтарь булса да,
Көтә белә.

Мине дә күпләр көттерделәр.
Әүвәл көттерде үсмерчак,

Мәхәббәт көттерде:
Сүз куешкан урынга
Көттереп килде сөйгәнем,
Көттереп үптерде.

Көттерде өлгергәнлек аттестаты,
Өлгергәнлек үзе...
Автобуслар, самолетлар, атлар,
Хатлар көттерде,
Көттерде бәхет, акыл, тәҗрибә...
Көтәргә өйрәндем.

...Инде сез –
моңа кадәр мин күрмәгән, белмәгән
Картлык, кайгы, авыру –
Килсәгез,
Көттерсәгез –
Үпкәләмәм кебек:
Инде көтә беләм кебек!

**ИСЕМНӘР**

Мин исемнәр ятатучы.
Гаҗәпләнмә, нигә? димә.
Байрон исеме, Пушкин исеме,
Һейне исеме ошый миңа.

Гаҗәпләнмә, Эдисоннар,
Колумблар да миңа якын;
Җәлил исеме! Һәрберсеннән
Никадәрле мәгънә таптым.

Мин исемнәр яратучы:
Минем йөрәк,
йолдызларны үзенә җыйган
Күк шикелле,
Мең-мең исем белән тулган.

Мин исемнәр яратучы.
Ә күп вакыт... яратмаучы!
Гаҗәпләнмә, нигә? димә:
Сөйми карыйм дошманнарым исеменә,
Һәм кайвакыт үз исемем дә
Чиксезлектә очып йөргән
Мамык-йондай тоела миңа!

**БЕЗНЕҢ ОДИССЕЯ**

Без дә Одиссейлар –
егерменче гасыр кешеләре,
ерак сәяхәтләр сөючеләр.
Яки аңа охшаш ирләр.

Хәйләкәрлек белән Трояны алган
һәм яндырган
сугышчы Одиссей түгел без.
Ә бәлки ил гизүче,
өйгә кайтырга,

Итакага юл эзләүче
мәңгелек юлчы Одиссей без.

Очрый безгә дә давыл, циклоплар,
күп куркынычлар күрәбез;
Зевс әмере белән түгел,
йөрәк белән һәм кыюлык белән
барысын да без җиңәбез.

Сиреналар очрый юлда, йөзмә утраулар.
Әйләнешләр күп, ураулар;
без йөзәбез, ил гизәбез
Итаканы эзләп һаман.

Без беркөн кайтырбыз аңа –
сөекле Пенелопаны
безне көтә белүе өчен
ирләрчә кочып үбәрбез,
Язмышны җиңеп көләрбез
һәм гомерне оныкларга
Одиссея итеп сөйләрбез.

**ЯРАТАМ БУГАЙ...**

Аның турында уйланып мин
Йокысыз үткәрдем төнне бүген;
Янып чыктым.
Әгәр дә шушы минутта
Ул авырып ятса, янса утта?
Әгәр дә ул каты сызланса?
Маңгаен тотарга да кеше булмаса
                    шушы минутта?!

Төне буе мин янып чыктым.

Әгәр дә бүген ул юлда булса.
Бәлагә очраса?
Караңгыда калса һәм уты сүнсә?
Әгәр дә ул юлда булса?

Төне буе мин янып чыктым.

Әгәр булса ул бүген диңгездә?
Шторм кубып, чайкалса дулкында?
Давыл белән көрәшсә бу төндә
Диңгездә!

Төн буена мин янып чыктым.

Мин авырыйм, мин саташам бугай...
Ләкин нигә авырганда
Үз хәлемне мин оныттым?
Ник уйладым һәм кайгырттым аны шулай?!
Мин авырмыйм. Мин... яратам бугай.

**ДУСКА ХАТ**

*Хәйдәргә*

Бер анадан туып үсмәгәнбез,
Ләкин нигә йөрәк пар безнең?
Без авылдаш түгел,
Йөрәкләрне
Очраштырган җирләр бар безнең.
Мин еракта хәзер ул җирләрдән,
Син якында әле, якында,
Шул җирләргә әкият итеп сөйлә
Минем сәер йөрәк хакында.
Икәү генә тапкан чишмәләр бар,
Синеке дә алар, минеке.
Без борынгы дуслар алар өчен,
Алар да бит безгә элекке.
Элекке шул кояш, шул йолдызлар,
Алар һаман якты яна бит!
Без аларга гашыйк!..
Без һаман да
Әнкәйләргә
Һәм дөньяга
фәкать бала бит.
Араларда йөри ак болытлар,
Яңгыр булып
Алар тутыра безнең елганы...
Бармы шундый дуслык булганы?
Үпкәләшсәк ялгыш,
шушы хәбәр
Дер селкетер иде дөньяны!
Юллар бара...
Гомер илтә безне
Киләчәккә, ерак таңнарга.
Акка кара һәм зәңгәргә кара,
Караларга юлда карама.
Әле яшьлек,
Әле икебез дә
Яшь гөл кебек
Яшәгәндә кояш астында,
Йолдызларга язып җыр калдырыйк
Дуслык хакында.

**СУ БИРҮЧЕ КЫЗГА**

Озак йөртеп, баскач яшерен сөю
Иңнәремне минем,
Мин кайгымны шигырь итеп сиңа,
Дусларыңа бирдем.
Укыдыгыз аны, шаулап-гөрләп,
Озак мактадыгыз.
Аңламадыгыз тик, юатырга
Сүзләр тапмадыгыз.
Бары бер кыз минем җыр-кайгымны
Тирән аңлый белде:
– Янасың бит... Авырыйсызмы? Сиңа
Су биримме? – диде...

Сиңа багышланган җыр юк инде,
Ул юк, онытылды.
...Бүген миндә су бирүче кызга
Өр-яңа җыр туды.

**САБЫРЛЫКЛАР БИРСЕН**

Сабан туе! Кызлар, кызлар күпме!
Ак яулыклар, кызыл яулыклар.

Кара күзле кызга күңелем төште, –
Бирсен сабырлыклар!
Иптәш кызларыннан сорыйм әле,
Кайсы яктан икән бу матур?!

...Көрәш бара. Мәйдан гүли, шаша,
Кем соң өскә чыга? Кем батыр?!
Сәетнеке алды, егып салды.
«Ур-ра!» белән күккә чөйделәр...
Кызлар миңа теге каракүзне
«Ерак авылныкы» диделәр.

Быел, яшьсең, диеп, көрәштермәделәр,
Батыр калмый кызга күз салмам...
Киләсе ел безгә сабан туена
Килә генә күр син, күзалмам.

Кызлар килер... җиңсәм, кызлар күрер –
Ал яулыклар, чуар яулыклар.
...Чуар күңел, белмим, түзалырмы –
Сабырлыклар бирсен! Саулык – бар.

**ЧАКЫРУ**

Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Югыйсә артык бушанды
Күңелнең урамнары.

Кайтыгыз, җилне-давылны
Тынычтан артык күргән,
Тын йортның ишеген ватып,
Урамга чыккан көннәр!

Кайтыгыз, йолдызлы төннәр,
Беркатлы өметләрем!
Кайтыгыз, кыш үскән гөлләр,
Йокысыз минутларым!

Кайтыгыз, былтыргы карлар,
Кайтыгыз, сезгә карыйм!
...Гөнаһсыз чакның карына
Гөнаһлы исемем языйм.

Кайтыгыз, минем сөюнең
Былтыргы бураннары!
Бушанды, артык бушанды
Хисемнең урамнары!

**ҮПКӘ**

*(Үз-үземә шарж)*

Янган чагым булды бар дөньяга
Ялкын бирер булып.
(Хәзер сүрелеп барам. Күгемдә дә
Йөри соры болыт!)
Янган чагым булды! Шунда, кызлар,
Сизә алмадыгыз.
Нигә хәзер – сүрелер чакта гына –
Сөеп алдавыгыз?!

...Язган чагым булды! Давылланып,
«Һейнеларча янып».
(Хәзер шактый үтмәсләнде каләм,
Сөю-хиссез язып...)
Шагыйрь чагым булды! Шунда, дуслар,
Бер сүз тапмадыгыз.
Хәзер прозага тарткач аяк,
Нигә мактавыгыз?!

## «БӨЕКЛЕК» ТУРЫНДА

Бөекләрнең тормышын мин беләм кебек:
Байрон бөек, Пушкин бөек, Хафиз бөек.
Әмма алар барыбер кеше синең кебек, минем кебек
(Юк дисәң дә табып була бер кимчелек).
Әйтик, Байрон азрак аксак булган икән,
Хафиз – фәкыйрь, гомере буе илләр гизгән.
Уңмаганнар мәхәббәттән Пушкин, Һейне,
Ә Хәйямның «сәрхуш булып» гомере узган.
Булган, булган:
Беркатлылык, донжуанлык һәм башкалар...
Уйласаң, бу кимчелекләр миндә дә бар.
Миндә дә бар!
Димәк, дуслар, фәкыйрегез мин дә «бөек»?!
Әмма бәла:
Нидер миңа җитми, нидер һаман ерак, биек.
...Шуны уйлап, «бөек» күңелем бүген боек.

## БЕЗ КҮРМИБЕЗ

Без күрмибез
Болытның ничек, кайчан яралганын.
Күрәбез коеп яңгыр яуганын.
Без хәтта иң якын дусларның
Ни белән яшәвен белмибез;
Белмибез берәүнең төн буе
          йоклый алмавын,
Эш өстендә ничек янганын,
          рәхәтен-газабын.
Шагыйрьнең эзләнүен күрмибез.
Ләкин без сокланабыз яңа ачышларга.
Башваткыч эшләргә, хисле җырларга,
Көчле образларга сокланабыз.
Алар ничек туа? Без белмибез.
– Табигать яраткан талант бу, – дибез.

Без
Болытның ничек яралуын күрмибез.

**ШАТ КҮҢЕЛЛЕЛӘР ҖЫРЫ**

Безнең көлү – башка төрле көлү:
Гариплектән, бәхетсездән көлмибез без,
Мыскыл итә белмибез без –
Кабахәт көлүе түгел безнең көлү.

Безнең көлү кемдер елаганга түгел,
Мәхәббәттән яшь кыз алданганга түгел,
Кемдер үзенең бәхетен таба алмаганга түгел...

Безнең көлү – башка көлү.
Без көләбез – кояш елмайганда,
Гөлләр тибрәнгәндә.
Без көләбез – башка кешеләр көлсә,
Һәм көлүнең кадерен белсә.

Елмаябыз – яшь бер кызның тигез булып
Тезелгән тешләрен күрсәк,
Дуслар белән саф һавада йөрсәк.
Шат көләбез – утын ярып, тау шикелле өйсәк,
Аруларны, авырлыкны җиңсәк.

Күп вакытта сәбәпсез дә без көләбез.
Ләкин җитди була белмибезме?!
Юк, беләбез.
Тормышны без әллә күрмибезме?
Юк, күрәбез.

Яшәү күңеллерәк булсын, диеп,
Әйләнәдә һәркем көлсен, диеп,
Күп вакытта бик елыйсы килгәндә дә
Без көләбез!

**МАЛАЙЛАР**

Малайларның күбесен анекдотлар кызыктыра,
Ә романнар түгел.
Малайларга
Тыелган әйбер күңеллерәк,
Рөхсәт ителгәнгә тартмый күңел.

Малайларга олыларча булу кызык:
Сөйләшүләр, киенү,
Трубка йөртү яшереп кенә, хәтта сүгенү –
Тәҗрибәле күренү.

Малайларга бөтен нәрсә ашыгыч кирәк:
Акрын атлау кызыкмыни?!
...Олы буын әнә ничек кызу йөри,
Һәрчак алда,
Киләчәккә юллар сызып йөри.
Малайларны да бит тарта батырлыклар,
Ерак юллар, адаштырган утлар.

Малайларга тизрәк өлкән булу кызык.
Алар белми: өлкәннәрнең үзләрендә –
Күпләрендә –

Малайчакны сагыну яши:
Тәвәккәл чак – малайлык юк!
Тик аларга артка таба чигенер юл юк.
Малайларга исә барысы кызык...

**КЫРЫК ЯШЬЛЕК ДУСКА**

*Н.Х-кә*

Кырык яшьтә ир кеше ул нинди булсын?
Иң беренче:
Ул нәкъ кырык яшьтә булсын! –
Дөнья биргән олы бүрек башта булсын.
Ләкин кирәк чакта олырак күренә белсен
Һәм, кирәксә, әйдә, малай булсын!

Кырык яшьтә чын ир кырык һөнәр белә.
Кырык яшьтә
Кырык җирдә чөй калдырыр юләр генә!
Кырык яшь ул – түгел чәчү вакыты,
Кырык яшь ул – урып-җыю вакыты,
Зурат кую вакыты...
Түгелдер ул, авыз корытып,
            матур кыз дип сөйләр вакыт:
Кырык яшең – үз улыңны,
            үз кызыңны сөяр вакыт,
Унау өчен яшәп, янар-көяр вакыт.
Менә – бәхет!

Кырык яшьлек инде кырык кайгы күргән.
Кырык кабат ул үлемне җиңгән.
Кырык кабат диңгез кичкән,
Чәчләргә дә күптән инде кырау төшкән.
Ул рудадан металл булып җиткән!
Менә шундый ул кырык яшь –
Валлаһи, дим, әй кызык яшь!

Ә соң кырык яшьтә кешегә ни җитми?
Бик аз гына – яшьлек
Һәм аз гына – картлык.
Ләкин һични җитә алмый
            җирдә мондый яшькә...
Кырык яшең белән, дустым, кырык яшә!

**ИРЛӘР БУЛЫЙК**

Ирләр булыйк һәрвакыт
            һәм һәр адымда.
Малай чакта –
            уйнаганда,
Күккә карап төрле уйлар уйлаганда.
Кыйналганда.

Ирләр булыйк – үсмер чакта,
Беренче кат яратканда:
Яшьтәш кызыңа оялып беркөн аңлатканда.
Үпкәләшеп йөрешкәндә,
Килешкәндә.

Ирләр булыйк –
Якыннардан аерылганда
Һәм аларны сагынганда.
Егет булгач – юллар үтеп арган чакта,

Ерып булмас карурманда калган чакта,
Куркынычның күзенә карап барган чакта, –
Тормыш таләп иткән һәр урында,
Утта, суда.

Ирләр булыйк –
Мәхәббәттә җиңелгәндә,
Чигенгәндә.
Кайгы һәм шатлык килгәндә,
Мәҗлесләрдә, бәхәсләрдә...
Акыл һәм дәрт көрәшкәндә.
Вәгъдәләрдә...

Ирләр булыйк – ир булгач та,
            картайгач та.
Ирләр булыйк!
Һичьюгында,
Күк гөмбәзен
           иңебездә
Бары бер көн тотып торыйк!
Ирләр булыйк!

## *II. Мәхәббәтнамә*
***(1965)***
**ЕГЕРМЕ ДҮРТ ЙОЛДЫЗ ҺӘМ**
унҗиде диңгез

### Кереш

– Әнкәй, җибәр мине ерак сәяхәткә,
Илләр буйлап йөрим...
Рөхсәт итче, җирнең читен күрим.

(Баш очымда нәкъ унике йолдыз!)

– Әнкәй, җибәр мине сәяхәткә,
Күңел диңгезләрен күрим
Һәм, утраулар ачып (алар күптер анда!),
Исемнәрен бирим.
Әнкәй, җибәр!.. Сау бул!

(Баш очымда нәкъ унсигез йолдыз!)

– Әнкәй, ялга кайттым, дөнья чиксез матур,
Әле ару белмим.
Ачуланма, синнән
Шуны мин сорарга телим:
Күңел байлыкларым күп җыелды,
Рөхсәт итче,
Җир кызына бүләк итеп бирим!
(Баш очымда егерме дүрт йолдыз!)
Ә йолдызлар күп бит, әнкәй! Сөен...

### 1

Таныш рәсем: ачык балкон һәм Татьяна.
Ак күлмәктән. Онегинга ул хат яза.
Чәчәк сибелә төн йөзеннән, йолдыз ява.

(Ак күлмәк бик килешә сиңа;

Шуны киеп, Татьянадай,
Хатлар язсаң иде миңа...)

Һәм икенче рәсем: анда
Онегинның үгетен тыңлый яшь Татьяна.
Калтырана үзе, яна.

(Син Татьяна булсаң иде,
Мин Онегин булмас идем!)

Өченчесе: шул Онегин,
Иргә чыккан Татьянаның
Аягына егылып, аның
Сөюен сорый. Ә ул – салкын.

(Мин кимсетмәс идем шулай үз-үземне.
Юк, иң башта мин рәнҗетмәс идем сине!)

Китап укыйм. Ә уемда тик син һаман...
Минем алда –
Бер-берсенә охшамаган ике роман.

**2**

Мин очраттым юлда сине,
бәхетем минем!
Мин бу җиргә синнән алда килдем,
Син соңладың бераз...
Соңлаган күк быелгы яз!
Уйга чумып, узган юлыма карый идем
(Нинди матур уйный язгы кояш!),
Сине күрдем:
Нинди матур син, нинди яшь!
Кояшка карап,
Киләчәккә юл башлыйсың бугай.
Без очраштык юлда шулай.

**3**

Бу – җыр.
Туу, яшәү – бер җыр;
Сөю, сөелү – ул да шулдыр,
Бер җыр – аның асылында Тормыш.
Син бу җырны хәтерләргә тырыш!

– Яшел яфрак күмгән язгы агач!
Мин таянып аңа басып тордым.
Зәңгәр күктә аккан болыт! –
Гүя тәү кат барсын күрдем:
Гашыйк булдым.

Бу – җыр, асылында аның – Тормыш,
Син аңларга аны тырыш!

Су өстенә агач шәүләседәй ятып,
Сыенып,
Яшь җаныма җавап көттем ярда.
Елга кебек таштым, таштай тындым,
Томан кебек киттем таңда.

Бу – җыр, исеме – Тормыш...
Тыңлыйсыңмы, ник син тыныч?

Китәм, әмма «сау бул» димим,
Кире кайтырга дип китәм. Саумы, сөюем!
Саумы, язмыш!

Бу – җыр, аның исеме – Тормыш.
Миңа кирәк ул җыр, кирәк!

Аңламыйсың аны?
Димәк, син әлегә
Миннән күп тапкырлар бәхетлерәк!
**4**

Дулкынга син тездән атлап кергән идең.
Кояш судан яңа чыгып килә әле.
Су чәчрәттең, үзең көлдең.
Һәм шул мәлне
ишеттең син:
– Борыл, кызый!
(Әни бугай?!)

Дулкынга син билдән кереп баскан идең:
Алга төбәп карашларың,
Толымнарың сүтеп суга син ташладың.
– Эчкә керәм, барыбер йөзәм...
Кемдер әйтте:
– Борыл, кызый!
(Әти бугай?!)

Дулкынга син күкрәгеңнән күмелеп кердең.
Тагын көлдең:
– Алга, алга...
Әнә анда
Бәхетем минем, алгы ярда.
Киттем!
...Һәм ишеттең:
– Хәерле юл!
Ярга җитми борылма, кызый!

Кем соң әйтте шулай?!
...Яшьлек бугай.

**5**

Безнең ара якын иде,
Бер-беребезнең җанына
Башта шундый якын килдек:
Сиңа тик бер адым алга –
Ә миңа бер адым артка
Атларга иде! –
            без аңлашыр идек!

Нигә бу адымны атламадык? –
Әллә артык горур булдык,
Әллә икеләндек?

Хәзер инде ераклашкач ара,
Ул адымны минут саен атлыйм,
Үзем гел кабатлыйм:
– Безнең ара якын иде, якын!
Онытасы иде ләса «иде» сүзен!

Ә син –
Нәрсә дисең?!

**6**

Миңа исем бир син, бер исем бир
Минем янар хисләремә,
Күтәрелеп килгән давылыма,
Көпә-көндез күргән төшләремә...

Исем эзлә, дөрес бер исем тап
Күңелдәге ярсуларга.
Яраларга...
Җанны баскан йөккә...
Шашындырган тиле көчкә...
Бер исем тап син шуларга!

Бер исем тап минем сәерлеккә,
Йокысызлык,
Алмашынган матурлык һәм ямьсезлеккә...
Бер исем бир минем киләчәккә,
Бүгенгемә, үткәнемә...
Тормышыма – язылып килгән романыма –
Бер исем бир!

Үтенәм синнән!
Бер исем бир!
Ләкин,
Кеше, диген.
Мәхәббәттә кешеләрчә көчсез,
Һәм шулай ук, көчле, диген.

**7**

Мин төш күрдем:
            алда нәкъ унҗиде диңгез!
Син күргәнсең:
            күктә егерме дүрт йолдыз!
Әйт, нәрсәгә дип юрыйбыз?

Ул йолдызлар – минеке иде,
Ә диңгезләр – синекеме?

Хәзер шул унҗиде диңгез
Күңелемне –
        йолдызларны үзенә тарта
             һичөзлексез!

Куркам,
Әгәр төш дәвамын күрсәң;
– Йолдызларың диңгезләремә егылып төшеп,
Бөтенесе батты! – дисәң!

Ә мин хәзер төшләр күрмим:
Сине уйлап йокысыз мин!
**8**

**Утрау**

Сине мин беренче булып ачтым –
Синең кыргый матурлыкны күрдем.
Мин беренче булып сиңа исем бирдем:
Син – билгесез, кеше аягы басмаган
Бер утрау идең,
Мин, Робинзон, сиңа килдем.

Сиңа әле кояш нуры төшмәгәндә,
Туфрагыңда бер чәчәк тә үсмәгәндә
Сине сөйдем.
Һәм сөюем белән
        сиңа кешеләр китердем мин.

Менә бүген мин шулардан сине көнлим.
Мин китәрмен, ахры, ят илләргә,
Качып түгел, диңгезләрдә
Яңа бер утрау эзләргә.
Табармын да:
    «Ул тагын да матуррак», – дип,
Мин мактармын кешеләргә.

Һәм барысы да синнән китеп беткән көндә,
Яшерен генә килеп, инде
Бөтенләйгә мин калырмын синдә.

**9**

Бәхетлеме бергә булу белән алар?!
Кырыс тарих дәреслеге – беренчесе...
Хыял сыйган нәфис дәфтәр – икенчесе.
Ничек шулай бергә куелганнар?
Куркып уйлыйм:
– Безгә охшаш түгелме алар?!

**10**

Мин күзәтәм бер малайны:
Ул өметсез сөя, яшерен яна...
Ул алдана.
Күкрәгендә тау күтәрер эһ тә итми.
Ә сөйгәнен онытырга көче җитми.

Мин яратам ул малайны!..
Ул чын гашыйк,
Назлар көтеп кенә, әйе, яратмый ул...

Тик
Мин кызганам да аны:
Бу беренче сөюендә
Мине –
Минем малайчакны кабатлый ул.

**11**

«Мәхәббәттән башка берни белмисең син,
Күрмисең син...» –
Шулай диләр.
Юк, мин беләм,
Мәхәббәттән башка да мин күпне күрәм:
Гөл керфекләре тибрәнеп ни аңлата?
Сандугач ник җыр ярата? –
Әйтеп бирәм.

Мин йолдызлар телен беләм...
Искән җилләр нәрсә сөйли,
Яшь тупыллар нәрсә көйли,
Бәхет кайда күбрәк үсә,
Кайгының ник көне бетә – барсын беләм.

Мин тормышны бөек иткән көчне
Мәхәббәттә –
Илгә, җиргә мәхәббәттә күрәм.
Һәм яшермим: сөям, сөям!
Мине
«Хисләреннән шашкан» дисез, әйеме?!

Бер сүзем юк...
Мәхәббәтнең
Мәҗнүн исемендәге премиясен
Бу ел өчен миңа бирегез, яме?!

**12**

Иртәдән бирле йөзем чытык минем:
Мин
    үземнең беркөн
        үләсемне искә төшердем;
Күз алдыма килде
Соңгы юлга озатуың мине.
Юатырга бик теләсәм дә, мин
Юата алмам сине ул көн.
Гомеремдә беренче кат,
        исем китмәгәндәй,
            мин карармын сиңа
Дәшми, тып-тын.
Елап озатырсың.

Кайчан үләсемне әйтә алмыйм,
Һичкем аны белми.
Тик
    иртәдән бирле йөзем чытык минем:
Мин,
    кайчан да елатып,
            сине җәберләргә теләмим!
...Үләсем дә килми.

**13**

Биек тауга менә идек,
Җитәкләргә мин теләдем сине.
Кулларым буш түгел иде.
Мәгәр
Мин күтәргән идем
        хыял атлы җәүһәр.

Тукталдым да
        бу байлыкны җиргә куйдым.
Аннан
        кулларымны сиңа суздым.
Ләкин күрәм:
        мин тукталган арада син

Үз кулыңа
        тәкәбберлек атлы
            авыр таш алгансың.
Шул ташыңны ташлавыңны
        көтә күңел,
Юкса
     җитәкләшеп менү мөмкин түгел.

Ә тауга без
Барыбер менәрбез.

**14**

Хәерле иртә!
Капкагызны аччы, сеңлем!
Бакчагызны күрим сезнең...
Алмагач чәчәкләренә –
Синең бәхетең төсенә
Карап сокланасым килә.
Капкагызны аччы, сеңлем!

Хәерле кич!
Бакчагыздан китәм, сеңлем!
Мин бернигә дә тимәдем.
Чәчәкләрне дә өзмәдем.
Бик ошады миңа бакча.
Ләкин
Һәркем кереп йөрмәсә иде,
Бикле торса иде капка.
Гөлләреңне сагынып синең,
Мин килермен. Сау бул, сеңлем!

**15**

– Зәңгәр болыт! Үзең белән
Сөю алып килче миңа!
Күңелгә шундый уй килә:
Нәрсә ул сөю? Ул – нигә?
Карыйм әле бер үзенә!
Зәңгәр болыт!
Сөю алып килче миңа!

– Ак болыт! Син бәхет китер
Мәңге талмас канатыңда,
Ерак диңгезләр артыннан...
Бәхет нинди?
Җиңелме ул, түгелме ул?
Мин күтәреп карыйм аны.
– Ак болыт! Син бәхет китер!

– Күк болыт! Син сагыш китер,
Тик бер тапкыр тәмен татыйм.
Нинди булса да барыбер...
Мин һичкайчан, ахры, китмәм
Сөю, Бәхет, Сагыш биргән
Мәңге изге туган җирдән!

**16**

Синең дустың

синең күз карашыңны да хәтта күтәрмәсә,
Иртәгә ул
бар дөньяны иңенә салыр – синең дустың.

Бер сүз әйталмаса бүген, очрашканда,
Ә иртәгә үлемгә сүз әйтә алыр –
синең дустың.

Бүген тамчы булып тама ул алдыңа,
Ә иртәгә күк күкрәтеп,
яңгыр коеп үтәр дустың...

Бүген ул –
бер чуерташ тик
ярда яткан,
Ә иртәгә
мәрмәр булып,
алмаз булып китәр дустың.

...Көчең җитмәс,
юк, калдырма иртәгәгә,
Гади йөрәк – синең алда,
иплəп кенә кулыңа ал,
күтәр, дустым!

**17**

*(Газәл)*

Бөек Шелли җанын үзенә тарткан диңгез!
Синдбад үзенең сәер бәхетен тапкан диңгез!
Робинзонга яңа тормыш биргән диңгез!
Үзеңә тарту көче синдә каян, диңгез?!
Колумблар, куш йөрәклеләр гизгән диңгез,
Синнән кемнәр генә кайта алган, диңгез?
Сиңа илтә бик күп юллар, ә кайтыр юл
Туган якта... төшкә керә һаман, диңгез!
...Хыял – ул да йөрәкләрне үзенә чакырып,
Тик һичкайчан кире кайтармаган диңгез!
Ике диңгез...
Авырса да тозлы җилдән, сусаудан җан,
Китә алмам, сездә калам, калам, диңгез!

**18**

Мин – карт моряк. Барысы да кызык миндә:
Җил ярган йөз, арыган күзләр,
Зур төрепкәм, төтен, сүзләр...

Ә син – миңа бик кадерле диңгез рәсеме,
Һаман туя алмыйм күреп сине.
Буяуларың җуелмасмы еллар белән? –
Сыйпап куям калтыранган куллар белән.
Дәшми генә син карыйсың карт морякка,
Ә ул сөйли, һаман сөйли,
сүз гел арта.

Син тыңлыйсың...
Ә ник сүзгә кушылмыйсың?!

**19**

Кичке авыл, матурсың син:
Тәрәзәләрдә елмаю...
Йокларга әзерләнәмсең?

Капка төпләрендә парлар
Бер-берсенә сыенганнар...
Ә ник анда
Ялгыз күләгәләр дә бар!?

(Төнге авыл, моңсуландың:
Төшеңә ялгыз мин кердемме
Яки горур ярым?)

Биек коймалы йортларын
Көнче ай саклый төн буе...
Ә мин тәрәзәгә килдем,
Ача алмыйм, җитми буем...
Күк, уятмас микән ярны,
Тәрәзәдән
Кереп, синең йолдызларың?

Төнге авыл, ник уяндың?
Әллә мине
Юатырга теләдеңме?!

**20**

Ачуланып, тамырларын өзделәр...
Ә гөлләрем үлмәделәр,
Гел кояшка үрләделәр...
Син янымда идең!

Аяк астымда тетрәп җир шуышты,
Мин һаман да егылмадым...
Син янымда калдың!

Бүген бөтен нәрсә үз урынында, тыныч.
Мин,
Бушлыкта калган кебекмен,
Бернәрсә дә күрмим, тапмыйм...
Син киттең...

**21**

Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген:
Диңгез шавы колагымда.
Акчарлаклар уйнаклыйлар, төшеп монда.

Ярга килә дулкын арты дулкын тавы.
Кинәт диңгез тып-тын калды.

Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген.

Күз алдымда – бер йөрәк... ул
Бар дөньяны урап чыккан.
Йөрәк – алма,

ачлар аны кулына тоткан, авыз иткән.
Кызыл алма... арыган да хәзер ярга
Тукталган ул – бары ялга.

Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген.

Кипарислар һәм тупыллар,
Ак каеннар, кызыл таллар –
Көньяк белән Төньяк бергә кушылганнар.

Алда – кеше.
Бер кулына Җирне тоткан, саклап тора.
Икенчесе белән бөек табигатьнең
Чәчен сыйпап, назлап тора.

...Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген.

Тыңла, сиңа
Үзем күргән
Назыйм Хикмәт турында мин сөйлим бүген.

**22**

 Яралы җанвардай үкерепме,
Ничек аңлатырга
Астыртыннарга нәфрәтемне?!

Алар урладылар сине!

Минем сиңа хисләремне,
Мөнәсәбәтләрне белмичә,
Белергә дә теләмичә
Алып китте алар сине.
Хәер, син үзең дә китәр идең.
Алар аңлаешлы иде:
Алар сиңа тулысы белән ачылмады,
Алар салкын канлы иде,
Алар минем кебек шашып сөю җырламады,
Алар нәзакәтле иде,
Алар ышандыра белде.
Алар сиңа күптәннән үк кирәк булган.

...Яралы аюдай үкерәм ачудан.
Шомалар тагын бер кат җиңде!
Бүген килеп алар
Минем бәхетемне урладылар.
Өйрәнелгән бер хәрәкәт белән,
күз дә йоммый гүя,
Кояшны, үрелеп алып,
Кесәләренә салдылар.

**23**

Зур корабка – зур дәрья, ди.
Бу ярларны калдыр, Сөю.
Зур йөрәккә – зур кайгы бар,
Җиңел бәхеткә ышанма,
Тын ярларны калдыр, Сөю!

Монда – ташлар. Салкын алар.

Алар дәшми, җанлы түгел.
Өмет-чәчәк сула монда,
Җавап-сөю көтмә, күңел!

Аңламаслар сине монда,
Таш булырсың, йөрәк, син дә,
Бу ярларны калдыр, Сөю! –
Зур корабка – зур дәрья, ди.

Син киттеңме, Сөю?
– Әйе...

Яр буш хәзер, тып-тын тора.
Ачы итеп җил сызгыра,
Ә зур йөрәктә – зур кайгы.

**24**

– Мине ярат, – димим сиңа...
Табигатьне ярат:
Яңгырларда чылан, кояшта ян,
Җилгә чәчең тарат.

Каеннарны кочаклап үп, талларны сөй,
Тауларга мен, җырла өстән карап, –
Биеклекне ярат!

Диңгез белән таныш, рәсемен күреп түгел,
Колач салып, дулкын чәчен тарап;
Гөлләр белән дуслаш,
Кояш белән, йолдыз белән сөйләш, –
Чиксезлекне ярат!
Ярат табигатьне!
– Мине ярат, – димим.
...Ә табигать, беләм, юлларында
Очраштырыр безне беркөн!
Аңлашырбыз, шикләнмим мин.

**25**

Нинди яз бу?
Һәр көнендә шатлык килә, кайгы килми.
Ләкин, гаҗәп:
Бер шатлыгым арткан саен, бер дус кими.
Сәер яз бу!
Һәр көнендә бәхетлерәк була барам...
Һәм кемнедер, нәрсәнедер җуя барам.

...Иң зур шатлык – бәхетемне
(Сине сөюем-сөелүемне!)
Мин һичкемгә әйтми тотам:
Соңгы дусым бүген янда,
Ул да
(Гашыйк иде бит минем күк сиңа!)
Әгәр белсә, күтәралмас бу хәбәрне,
Ташлап китәр мине. Куркам...

**26**

Сиңа:
– Якын килмә!
Янган утларымны сүндерерсең,
Ялгыш
Саксыз тия күрмә!
Якын килмә, миннән еракта бул.
Кочагымда түгел, булсаң, йөрәктә бул!
Миңа кирәк яшерен яну, сагыну-утлар;
Юкса куркам: давыл тынар,
Хис-хәрәкәт бетеп туктар.
Якын килмә! – дидем.

Юк, ышанма!
Бу ясалма сүзләрне мин
Сине югалттым дип өзгәләнгән көндә
Үз-үземне алдау өчен әйткән идем...

**27**

Күңел диңгезендә кораб күрсәң,
гаҗәпләнмә:
Мин җибәрдем аны...
Фонаремда
Сигнал утлар янар төн буена.
Ярдәм көтеп синнән,
Мин кабыздым, мин күтәрдем аны...

Төнге диңгездә мин:
Килүеңне көтәм.

Берәм-берәм сүнде утлар, дулкын югач,
Инде хәзер мин яндырам йолдызларны;
Соңгы йолдыз! Күкрәгемнән суырып алып,
Баш очыма мин кабызам аны...

Соңгы сигнал,
Күрүеңне көтәм...

Иртән
Дулкыннарда йөзгән җилкән күрсәң,
Бел син
(Җилкән түгел, минем сынган горурлык ул!),
Дулкын басылсын дип, төнлә мин ташладым
аны, –
Кистем дә мачтаны!
Шушы төндә дөнья яңа җыр ишетте, –
Минем җыр ул,
Кораб баткач, мин башладым аны...

Менә ул җыр!
Дәвам итүеңне көтәм.

**28**

Синең белән очрашудан куркам.

Яраларым төзәлгәндә генә,
Онытырга тырышып, йөрәгемә
Ялганларга өйрәнгәндә генә,
Сине күрермен дә – барысы кире кайтыр.
Горурлыгын җуеп,
Башым тагын тезләреңә ятар.

Газапларым артыр.

Синең белән очрашудан куркам.
Ләкин үзем иртән-кичен
Син үтә торган төшләрдә
Һәр көн йөрим,
Югалмаган нәрсәмне эзлим.

Ә, юк, нигә ялган сөйлим! –
Мин бит
Синең белән
Кабат очрашудан куркам!

**29**

Кешеләргә әүвәл икмәк кирәк...
Ә мин – кыргый җимеш,
    ни хәл итмәк кирәк.
Җимеш тансык өчен генә, имеш.
Мин дә синең килүеңне көтәм:
    кагыл, җитеш!..
Үзем кып-кызыл мин оялудан,
Өлгерүемне тоюдан.
Син өзмәсәң, беркөн үзем өзелермен –
Әйе, җиргә төшәрмен мин.
Эндәшермен тагын сиңа:
– Әйе, мин икмәк түгелмен,
Сиңа бик кирәк түгел мин.
Тик онытма:
    иген үсми торган җирдә
Бик кадерле, бәлки, мин дә?!

**30**

Дустым!
Синнән тора барсы – миңа үзгәрергә куш син!
Шундый халәт миндә: һични белмим хәзер,
Көнме, төнме... таң атамы – күрмим хәзер.
Мин ишетмим урманнарда кошлар җырын,
Йолдызларга хәтта җанда тапмыйм урын.
Ә соң диңгез? Тыңлап туймаган җыр –
Диңгез?!
Яшим ничә айлар ансыз – дулкын, җилсез.
Вакыт агышы, табигать, җир, шатлык-кайгы,
Бәхет нәрсә? Мин оныттым, ахры, аны!
Укый башлап, ташлаганмын – күр, китаплар...
Ачылмаган килеш ята күпме хатлар!
Шундый хәлем. Йә, әйт, мин сәерме, дустым?!
...Ә бит
Барсын онытып сөяргә үзең куштың!

**31**

*(Кырыс әкият)*

– Диңгез ярының сылу кызы!
Бик кыенмы көтү аны –
Күптән офыкка күмелгән
Ал җилкәнле ак корабны?
Җилләр нигә китермиләр
Ерак киткән якын ярны?
Мәңге көтәрсеңме аны?

– Капитан, тозлы җил дусы,
Кая илтте синең юлың –
Кайда күмде эзең дулкын?
Кайт син монда, ярың янына:
Зур сөюең исән кайтсын,
Кыз күңеле – ясмин гөле –
Тагын күкрәп чәчәк атсын! –
Капитан, әй, ишет, кайт син!

– Диңгез ярының горур кызы!
Әйтче, ярда ни эзлисең?
Көтәсеңме күк дулкыннар
Гәрәбәдәй чыгарыр дип
Асыл бәхетеңне синең?!
Офыкта тик болыт бүген,
Ә алдыңда – гади ташлар.
Кара, ничек ялтыраткан
Аларны су, вакыт, яшьләр...

– Капитан, бәхет эзләүчем!
Кайчан күренер офыкта
Синең шатлык әләмнәрең?
Нигә җил тантана итә?
Авыр, юеш җәтмәләрең:
Бирми язмыш гәүһәрләрен,
Бәхет калган туган җирдә.
Ярың көткән ярга кайт син!
Соры ташлар чәчәк атсын...

...Вакыт үтә, яшь кыз көтә.
Гыйбрәт алыргамы безгә?! –
Җиңел килми бәхет хәтта
Әкият булып әкияттә!..

**32**

Иске пычак!
Үтмәс түгел һаман да син,
Син җанны җәрәхәтлисең:
Тәкәбберлек – синең исем!
Кем калдырган сине аңа,
Беркатлы ул кыз балага,
Кем калдырган мирас итеп?!

Иске пычак! Ә кем сине –
Шундый ук, һаман үткенне
Калдырган миңа?!
Кыю ир булсын дип мине,
Рухым-дәртемне яндырган, –
Кем калдырган?
Горурлыкмы синең исем?!

Иске пычак...
Ә нигә мин калтырандым,
Нигә әле
Кыз каршында сүзсез калдым?
Торам – тавыш-тынсыз сымак.
Әй, кайда син, кыюлыгым –
мирас пычак?!

**33**

Үтенәм синнән:
Яшел урман булчы бүген!
Бөркү миңа (төшлегендә Кояш!),
Фәкать бер мизгелгә генә
Күләгәдә торыр идем...
Балачагым кебек җиләс урман булчы!

Үтенәм, диңгез булсаң иде.
Бу тыйнаксыз йөрәгемне
Яшерер идем дулкыннарда...
Гел тынгысыз зур суларда
Суытыр идем кайнар канны,
Күмелеп күк дулкыннарда!

Булчы бер юл!
Аптыраган минутларда
Урын тапмыйм кайчак җанга –
Үземнән үзем качканда,
Уй чигенә алып чыкчы!
Онытылырлык бер юл булчы!

Бул бүген мин теләгәнчә!
Син шат аваз, көлү тавышы!
Ләкин бүген күз яше бул!
Тозлы бул яки ачы бул!
Күңел савытын барыбер тутыр! –
«Бәхет» сүзен дә әле ахырынача
Әйтә алмаган,
Ләкин инде көеп-янган
Иреннәргә бүген бер тамчы бул!

**34**

Һава ачык... аяз күкләр.
Күңелдә тик язгы хисләр:
Мин яратам сине!

Төш шикелле авыр, тәмле яшь тамчылар
Минем керфектән тамдылар.
Сөю энҗеләре күмде мине!

Кояш ярты юлда гүя туктап калган.
Аңа нәрсә булган?
Мин дә сүзләремне әйталмыйча өнсез торам.
Син күрдеңме, безнең алга
Очып пар күгәрчен төште?!
Иркәләде алар ничек берсен-берсе! –
Бер-беренең томшыгыннан ширбәт эчте.

Шашып, сөюеңне көтә күңел.
Бәхетнең бит кыргый балына да мин
Риза булыр идем!

**35**

Мин бик матур төшләр күрдем.
Өндә бүген
Миңа очрамасаң иде.
(Ягымлы итеп күрдем сине!)

Юк, бүген миңа очрама,
Миннән көлеп сүз башлама...
Миңа төштә Сөю килде,
Сәлам бирде!

Өндә, зинһар, күренмә син,
Кире алырсың бәхетемне,
Берүк җанга үрелмә син!
Тагын аерылу килмәсен:
Мин яр итеп күрдем сине!

**36**

Кичер мине,
Сөюем белән,
Беләм, күп газаплар бирдем сиңа.
Җаныңа кыен була калса,
Мин гаепле моңа:
Китердем мин сиңа кайгы томаннарын
Һәм сагышның сары яфракларын,
Көнләшүнең беренче чәчәкләрен,
Хыялларның аңлашылмасларын –
Мин китердем һәм калдырам сиңа.
Кичер мине, мин гаепле моңа.

Ләкин бүген елап озатып калсаң,
Ә иртәгә шат, бәхетле булсаң,
Чәчләреңнең таҗы белән башкаларга иелсәң,
Гамьсез көлсәң,
Гафу итүең кирәк түгел миңа.

Мин хыянәткә юл күрсәтмәдем сиңа!

**37**

Юллар ерак.
Бәлки, тиз кайталмабыз да,
Вәгъдә бирмә, йөрәк!..
Кыңгыраулар тавышымы зең-зең иткән? –
Күңелдәге тавышы!
Ә нәрсә ул җем-җем иткән? –
Күзләрдәге сагышы!

Аяз иртә, аяз офык.
Үләндә һәм керфектә чык.
Аерылуны сизеп алдан,
Чапкын атлар кешни һаман...

Юллар ерак.
Кайталмассың, вәгъдәләрең нигә кирәк?!
– Юк, вәгъдә бир! Һәм оныта күрмә, йөрәк!

**38**

*(Киткәндә)*

Иреннәрем белән генә түгел,
Бетәр диеп курыккандай,
Кулларым белән кагылам
Хыялдай чиксез бушлыкка –
Урамыгыз һавасына!
Аякларым белән генә түгел,

Гәүдәм белән тотынам бу җиргә мин.
Шашып үбәм һәр үләнен;
Җир аяк астыннан китә,
Җибәрмәскә тырышам аны,
Ә ул һаман читкә шуа –
Урамыгызның туфрагы!

Кочагыма түгел, җаныма алам
Тупылларның нәфислеген,
Яшь яфраклар назын, тавышын –
Алам барсын!

...Нигә үпкә белән карый,
Миңа орынып, тетрәп шаулый
Урамыгыз агачлары?!

**39**

Агыйделдә сагынам мин сине.
Сагышымны башка бирәү белмәсен дип,
Көлмәсен дип,
Йөзем белән суга иелгәнмен,
Дулкыннарга күмелгәнмен.
Дулкын юар, бәлки, күңелемне?

Агыйделдә сагынам мин сине!

Очрашуның кыска мизгелендә
Аерылышу көтмәдем мин,
Хәтта үпкәләмәдем мин.
Иренемә кагылып, салкын тамчы
Шуны исемә төшерә тагы.

Агыйделдә сагынам мин сине!

Бәлки, сагышымны юган дулкын,
Вакыт үткәч, сезнең ярга җиткәч,
Сине танып туктар,
Аягыңа сарылыр сөю белән.
Хәлсезләнеп егылыр ләкин,
Кире кайтмас миңа, беләм!

Агыйделдә сагынам мин сине...

**40**

*(Хыялда киләчәккә карап)*

Мин хыялда синең чәчләреңә –
Дулкын-дулкын аккан шатлыгыңа –
Йокысыз чакларымда
Күпме төн карасын яктым.
Күк яулыгы белән яптым...
Еллар үткәч, үз чәчемдә менә
(Шул төннәрнең истәлеге!)
Күпме ак йолдызлар таптым.

Мин, сүзләрем белән җаныңа кагылып,
Синдә, ахры, ут кабыздым,
Кыргый хыял көчем белән
Гомерлек ялкын калдырдым.

Күпме еллар сиңа карап торам:

Матур ялкын төсе.
Әмма һаман – яхшы белеп яшим! –
Сиңа түгел, әйе, миңа эссе!

**41**

*(Тагын кайтып килгәч. 1972. Эпилог)*

Нәрсә әйтим баш бирмәгән ярсу
Тулпар атларыма?!
Тагын кайтам менә Уразмәткә,
Мөслим якларына.
Оныттырып дөньям, гамь-шөгылем,
Җан канатым шул ат,
Нигә һаман шунда каера әле
Ярсып, шашып, дулап?
Нигә анда кайту? Хәзер миндә
Башка мәшәкатьләр.
...Улыма булсын хәзер ярсу атлар,
Шашкын мәхәббәтләр.
Кичтем күптән хис-моң Рубиконын,
Нәрсә кирәк тагы?
(Инде ыргып үталмассың, Ыкның
Ташып аккан чагы!)

Анда – хыял кызы... Күңелемдә
Элеккечә калсын!
Ул кабызган йолдыз яна һаман,
Элеккечә янсын.

Нигә карау хыял аръягына,
Үткән кире кайтмас.
Үткәннәрнең урамы тын, йоклый
Йортлар – күзен ачмас...

Тик ни әйтим тыңламыйча чапкан
Тойгы атларыма?
Тагын кайттым (ничәнче кат!) языма –
Мөслим якларына!

# ***III. «Уел»га юл***

## ***(1965–1971)***

* * *

*(Әниләр күңеленнән нурлар)*

– Нарасый Кояш!
Син дә бала кебек гамьсез.
Онытылып, күгеңнән ычкына күрмә!

– Сабыйлар, йолдызлар...
Мөгаен, әниләре үгидер –
Көндез уенга җибәрмидер,
Ул йоклагач кына, качып чыгып,
Төнлә уйныйлар.

– И газиз Җир!
Син дә буй кызларга охшаш ласа:

Матурайган, үскән саен борчуың да арта.

– Гомер юлы, диләр,
Чәч коелган саен ул кыскара.
Үз гомерен, димәк, яшәп бетми Кеше?! –
Үлгәндә дә
Күпме чәче башта кала!

– Дөнья, бик зур гаилә син!
Бертуганнар булсалар да,
Төрле-төрле оланнар да.
Һаман бәхәс... Ходаем!
Татулыкка ни җитә соң?!

* * *

*(Аның хатыннан)*

Сездә көннәр шулай матур булса, абый,
Бездә – көнгә әйләнәчәк кояшлы иртә.

Йолдыз, аегыз турында күп ишеттек, –
Төн күге зур, бар кешегә дә ул җитә!

Тупылларым шаулый, дисез, сокланасыз, –
Безнең урамда да шул ук җилләр исә.

Зур сер шикелле саклыйсыз «сөю» сүзен,
Ә белмисез:
Безнең толымнар да инде билгә җитә!

Күрегез, нинди матур, кояшлы иртә...

* * *

Әтиемне юксынам.
Еллар үткән саен әнкәемнең чәчләрендә
Ак бөртекләр артуын күргәндә,
Йөземне аларга яшергәндә,
Әтиемне юксынам.

Җир ак чәчәкләргә күмелгәндә,
Баш өстендә ак болыт йөзгәндә,
Яңагыма кунып кар эрегәндә –
Ак фонда ул калкып чыга сыман.
Үткәнемдә, бүгенгедә,
Киләчәгемдә – ул балкып тора сыман.

Кояшта, бәлки, аның көлүе чагыла,
Йолдызларда аның карашыдыр;
Төсе итеп ал таңга табынам:
Яшел җирне саклап, кара җирдә калган
Әтиемне сагынам.

Изге агач – тынычлыкның тамыры тирәнрәк китә,
Мәңгелек гөл – шатлык һаман күбрәк үсә:
Тормыш матур, тулы бер җыр сыман...
Бер яфракны эзлим,
Бер чәчәкне күрмим,

Бер аһәңне тапмыйм, ул юк сыман.

Мине бер тапкыр да күрә алмаган
Әтиемне мин –
Тиздән инде аның яшьтәше – улы –
Сагынам һаман һәм юксынам...

## КЫЗ СУРӘТЕ

Менә баш очыннан җиңел болыт үтте.
Күзләр тирән ачылып китте:
Иренгә бер тамчы яңгыр,
Керфекләргә кояш төште.

Җил оялтты –
Күлмәген тарткандай итте.
Керфекләрдә яшь күренде, аннан кипте.

Күрше малай аңа карап авызын ачкан:
Нишләгән кыз? –
Чиләгендәге су агып бетте.
Чишмәнең дә түземе бетте.

Толымын тешләп, һаман уйда утыра кыз,
Чәчәкләре сусаганны оныткан ул.
Пышылдый тик:
– Бәхетме бу? Вакыт җитте.
...Нидер килде. Нидер үтте.

* * *

Әгәр китә калсаң, ничек булыр
Йөрәк атлы иптәшнең хәле?!
Син йөрәккә исәнләшми килдең,
Саубуллашмый китмәссең әле?!

*Беренче дәфтәрләрдән*

Син йөрәккә минем кинәт кердең:
Исәнләшми кердең.
Болытлы көн идем – аяз булдым,
Моңсу идем – көлдем.

Син йөрәккә атылып килеп кердең,
Гамьсез, юньсез идем.
Хәзер дөнья белән тулы йөрәк,
Хисем диңгез минем.

Син йөрәккә көтмәгәндә килдең,
Хәерлегә булсын!
Кунак булып килдең, инде үтенәм:
Аңа хуҗа бул син.

Син йөрәккә исәнләшми кердең,
Нәрсә әйтим моңа?!
Исәнләшми килдең, әгәр китәр булсаң –
Саубуллашып торма!

* * *

«Мин» дип, бәлки, күбрәк сөйлибез...
Тик
Үзен дә бит аңлатырга тиеш Кеше!
Үзе ышанырлык көчен тоеп,
Җиргә
Тавышын яңгыратырга тиеш Кеше.
«Мин!» диденме – Кояш белән тиң бул.
Карашыңда диңгез йөртсәң,
Үрелеп йолдыз тотсаң,
Сабантуйда, авыр юлда,
Дошманнарга каршы җырда,
Хаклык өчен дауда,
Халкың өчен яуда
Җиңеп чыксаң, «Мин» бул!

«Мин» дип, бәлки, күбрәк сөйлибез,
Тик
Тагын әйтәм: көчле булсын, көчен
Кешеләр өчен җигә белсен Кеше.
Хәтта
Мин-минлеккә каршы көрәштә дә
Горур, тыныч –
Хаклы «Мин»е белән җиңсен Кеше!

## ГАДИЛӘР

Мин – бер гади кеше:
Гади эшем,
Гади эчем-тышым, бар торышым.
Дусларым да үзем төслеләр:
Гади кешеләр.

Гадибез, гашыйкбыз
Катлаулы дөньяга.
Эшлибез, яшибез... әйтмибез:
– Кирәкме без аңа –
Төсләргә ансыз да
Мәңге бай дөньяга?!

Бик гади яшибез,
Бик гади үләрбез.
Кем белә,
Сез, бездән калганнар, сөйләрсез:

– Бу гаҗәп сөйкемле,
Күптөсле дөньяның
Кайсыдыр бер төше –
Мең дә беренче төсе
Тоныклана төсле! – диярсез.

* * *

– Елавыңны күргәнем юк, дисең...
Ә нигә еларга миңа?!

Кояшлы көндә яңгыр сирәк ява...
Елгалар да башланганда
Чишмә булып челтерәп ага,

Суы болгана тик соңга таба!

Нигә еларга ди миңа?!
Иртәнге чык – көмеш көлү ошый миңа.

Мин тозлы суны яратмыйм.
Миңамы еларга?! –
Мин – әлегә
Ул көйне белмәгән гитара.
Елак түгел минем җырым! – тыңлап кара.

* * *

Кадерлем, Кояш кызы син,
Гөлләрнең сеңлесе син.
Чәчләрең белән шаярган
Җилләрдәй күңеллесең.
Кадерлем, Кояш кызы син,
Бәхетнең бертуганы.
Шатлыкның нәкъ ай кебеге –
Түгәрәге, тулганы.
Кадерлем, якты уем син,
Мин дә шул Кояш улы;
Сөюем дә шул нурлардан,
Күңел дә – Кояш тулы.
Гөл кебек күз сирпеп килдең
Тормышым юлларына... –
Җәяүләп килгән бәхетем син,
Кушылдың җырларыма.
Язмышым – Кояш кызы син!
Көннәрнең алгысына
Бергәләп чыгыйк: мин риза
Кояшлы язмышыма!

## РӘХМӘТ, ТОРМЫШ!

*Сибгат Хәкимгә*

Күп нәрсәгә өйрәткәнсең, Тормыш:
Җырларга, еларга,
Югалганны эзләргә, табарга,
Табылмаса, чыдарга.
Подлец булырга ләкин өйрәтмәдең.
Мәхәббәткә һәм нәфрәткә дә син өйрәттең,
Битараф булырга, ышанам, өйрәтмәссең.

Әле юлда минем йөрәк;
Сораулар белән тулы күзләр
Озак әле табигатьтән серләр эзләр.
Әле карда, комда озак калыр эзләр.

Тик ышанам:
Ибне Сина ачалмаган хакыйкатьне
Уйга чумып эзләгәндә,
Түземлеккә дә мине син өйрәтерсең.
Инде, «таптым!» дип уйлаганда да
Кыйбламны һәм йолдызымны күчерерсең дә,
Ялгышымны күземә төртеп,
            җанны тагын тетрәтерсең.

Барыбер...
Рәхмәт сиңа, Тормыш!

* * *

Сеңлем!
Толымнарың кисмә, яме?!
Мин, аларны күрсәм, һаман
тотынып, гүя балачакка кайтам:
озын чәчле су кызлары
төшкә керде балачактан.
Беләм, алар һаман да әле озын чәчле!

Толымнарың кисмә!
Күпме истәлекләр яшерә алар:
анда миңа беренче оялчан карашлар,
анда
кояш үбүе, яңгыр биргән назлар,
безнең өчен генә килгән язлар.
Син аларны, зинһар, еракка алып китмә,
толымнарыңны кисмә, яме?!
Кисмә!

* * *

Мин,
диңгездән кайткач, истәлеккә
малайларга кабырчыклар бирдем,
яраттылар бүләгемне минем:
–Диңгез кабырчыгы, бәлки,
бәхет ярчыгы ул?
– Юк, минемчә, кабырчыклар
диңгезнең күз-колагы алар:
яр шау-шуын, җир хәбәрен
дулкыннарга тапшыралар.

– Ә кем белә, бәлки, алар,
диңгез йөрәге ярсынып,
ачуданмы, сөюдәнме –
бер-бер хистән яралганнар?..

Без сөйләштек.
Диңгез кабырчыклары тик
(әйтерсең лә
мин яраткан сылу кызның
һаман горур күз яшьләре)
сүзсез калды, серен эчкә йотты һаман,
эндәшмәде.

* * *

*Көньякка киткән кызга*

Сочи матурлыгын син сөйләмә миңа!..
Платаннар янында төшкән рәсемеңне күрдем:
Күзләреңдә каеннарның шәүләсе бит? –
Сиздем...
Сагынгансың кебек.

Әйдә, уйда
үзебезнең урманнарда йөреп килик?!

Диңгез табигате турында еш язма миңа!
Никадәрле соклансаң да, чәчләреңне
Ык сулары үстергәнен онытма, яме?!
Чинарларга гашыйк булып,
Хәтерен калдырма талларның,
Көнләшмәсен, боекмасын Ык гөләбе!

Көньякларга мине син чакырма,
Андагы бәхетең турында язма:
Монда көннәремә куш син
Алтын әфлисуннар төсен –
Карашыңа көньяк җылылыгын ал да
Ашыгып кайт син – туган якта
Быел гөлләр, бәлки, иртә чәчәк атар?!

Диңгез матурлыгын
миңа язма хатта!

* * *

...Әй ул кичтә! –
Һаман истә:
Зур күзләрең, тирән ачылып,
Ялтыраган иде гүя йолдыз булып.
Әйткән идең шул бәхетле кичтә:
– Кешенең башы әйләнгәндә,
Аннан фикер сорыйлармы?
Бәлки... бүген хис тә җитә?! –
Дигән идең син ул кичтә.
Истә...

* * *

Нинди матур син, әй, хыял!
Синнән башка
яфрак ярмас иде кебек агач;
баш калкытмас иде һәрбер язда
терелеп умырзая...

Җилләр исмәс иде гаваньнарда,
күптән баткан корабларны көтеп;
күз талдырып, юл чатында
кызлар көтмәс иде,
өметләрдән чәчәк тотып:
төрле чәчәк – зәңгәр, ак, ал...
Нинди матур син, әй, хыял!
Әгәр буш булмасаң,
чынга ашсаң...

* * *

Чәчләреңне синең юган
Яңгыр түгел, шатлыктыр дим;
Кем дип белмим эндәшергә,
Исемең синең Бәхеттер дим.

Бар булганың – бәхет инде:
Кашлар-күзләр, ирен-тешләр,
Нур белән кушылган түсләр;
Бәхет түсе, бәхет исе!

Менә нинди икән бәхет! –
Кулы белән кагылып китсә,
Мин фәкыйрьне адәм итсә,
Нәрсә әйтим, күптән вакыт!..

Карап торам... бу ни кызык!
– Әнием! – дип дәште сиңа –
Мин сокланган зур Бәхеткә –
Мисле чәчәк матур кызый.

Моңнар, гамьнәр баласы мин;
Мин – хыялда... – Бәхетнең дә
Була икән димен кызы.
Сокландыргыч икегез дә...
Кичерегез, алиһәләр,
Каты булса хыял күзе!

* * *

Син хаклы! Әйе, мин бала,
Ләкин бер сәер бала;
Тынгысыз уй-җаным, янда
Син булсаң, тынып кала...

Иң «изге» ялганнарыңны,
Ышанып, исем китеп,
Әй тыңлыйм еллар буена
Мөкатдәс чынлык итеп.

Бар нәрсәм – ай да кояш тик,
Ал да гөл – дөньям үзе;
Тик бәхет бирергә генә
Яралган кызлар йөзе.

Кайчак син көләсең шашып,
Тешләрең энҗе була;
Мин, юләр, елыйм, күзләрдән
Гүя йолдыз коела.

Әйе, син хаклы, бала мин,
Тик шунсы аның бәла:
Бу бала – сине сөюдән
Чәчен агарткан бала...

* * *

Мин сагыну фәнен беләм.
Яшь җаныма аның белән
Очрашырга туры килгән!

Мин юксыну фәнен беләм.
Кем җырлап, кем күз яшь белән,

Кем вәгъдә, ант, киңәш белән
Мине юлга озатып калган.

...Сүзсез генә яратканнар,
Яшьсез генә аңлашканнар,
Тын сөюләр, хатирәләр,
Тын бәхетләр истә һаман.

Мин онытмау фәнен беләм!

* * *

*(Авырганда Тукай рухы белән сөйләшү)*

Авыру чагым – авыр чагым,
Тән гүя таштай авыр:
Җан исә мәңгелек юлын
Мең үткән кебек арыр...

Авыру чагым – уйда җаным,
Акыл сау, фикер – кылыч;
Салмак уй айкый җиһанны,
Давыл юк, диңгез тыныч...

Авыру чагым – саф, моң җаным
Юам тик пакь хистә мин:
Рух – горур, соңгы юлга дим –
Мәңге керсез йолдызларга –
Кер, тап алып китмәмен!

* * *

*(Сөйләшү)*

– Гадисең дип уйламаган идем сине...
– Әйе шул, мин
        Ювелир кулы тигән бер
Нәфис бриллиант түгелмендер...
Мин – һәрчак шат, ирекле җил.
Ә җил нинди? Гади лә ул!

– Уйчан дип тә уйламаган идем сине...
– Әйе, су өстенә тик бер мәлгә
Калыккан бер балык түгелмен лә...
Бәлки, үзгәрүчән дулкындыр мин?
Ә дулкынның җыры берме?!

– Шулай да син
Уйда башкачарак идең...

– Ул чакта син, бәлки, сөйми идең?
Мәхәббәтнең күз-керфекләре гел ачык:
Гаҗәпмени, төс үзгәртсә дөньяң синең?!

* * *

Очрашасы иде...

Арабызда яткан ераклыклар томанына
Үч итеп, бер очрашасы иде,
Югалган дип уйланган,
Юлы бүленеп торган
Шатлыклар чыгында
Керфекләрне чылатасы иде! –
Очрашасы иде!

Бәхетнең тик автобуста килгән,
Баскычлардан йөгереп менгән,
Ишекләрдән кергән,
Ситсы күлмәкле
Гади кызын очратасы иде:
Таңнар атканда,
Кояш батканда,
Йолдыз калыкканда...
Очрашасы иде!

Ялгыз калган тупылларны җанландырып,
Тын ярларны шатландырып,
Җилләр белән куышып,
Җирне яңгыратасы иде.
Пәрдә япкан тәрәзләрне оялтасы иде.

Кемнәргәдер үч итеп,
Кемнәргәдер үз итеп,
Гайбәтләргә туры карый алган
Күзләреңне очратасы иде:
Очрашмау дигән сүзнең
Үзен дә онытырлык итеп,
Очрашасы, тизрәк очрашасы иде!

* * *

*Хыялдагы сурәткә.*
*Кемгәдер багышлап түгел.*

Буй-буй кофта... зәңгәр күлмәк...
Бантиклы чәч, зәңгәр күзләр.
Кыз биеми, гүя йөзә.
«Сез кем?» – дидем мин.
«Лениза!»

Өянкеләр сакка баскан,
Инеш буен томан япкан.
Яр сукмагы тарын тар да,
Серле дөнья ул яшь парга...
Көн дә кичен икәү уза:
Берсе – мин, берсе – Лениза!

Бантиклы чәч, зәңгәр күзләр...
Кабынып әйттең үпкә сүзләр.
Без аерылдык. Яшьлек уза.
Сине сагынам мин, Лениза!

Бу – истәлек кенә түгел.
Бу – язмышлар турында җыр.
Йә ялгышлар турындадыр.
(Ә ялгышны төзәтү авыр!)
Ни булса да,
Онытылмаска туган бу җыр!

Син ерак та түгелсеңдер,
Минем юлдан йөрисеңдер;
Очрашырбыз, күңел сизә:
Бантиклы чәчең үскәндер,
Зәңгәр күз ачыла төшкәндер, –
Бәлки, йөзеңдә моң йөзә.
Танымасам. «Син кем?» – дисәм,
Элеккечә әйт:
«Ле-ни-за!»

* * *

Үземә дә сиздермичә,
Үземә кайтып барам.

*Р.Идиятуллин*

Кайларда йөрмәдем,
Кайларга бакмадым;
Алымы-гөлеме,
Аз түгел тапканым.

Кайларга кермәдем,
Нәрсәләр күрмәдем;
Ачылды йөзләрем,
Ярылды эзләрем.

Дөньяның һәр көне
Ал түгел, гөл түгел;
Аңладым, юандым:
Түземле бул, күңел!

Карадым дусларга,
Карадым күзләргә;
Киңәшләр бер булды:
– Эзләргә, эзләргә!

Булганны бүлештем,
Тапканны өләштем;
Акыллы кешедән
Күп вакыт көнләштем.

Күгемә, җиремә
Әле аз бакмамын.
Эзләрмен... Табармын!

...Үземә, ахрысы,
Әле тиз кайтмамын.

**БУ ХИССИЯТ...**

Кем әйтер сиңа? Нидән ул
Җанда ялкын – хиссият?! –
...Бер мизгел, диярсең, Кешем,
Бәлки, бу чын шигърият?!

Исәнме Тукай-пәйгамбәр
Калдырган өмет уты?! –
...Ә ятмы Дәрдемәнд аһәңе
Безгә йә Рәми бунты?

Алламы йә Газазилме
Бирде сиңа көч-куәт?!
Бөек халкыңның исеменә

Лаекмы синең хезмәт?

Вөжданы санап шагыйрен,
Ни табар синдә илең?
Шат итәрме яшь бер углан
Әнкәсен, аннан җирен?

Мәхәббәт, нәфрәткә калыр
Ни үрнәк синнән, ни ат?
Антка тик тамчы хыянәт,
Нәслеңә мең-мең нәләт!

Еракмы сабый чагыңнан
Җан тарткан Тукай уты?!
Һәм чорга Дәрдемәнд аһәңе
Ярыймы? Рәми бунты?

Хиссият... юктан түгел, син –
Илаһият, хөррият!
Кешем, хакмы юлың, әйт!
Пыскып януданмы гыйбрәт
Йә тоташ ут-шигърият?!
* * *

Гомер бакый булган – ышанганнар,
Булган алданганнар...
Хыял, чынлык, дуслар, яшәү-язмыш –
Күп чак алдаганнар.
Күпләр алданганнар.

Әй, яшәсен алар! –
Бер кайгыдан коелып төшкән,
Максаттан ваз кичкән,
Язмыш ачысын, күнеп, эчкән
Көчсез кешеләр түгел! –
Бәлки, алар –
Үзсүзлеләр, йөрәклеләр,
Көчлеләр дип ат алганнар,
Һиндстанны эзләп чыгып,
Америка ача алганнар;
Тынгысызлар, оптимистлар,
Бер түгел, мең кат алданып,
Мең дә беренче очракка
Барырга көч табалганнар!

Уйлан, каләм: нигә әле
Элек шундый кешеләр генә
Шагыйрь дигән ат алганнар?!

* * *

Сөйлә!
Бик күптәннән тавышың ишетмәдем.
Шундый тансык миңа!

Колак салыйм шатлыкларың чишмәсенә,
нинди көчләр шулай күчкән сиңа?
Мин бәхетле, тыңлыйм озак... Сөйлә!

Сөйлә серләреңне, яшь җаныңда

нинди хыяллар бар, сөйлә!
Чәч тузгытып җилдә, очынып көлә-көлә,
яшьлегеңнең назлы көен көйлә!

Язгы яңгыр кебек җылы сүзең –
чыланырга ризамын мин.
Кояш та әнә чыгып килә,
сөйлә!

Сөйлә миңа имин юллар юрап,
кайтыйм синең янга тиз үк урап,
телә: кайгы миннән йөрсен ерак,
җил чәчмәсен җырларымны урлап.
Ә син сөйлә,
арыганчы сөйлә...
Мин киткәч тә, бергә чакны сагынып сөйлә.
Мин кайткач та,
күпләр кебек:
«Соңлап кайттың», – димә.
Шатлыгыма тимә!
Онытсаң да мине, сөйлә!

Һичьюгында, шулчак
кемне
ничек сөюеңне сөйлә!

**КЫЗ ҺӘМ ЧИЯЛӘР**

Шау чәчәктә бакчам:
Ап-ак чия,
Алмагачы,
Чия, шомырт ап-ак, чияләр...
«Нигә һаман чия», – диярләрме?
Нәрсә әйтим?
Әллә нигә өзелеп
Яратам шул чияләрне!

Язлар матурлыгын,
Син булмасаң,
Ятлар миңа әллә сөйләрләрме? –
Синең сөюең белән ачылдым бер,
Чия чәчәгедәй – җаным,
Сердәш иттем чияләрне!

Киткән юлларыңа берәм-берәм
Агачларым чәчәк сибәрләрме?
Чиям,
Минем кебек,
Иртән чәчәк-яшен койды,
Сагышын яшерде аннан, тынды...
Син дә ярат,
Аңла чияләрне!

Эсседәнме,
Әллә юксынудан
Туган моңнарымны сизәләрме? –
Кызардылар бакча җимешләре...
Ә иң элек – чияләр:
«Авыр булса да көт,
　　　сагын», – дияләрме?
Ышан:
Сөям, көтәм,

Бик сагынам сине
Һәм... яратам чияләрне!

**КЫЗ ХӘТЕРЕ**

Ядәчтә отылырга
Теләмим һич синнән,
Күрәмме мин сине,
Гел искә төшерәм:
– Исемдә, исемдә! –
Димичә бернәрсә
Алмыймын мин синнән.

Иртән дә исемдә
(Хәтерсез кыз булмас!),
Кичен дә исемдә
(Керәсең төшемә).
Уенмы, чынмы ул –
Онытырга ярамый,
Отылырга ярамый;
Ничек тә әйтермен:
– Исемдә, исемдә!

Аралар да ерак,
Һәм үтте күп еллар.
Мин һаман онытмыйм,
Син минем исемдә.
Кайтсаң син авылга,
Очрашсак бер көннең
Таңы йә кичендә,
Күрешеп, мин сиңа
Кулларым сузармын...
Әйтерсең, бәлки, син:
– Исемдә... исемдә!

**ЛИРИК АЛЛИТЕРАЦИЯ**

Җил, исмә! Исмә, җил,
Каенга кагылма.
Караңгы каеннар,
Каеннар кайгыда.

Каеннар катында
Калгандыр эзләре.
Калгандыр каенга
Эленеп сүзләре.

Эземе, сүземе,
Калгандыр кайсысы –
Бары да кадерле!
Калгандыр кайгысы –
Аерылу кайгысы!

Җил, исмә... исмә, җил! –
Каенга кагылма.
Шушында бары да:
Эзләр дә, сүзләр дә,
Иң авыр кайгым да.

Кагылма каенга –

Кагылма
Кадерле кайгыма!

* * *

Мин таныдым аны:
Хризантемаларның
Таҗ яфрагын
Өзә нәфис куллар.
Хәрәкәте таныш –
Аз гына калтырыйлар
Нервлы бу куллар.

Миңа чәчәк сузмадылар,
Хәтта
Ак юл теләмәде шулар.

Бүген
Танытмаска теләде ул,
Уйлагандыр: «Елар...»
Ә мин тыныч.
Ләкин шундый истә икән
Мине читкә эткән
нәфис куллар!

* * *

Мин бер малай, ә ул буй кыз иде...
Үртәп көлде миннән, елатты.
Соңыннан җиләк биреп юатты.
Малай идем, ә ул зур кыз иде.

Жыр язмышы шуннан башлангандыр:
Ярның булган яры – үз тиңе.
Һәм күңелнең минем тап-миңе
Шуннан, бәлки? – Шагыйрь башлангандыр...

Шул чактагы ачы, тәмле яшем
Мәңгегә кипмичә калдымы?
Шатлык идеме соң, кайгымы
Җиләк тәме катыш ачы яшем?

Мин бер малай, ә ул буй кыз иде...

* * *

Гаҗәп соң син, тормыш!
Гел үзгәреп тормыш:
кемдер егылып калмыш,
ә кем алга бармыш;
берәүләргә – булмыш,
берәүләргә – юкмыш.
Күп төстә син, тормыш!

Әмма сиңа хисем
һич тә кимемәстер –
гәрчә белеп торам:
күп эшемә рухың

бәхиллек бирмәстер!
Тик Кояш, икмәктер:
үз теләгем белән
җаным сине мәңге
ташлап китмәстер! –
Сүзем – ихластыр!

## ТИК БЕР АДЫМ...

Тик бер адым гына, диләр,
Түбәннән – биеккә,
Гадидән – бөеккә.

Тик бер адым, әмма нинди адым?!
Кемнәр көче җитеп атлый алыр?
Алыплармы?
Наполеонмы йә Байронмы?
Кем булса да, барыбер авыр.

Куркыныч юл, урталык юк:
Йә китә баш,
Яки кәтә әкият кызы,
Алпамшаның
        күңел кошы ул, Сандугач.

...Ә бит нәкъ шул бер адым тик
Һәм кирегә:
Биектән – түбәнгә, бөектән – көлкегә!
Тик бер адым.
Арабызда кемнәр кемне
Бу адымнан саклый алыр?
Егылганда тотып калыр?
Бу – мәсьәлә. Авыр!

## АДӘМ УЛЫ

Әй, ярату, гомерем таңын
Синме онытылмас иттең?
Җәяү идем – атка мендем,
Җайдак булдым – җәяү киттем...

Җанның газиз җәрәхәте!
Эзең калды күп көннәргә:
Шадра идем. Ә сөйгәнем
Гашыйк икән сипкелләргә.

Еламадым. Ары киттем;
Йөрәк әйтте: – Хуш, әлвидагъ...
Юлга чыктым әнә шулай...
Бәхет юлы икән ерак!

Очрый икән барысы да,
Тәвәккәллек кирәк иргә.
Аңладым мин: Адәм улы
Көрәш өчен туа җиргә.

Көчсезләрдән көлә тарих...
Заман – кызу. Тимерләрне
Кызуында сугар өчен,
Тимерчеләр, син күр әле!

Өйрәтәләр шагыйрьләрне!

Һәм мин риза! Тормыш икән –
Тормышчан шәп җыр да кирәк...
Әмма кызык: онытыла да
Юл башына кайта йөрәк.

Яшьлек, яшьлек! Ул һаман да
Шул мәхәббәт базарында
Кыргый җимеш... Ни дияргә? –
Калган шадра килеш... Ярым
Һаман гашыйк –
Сипкелләргә!
* * *

*(Ә чынлыкта...)*

Киноларда кайчак шундый кадр:
син яраткан бер каһарман менә-менә
ясаячак хәтәр адым.
Кычкырасы килә:
– Саклан, егет! Алда упкын... Алданасың!

Китапларда – кеше бәхете белән
шаяра күк очрак-язмыш.
Әй, белмиләр алда ни көткәнне!
Әйтәсе иде:
– Алай итмә... Саклан, бала,
анда – бәла!
Бел, бу эшең ялгыш!

Җырда – үзенә чит, хаинәне сөя егет!
Харап була! –
Әгәр вакытында киңәш бирсәң,
аңлар, утка кермәс кебек...
Тик фаҗига үсә, котылгысыз...

Бәлки, шунда сәнгать көче? –
Барсын күреп янса да җан,
бездән тормый чишелеш,
ярдәм итү мөмкин түгел!

...Чынлыгында менә куркынычтан
үзең
кемне араладың, гомер?

* * *

– Иртә әле безгә,
яшик әле, үлмик!
Парижларны күрик!

Бер-беребезгә, дуслар,
шулай диешә идек
авырганда, арыганда,
авыр уйдан каңгырганда...
Бер максатлы идек:
– Әй, бирешмик! Парижларны күрик!

Тик һәркемнең үз Парижы!

Шәһәр түгел, түгел әкият җире,
бәлки, асыл нокта безнең, –
Идеал, Максат иле...
Барыннан да элек
җан Парижы, дан Парижы...

Еракмы әле, җитәбезме аңа?
Күрик!
Аңа күптән яздык Сөюнамә,
девиз булган исеме күңелләргә,
көнләшмибез юлы җиңелләрдән –
һаман максат кушкан юлдан йөрик –
Өскә, өскә үрлик!

Күрик күрәчәкне, белик беләчәкне,
юлда каршы алыйк Кояш – киләчәкне, –
берүк иртә үлмик!
Парижларны күрик!

* * *

Яратырга телим:
Күңелемдәге уйлар болытыннан
Явар сөю яңгырлары көтәм.
Инде күптән, әсәрләнеп,
Мин мәхәббәт симфониясе тыңлыйм,
Сонаталар ишетәм:
Җирдән килә моңнар,
Килә күктән.

Җир баласы –
Мин мәхәббәт эзлим.
Леонардо Джокондасы,
Әйтче, мәшһүр елмаюың
Ни аңлата синең?

...Серле кыз карашы
Мине шагыйрь итте,
Кыз тавышы (һәм дәшмәве!)
Моңга әсир итте.
Әкияттә – кыңгырау, аккош тавышын түгел,
Ерактан
Ризык тавышын ишетә алса күңел,
Тормышымда
Сөю җыры мине әйдәп йөртте.

...Яратырга телим:
Һаман
Үләннәргә ятып иркәләнәм,
Елгалардан уема җавап эзлим,
Көн агышын тойган ике күзем белән
Һаман Җирне, комсызланып, иңлим –
Яшим, –
Яратырга телим!
Кайда ахыр нокта?
Кайда бөтен юлларыма хисап?
Бәлки, берчак
Гомер буе эзләгәнем табылыр?

Ә ул
Җавап бирмәс миңа,
        таштай салкын калыр?

Әгәр шулай булса,
Соңгы ярсуымда, бер ыргылып,
Ватар идем ташны
Яки шул ук ташка орыр идем башны...

Әй, кем белгән мәхәббәтнең соңгы көнен?!
Бәлки, кирәк булмас,
Бәлки, көчем җитмәс минем...

Бүген, шашып, һаман
Яратырга телим!

**КИЧ ТУРЫНДА ИРТӘНГЕ УЙ**

Була һәрнәрсәнең яшьлек вакыты,
Яшь күңелнең бары «яшен» вакыты,
Акыл җимешенең яшел вакыты!

Гүя Кеше барысын да белеп туган,
Гүя коеп куйган бөек булган, –
Ул дөньяда Алла итеп сизә үзен,
Көмеш урынына сибә сүзен!

Күңел, яшь бер этәч төсле,
Һәйкәлләргә очып-очып куна;
Шекспирлар белән ярсып бәхәс кыла.
Фәкать үзе генә хаклы кебек,
Нәрсә әйтсә, барысы яхшы кебек,
Ул әй тыныч, горур тора,
Үзе ышана,
Бүтәннәрне ышандыра...

Әй, яшь вакыт! Күперләрне яккан вакыт,
Җимерергә әвәс, күпне ваткан вакыт,
Синме әллә үз-үзеңне тапкан вакыт?!
Ә бит беркөн
Синең өнең басыла, бетә.
Акыл көне,
Үз-үзеңә тәнкыйть көнең җитә.

Хәтер ул көн исәннәрдән гафу сорар,
Үлгәннәрнең ядына җыр багышлар,
Туфрагына яшен кояр,
Чәчәк куяр.

Ә мин нигә бу турыда бүген уйлыйм?
Кич турында иртән сөйлим?
Гөнаһларым артык күптер, бәлки?
Әллә акылга баш ияргә вакыт җитә?

Миңа
Әле иртә бугай... Иртә.

**ШАГЫЙРЬ ЗЫЯ ЯРМӘКИ КАБЕРЕНДӘ**

Ярмәгеңдә түгел, чит җирләрдә
соңгы төяк тапкан икәнсең:
Мәрголәннең таш зияратында
йоклау язган сиңа, күрәсең...

Нинди җилләр исеп китергән дә,
нинди җепләр монда тартканнар?
Дип уйласам, күпләр икән монда –
Урта Азиядә татарлар.

Мәгърифәт һәм белем таратучы
йә кунагы илнең – миһманы,
килгән алар монда дус-тугандай,
җиңгән яуда уртак дошманны.

Бергә яшәү өчен калган күпләр
Нәвои һәм Хәмзә жирендә.
Шагыйрьнең дә гомере узган монда,
монда икән ләса кабере дә.

...Үзбәк җире матурлыгына тик
сөенеп, көләч иде күңелем;
очраттым да сине монда килеп,
моңга талдым әле мин бүген:
туган җирләр сагындырды кинәт!

Юксындыргандыр бит сине дә гел
шул Ярмәкнең тыныч таңнары?
...Анда синең ак каеның шаулый,
«гөрләп тора һәрчак тау яны».

**БЕЗНЕҢ ГАЕП**

Гөрләп торган шат мәҗлесләр тына,
моңсулана кайчак,
һичкем кагылмаган касә, буш урыннар,
сүнгән шәмнәргә күз салсак,
кайтмаска дип киткәннәрне
бермәл искә алсак.

Исән дуслар шатлыгында чагыла
кемнәр күләгәсе?
Югалтулар искә төшә... Сызып,
җан, өзгәләнәсең...

Онытылмаслар алар,
үзең төнгә күмелгәнче,
гомер кояшың баеп...
Авыр уй бар: нигә сакламадык,
бәлки,
егылган ул таеп?..

Гөрләп торган шат мәҗлесләр тына:
сүнгән шәмнәр арту –
синең, минем гаеп.

**КАЛА**

Ялым бетеп, туган җирдән
Калага мин китеп барам.
– Шофер, кауламачы шулай,
Ашыкма.
— Ә кемең кала?!

...Кемем кала? Кала, туган,
Бөтенесе монда кала.

Әнә балачагым гүя
Урман авызында бала –
Кала!
Уйнаклап чаба бер колын,
Арыш – биек, күмелеп бара. –
Кала!

Яварга дип әзерләнеп
Болыт килә... хәзер ява.
Миңа тамчысы да төшмәс. –
Кала!

Печән җыя кызлар әнә,
Җыр җырлыйлар,
Бер шаяны
Миңа, ахры, караш сала.
Алар белән түгелме соң бәхетем минем? –
Кала!

Кала туган туфрак, кара! –
Бәрәкәтле, дымлы, кара,
Ата-бабам тире анда. –
Кала!
Бәлки, юлым биеклеккә,
Хөрмәт, данга таба...
Гомерем буе туган җирем,
Сизәм, җанда бара.
Ә нигә соң елыйсы килә?
Нинди төер кала?!
...Шофер, дустым, яле,
Әйдә, каула! Каула!

**АРЫШ ДУЛКЫНЛАНА**

*Илһам Шакировка*

Казан өстендә бер болыт –
Кала өстендә ак болыт!
Көн кызуы арта бара.
Явар микән?
Яңгыр тели җаным:
Анда –
Авыл басуында –
Игеннәрем яңгыр көтә.
Арыш дулкынлана.

Кала кешесе без, уйда һаман сала;

Һаман
Күздә – яшел арыш төсе,
Арыш исе – җанда.
Нишләсәң дә, уйга килә,
Төшкә керә:
Басуыңда арыш дулкынлана.
Арыш дулкынлана!

Йөгерә-йөгерә, яланаяк,
Басу иңләп узганнар бар.
Яңа пешкән арыш ипиен
Күз алдына китереп,
Авыз суы корыганнар бар.
Балачактан изге җир ризыгын –
Авыл ипиен татып,
Күтәрелгән без – оланнар.
Иген өчен яну бездә – мәңгегә!
Ул хис иске,
Ул гел яңа:
Дәүләт гербында башак күк,
Балкый, яна...

Кырлайдамы,
Сармандамы,
Туган Марсымдамы – әнә
Арыш дулкынлана:
Күңелемә бәреп керә музыкасы;
Модернистик була алмый картинасы! –
Реаль тормыш анда.
...Җырчы суза иң мөкатдәс халык көен.
Сокланалар залда:
– Каян бу кадәрле моңы,
Бу соң кайда үскән бала?

Ә ул беләː
Колагында гомере буе башак җыры,
Йөрәгенә кагылып иген,
Арыш дулкынлана анда.

Арыш дулкынлана...

* * *

Нигә килгән монда? Нәрсә эзли?
Монда бакча, монда гөл иле...
Чәчәкләрне сыйпап, уйланырга
Тукталганмы юлчы Гулливер?
Лилипутлар йә алыплар түгел,
Үз калыбы аның илендә,
Ә ул һаман яңа ярлар күзли,
Маҗаралар – армас күңелендә.

Бер ишетүе бер гомерлек җырлар
Яңгырармы чит-ят җирләрдә?
...Бәхетстаннарда яшәсәң дә,
Күңел бәхете җитми ирләргә.

Чынлык белән болай дус кебек без,
Киләчәккә күзләр төбәлгән,
Дон-Кихоттай, рыцарь заманнарын

Тик романнар укып өйрәнгән
Безнең күңел вакыт-вакыт шулай
Ерак юлга чыга түгелме?

Тормыш белән якынлашкан саен,
Хыял өчен артмый җиңеллек...
Упкын кебек уйлар, күңел тирән,
Диңгездәге җәүһәр – яшьләрең.
Тирәнрәк кергән саен күбрәк
Таба, ахры, асылташларын.
Шулар белән һаман уйный, армый:
Серле әкият төсле һәммәсе.

...Тын яшәргә, эзләнмичә генә
Мүкле таш түгел баш, янәсе.
Шулай кеше гомер буе саклый
Поэзия җирен, гөл илен.

Чәчәкләрне сөеп, серен сөйли,
Мәңгелеккә бара Гулливер –
Шагыйрь күңеле.

**ИДЕЛ-ЙОРТКА ЧАКЫРУ**

*Риммага*

Бездәгечә түгел сездә кояш,
Икенчерәк монда ай нуры;
Өйләр төсе башка, туфрак төсе,
Эсселеге көннең, яңгыры.

Шушы якта туып үскәнсең син;
Ә мин чакырам сине илемә –
Иделемә, арыш кырларына,
Шулар сеңгән минем күңелемә.

Син – розалар, мәк, тюльпаннар дусы,
Юмарт ла ул – гүзәл Гөлстан;
Гөл телләрен өйрәнгәнсең, никтер
Үз телеңне... азрак оныткан.

Ә ул телдә
Илнең гадәт-йолалары, зур тарихы.
Анда
Әнкәйләрнең моңы, җан көе.
Кайтыйк әйдә илгә! –
Улыбызның, бәлки, татарча ачылыр теле.

Шунда килер
Бәхетләрнең безнең җәй, көзе.
«Ә нәрсә ул туган җир көйләре?» –
Шундый сорау укыйм күзеңдә.
Әйдә,
Чакырам сине илемә, Иделемә...
Күр барысын да! Кайт әле син
Көткән җиреңә, туган телеңә,
Халкың күңеленә, моң күленә!..

Әкияттәге үрдәк бәбкәседәй
Кайт әле син, Аккош,
Үзеңә!

**САЛЬЕРИ ТУРЫНДА**

Агу сайлый көчсез Сальери...
*Зөлфәт*

Ә Сальери... түгел элеккечә!
Ул бөтенләй башка,
Баксаң да
Танымассың:
Вакыт-чорга җайлап,
Модный костюм кия шайтан да.

Ул бөтенләй башка: шат чырае,
Сүзе, үзен тотышы, адымы.
Халык, хаклык исеменнән сөйли,
Булу мөмкин хәтта... ордены.

Сәнгатьне ул җаны күреп яклар,
Яңалыкны мактар,
Чаралары булыр яшеренрәк:
Агу бирмәс, дару биреп сиңа,
Дусың булып, әләк әзерләр.

Моцарт өчен түгел, мәнсаб* өчен
Җанны сату күптән чүп нәрсә!
...Әле шайтан, үзе шикләнмичә,
Бизнесына якын җибәрсә...

Төгәл, шома, нәзакәтле, көяз,
Эчеп, йөреп чыкмас иseme;
Картлар сүзен тота, яшьләргә дус,
Карьерага – дошман...
Кем яратмас шундый кешене?!

Һәм кем таныр? Аерым билгесе юк,
Юк сыйфаты – чиста, сак йөри.
Хәтта «Моцарт!» дип үк эндәшерсең...
Бик үзгәргән шайтан, Сальери!

**ҖАННЫҢ КАЙЧАК...**

Кайчак килә тормыш авазларын
Шашынып
Үзеңә иш итәсе!
Килә кайчак анда
Гаҗәп моңнар, өннәр ишетәсе!
Әмма яңгырый көтмәгәндә,
Урам тулып,
Матәм музыкасы...

Сәйдәш, Бах йә Шопен:
Өзелгән дә гомер – иң нечкә кыл,
Бу кайгыдан
Саз кыллары да өзелергә якын!

Әй, дөнья, бер балаң бит мин;
Миңа тормыш җырларының
Барысын да
Җанга үз итәсе...
Нигә авыр миңа бүген?!

Урамымда яңгырый, ишетәм,
Матәм музыкасы.

**ИСКЕ КИТАПКА**
**ЗИМАГОР БАБАЙЛАР ЯЗГАН ҖЫР**

Үткән – ямансу җыр,
Алдагысы – озын юл.
Туган җирләр – без оныткан бакча.
Шул бакчага кайтып егылырга да
Акча җитми, акча...

Нужа белән «дус» без,
Бәхет ләкин ерак.
Килер иде, сулар үргә акса.
Качып йөрмәс иде, әй, бәхет тә,
Акча төшми, акча...

Тимер өзәр чаклар...
Кашка, тимеркүкләр
Кайда икән? Атланыйк бер атка!
Бердәм булыйк, исән-таза булыйк,
Төкер! Янсын акча...

Сөйгәннәр – каракаш,
Гел кайгырмас ла баш,
Куенны – җил, күңелне яр ачса...
Мал мәңгелекмени, ил кулында
Без үзебез – акча!

Киләчәк билгесез,
Хәзергесе – алда,
Үткән гомер – туган җир, гөлбакча.
Кайтасы иде... Юлга үлән үскән,
Үлән нәрсә,
акча кирәк, акча...

## ТӘРҖЕМӘ, ТӘҖРИБӘ

Нәрсә сөйли икән чал тәҗрибә? –
Шатлыкларны, кайгыларны
башка телгә
итеп буламы тәрҗемә?

Тойгыларны, хисне,
шатлык, бәхетләрне,
моң, ядкярне
чыгарабызмы бер-бер илгә?

Әллә сүзләр, җөмлә,
шартлы тәгъбирләрдә тик
китапларны күчерелә
чит бер телгә?..

Сүзлекләргә сыямы Сөю,
Нәфрәт, Ватан?
Телләр белүдә тәҗрибә күп инде.
Әйтегез,
тәрҗемә итәргә мөмкинме Кешене,
аударып буламы күңелне?

* * *

Бер як читтән торып карый алсам

гомер елгасының агышын,
чуерташлар булып калкыр кебек
су читендә һәрбер ялгышым.

Ә елгалар шулай: башланганда
гел ташлардан сикерә түбәнгә,
тик киңәйгәч, зур ярларга кереп,
тыныч ага...

Карыйм көннәргә:
шаулы чагым, җырлы чагым бүген.
(Ялгышлардан әллә җыр туа?!)
Күңелем минем шул халәттән риза,
аны тыныч агым куркыта.

Юк, үкенмәм, яшьлек ялгышыннан
җанга төзәлмәслек яра алсам.
Тик шартым бар: елгам койган җирдә
утырып уйланырга
үземә тик бер таш табалсам;
юк, үкенмәм – бүген яна алсам...
Әгәр бүген матур язалсам!

## ЯШӘҮНЕҢ БЕР МОҢЫ

Колагымда таныш бер моң. Җырмы?
Әллә чылтыр-чылтыр су ага?

...Күптәнме әле чишмә ярында мин
Малай булып бактым дөньяга?!
Җил дә урман, чишмә дә тау гына –
Күзаллаган дөньям алдымда.
Әкиятләр маҗарасы белән
«Ак бүре»ләр йөри янымда.
Әкиятләрдән чынлыкка зур ара...
Ә үскәч мин күпне беләчәк...
Каршылаган һәрбер зәңгәр кичтә
Йолдыз булып кабына киләчәк.

Ә моң ага. Әллә әнкәм тавышы,
Әллә шаулый чишмә – су ага:
– Әткәң юк, – ди. – Таян үзеңә, бала,
Өметеңне багла дөньяга.
Көтүченең чыбыркысы шартлый,
Эшкә өндәп гүя якында.
Алга барсам, рәшә сарган кырлар,
Саклап, урман шаулый артымда.

Әй, чишмәләр, күпме күрдем сезне
Урта сыза, Торна сазында.
Кузгалакмы, җиләк, балтырганмы,
Азык эзләдемме җаныма?

...Ә моң ага. Шуны тыңлый-тыңлый
Имтиханнар бирде йөрәгем:
Авыл, калаларда, чит җирләрдә,
Эштә, мәхәббәттә – чын җырларга
Җилкән булды әрсез теләгем.
Каян бу көч?! Вакыт агышымы?

Яшәү җыры? Чишмә гел ага.
...Бала булып юллар ачкан күзләр
Әти булып бага дөньяга.

Туган туфрагымны кулына ала,
Гүя эзләп кайткан Салават.
– Моңнар тулы күңел, илең булса,
Җирдә килмәс, улым, яманат.
Учлап сулар алам, битең юам,
Юлың башла җирдән, чишмәдән.
Чишмәләре булган сулар гына
Диңгезгәчә агып төшәләр.
Яшәү сере итеп аңла шуны,
Багла күңелең... җырлап су ага.

...Туып, Кеше булып яшә генә,
Моңнар табыла,
Истәлекләр табыла дөньяда.

**«БИШТАШ» УЕНЫ**

Син дә, мин дә – бала,
Сабый әле, бик яшь...
Уен гына уйда,
Уен исеме – «бишташ».
Әй чөелә ташлар!
Әй иелә башлар!
Кызык шундый уен,
Аерылу кыен!
Җитезлегең сыный
Шомарган ак ташлар.
Менә яшьтәш арыр,
Ташы төшә башлар.
Биш ташың – биш якка!
Җыйсын тик биш бармак...
...Ә күңел уенда
Остармак, шомармак.
Син дә, мин дә – үскән,
Күңел – һаман бик яшь.
Югыйсә каян ул
Уеңда – уен... таш.
Әй чөелә ташлар,
Иелә чал башлар.
Безгә түгел дә уен,
Аерылуы кыен.
Күңелдә, күңелдә
Ташларның барысы...
Һәммәсе – тормыштан
Үзебез җыйнаган
Тәҗрибә, ахрысы!
Килегез – күрегез
Ташларым, дус-иптәш!
Сезгә соң танышмы
Тәҗрибә ташлары? –
Биш түгел, бик күп таш...
* * *

Ерак Марс авылы! Башлап
Мин дөньяны күрдем синнән –

Карап
Туган йорт тәрәзәсеннән.
Тәрәзәләр,
Өч малай һәм әнкәй – безгә
Дүрт тәрәзә – дүртебезгә.

– Әнкәй, нигә һаман әле
Тәрәзәгә текәләсең?
Ни күрәсең?
Нигә һаман-һаман күзең яшьле синең?
...Үскәч белдек, еллар буе
Ерак юлга карап көткән
Кайтуын ул әтиемнең.

– Рәшит! Синең тәрәзә аша
Ни күренә?
Нинди кызык?! Ни тамаша?
...Җәй булса – яшел басулар,
Кышын исә – карлы кырлар.

– Ә син, Рәфит, ни күрәсең?
...Аңа күренә олы урам,
Аннан – урман.
Ә мин карыйм күрше авылга илткән юлга.
Юл чакыра, уйлар сәяхәткә чыга...
– Күрше авылдан соң ул юл, әй, кая илтә?
Юлның ахыры кайда?

Җирдә? Күктә?
Ә абыйлар җавап бирми, дәрес ятлый,
Һаман да бер сүз кабатлый:
– Барлык юллар Римга илтә, Римга илтә.
...Якын Марс авылым!
Туган йортым, туган җирем!
Мин дөньяга сикереп чыктым
Тәрәзәңнән синең.

Кайткан саен,
Тәрәзәмнән торам карап.
Һәм җыенам... инде ераккарак.

Беләм хәзер: барлык юллар Римга китми.
Дөнья ләкин
Җанны кая гына йөртми...
Юлларың да:
Шатлыкларга, кайгыларга,
Хыялга, чынга –
Барысына алып чыга...

Барлык юллар, тормыш, сиңа илтә,
Ә миңа шул җитә!

* * *

Әй, күңелнең көче!
Өстәлеңдә гөлләр сулса бүген,
Күңелеңдә аның таныш исе.
Сөйгән ярлар китсә, мәңгелеккә
Кала

Яд итәргә исеме...

Дуслар китсә – истәлеге,
Шагыйрь китсә – күңел җимешләре,
Шигырьләре.

Килә гөлләр исе...
Хыял көченнәнме,
Истәлекме? Каян
Бу исемнәр, күңел, синдә калган? –
...Фина, Альбиналар... –
Нинди романтика алып килгән
Якты исем алар? –
Инессалар, Ленизалар?!

Кышкы төндә шагыйрь учагында
Атыла зәңгәр йолдыз төркемнәре.
Алып кайта хәтер киткән дусны,
Ярны, шагыйрьләрне;
Искә төшерә калган исемнәре,
Истәлеге, шигырьләре...

Күңелдә ут яна төн буена,
Таныш исле гөлләр дөрли, яна.
...Ялгыз булып кара
Шундый чакта,
Йөрәк, янмый кара!

## УСАЛЛАНА КЕШЕ...

Усаллана кеше. Һәрчак юаш,
Сабый булу – авыр.
Тормыш әниеңнең кулы түгел.
Түгел апа, абый.

Мине, беркатлы, гел ышанучан
«Ыштансыз» бер җанны,
Шактый сабак биреп өйрәттеләр
«Юктан бар булганны»...

Аңладым мин: кемгә ышанмаска
Һәм кемгә ул – ярый.
Нәрсә чынлап тулы, ә нәрсә тик
Буш мичкәдәй яңгырый.

«Күбәләктәй газиз җанга көч» тик,
Кояш кайда да бер.
Нур-һавадан, судан еш исермә,
Инде урыр чакта чәчеп йөрмә –
Яшәү сере шулдыр!

Усаллана кеше. Ачы дөнья
Үзенекен эшләр!
...Мин нарасый, усаллансам була,
Соң,
Ә усаллар нишләр?!

## ЫШАНДЫРЫЙК!

Юлга чыга берәү.
Кемдер фатихасын бирә:
– Диңгезләргә барып чыксын юлы!

Җилкәне нык булсын! Кыюлыкка чик юк,
Ләкин
Юл җиңел булыр дип ышандырмыйк!

Юлга чыга берәү.
Киңәшләр күп:
– Юкны эзләмәскә, барны үстерергә!
– Булган белән генә чикләнмәскә,
Эзләнергә, эчкәрәк керергә!

– Ай, зур юлга, авыр юлга чыга Кеше!
Рухы булсын гел нык! Теләктә булыйк!
Табар ул яңаны,
Ә бәлки – юк...

Ләкин, әйдә,
Юл кирәк диеп ышандырыйк!

Юлга чыга берәү:
Дон-Кихотлар, Одиссейлар юлына.
Эзләүчеләр, утопистлар,
Көрәшчеләр юлына.
– Барысы тормыш юлы! Бар турыга!

Улым башлый гомерен, улым чыга юлга!
Ничек атлар адымнарын? Карап торыйк.
Җиңел булмас, бәлки,
Ләкин артка юл юк.

Йә, әйдәгез:
Яшәү бөеклегенә ышандырыйк аны,
Кешенең көчле булуына ышандырыйк!

**ИСКЕ СҮЗДӘН ЯҢА МӘГЪНӘ**

Иске сүздән яңа мәгънә
Таптымы соң җаным? –
Теләкләрнең хуш килгәнен
Каршылыйм, дип:
– Амин!

Яратам шул иске сүзне,
Бик куана җаным,
Мин дә теләк тели калсам,
Әйтсә дустым:
– Амин!

Бүләк итте гомер миңа
Кабатланмас ямен.
Һәрчак сөеп, гашыйкларча
Яшиемче!
– Амин!

Дошман да бар.
Курыкканым:
Кара уен аның
Сизмичә куймаммы әйтеп,
Ялгышып мин:
– Амин!

Нәрсә әйтим? – гөнаһым күп:
Күп сөйләп, азрак эшлим күк.
Гаебемне таныйм.

Башкалар да танысыннар!
Шуны көтә җаным.
– Амин!

### ҖЫРНЫҢ – ҖИРЕ...

«Кешенең иле булсын! Җырның – җире...
Үксез булмасын җан!
Уйга Ватан булсын», – дигәннәр.

Ә нигә соң шундый мәкаль:
— Һичкем
Үз илендә булмый пәйгамбәр!
Булмый?

Үз җирендә? Өндәүләрең синең
Салкын мыскыл, көлү көтәме?
Кеше үзен аңлаталмый, сүрелә
Яки беркөн читкә китәме?

Эмигрантлар. Ятлар... аерылганнар
Бәхетеннән – җире, халкыннан,
Уйлыйлармы авазлары беркөн
Ишетелер дип диңгез артыннан?

Бәхетсезлек – җырда зимагорлык,
Уйда дезертирлык. Зур хата!
Кешелекнең үзе, илең белән
Бәхетең бәйләү, нәрсә булса да.

Туган туфрагыңнан аерылсаң,
Гомереңнән синең ни мәгънә?!
Илем – ул бар: җырның туган җире;
Ә пәйгамбәр... булмам. Бигайбә!

### ЙОЛДЫЗ ҖИЛЕ

Мин – Марстан. Юк, йолдыздан түгел,
Җирдәге бер матур авылдан.
Әмма миңа барыбер йолдыз җиле,
Йолдыз җене диләр кагылган...

Мин – Марстан, тик марсиян түгел,
Мин – җирский: тузан бер, бала.
Күкләр күптән ачылса да күзгә,
Әлегә китә алмам: Җир кала.
Җир кызлары кала. Сөюем монда,
Монда җирдәй җылы күңелем.
Йолдыз гөлләренең яме күптер,
Миңа тансык монда кыр гөлем.

Җирнең
Һәр куагы, кошы, кешеләре,

Эчкән суым, һава, икмәгем –
Беләм, ныграк яраттырыр өчен
Мине
Күк юлына илче иткәнен.

Ерак планеталар чакырганга,
Күптән җырда йолдыз кабынган.
Юкса кешедә әле – Җир паспорты,
Мин дә Марс дигән авылдан.

Йолдыз җиле,
Йолдыз җене... шунда кагылган.

**КАР АСТЫНДА – ГӨЛЛӘР**

Эретәсе иде туңган җирне,
Терелтәсе иде гөлләрне...
Төшкә керә һаман язгы кояш,
Йокы япкан саен күзләрне.

Яфрак яңгырлары күптән узган,
Карлар күмә үзән җирләрне.
Йокламыйча, сакта тора Хыял,
Гүя уяулыкка дәшә күңелләрне,
Нәфрәт-мәхәббәтне, илләрне, –
Летаргия басар кебек Җирне!

Хыял, әгәр чынлап көчең булса,
Язны чакырып, син бер эндәш инде,
Яланаяк йөгереп, җыйыйк бергә
Карны тишеп чыккан гөлләрне!

* * *

Су астында калган кыйтгам –
Хәтер төбендәге гомерем –
Син югалткан Атлантидам,
Синдә күпме урман, гөлем!
Океаннардан узган чакта
Кошлар туктап торган кебек,
Сәламнәрен биргән кебек,
Эзләп килә күңел сине,
Хәтер төбендәге гомерем!

Океан астындагы гөлләр,
Чыгасыгыз киләме соң
Кояшка, җир дөньясына?
Җирдә шундый матур көннәр...
Ә ни атлы хәтер гөле? –
Роза, тюльпан, канәферме?!
Тын дөньяның күп серләре,
Шунда диңгез йолдызлары,
Хыялга тиң энҗеләре –
Күрә алыр кем күзләре?

Су астында калган кыйтгам –
Хәтер төбендәге гомер,
Сабый чактан калган төшем!

Гаувас кебек, төптә йөри,
Атлантида серен түгел,
Сине эзли минем күңел!

## КАРАБОДАЙ

Хәйран җирне вәйран итеп
Чәчкәннәр карабодай;
...Болдырларына менгәч тә
Борылып карый бугай.

*Әткәйнең сугышка киткәндә*
*җырлаган җыры*

Караган киткән юлыңа,
Караган әнкәй һаман...
Карабодай кырларында
Карашың калган сыман.

Ул кырлар – сезнең яшьлекнең
Чәчкәсен күргән кырлар;
Ә җырлар – сөйгән кырларга
Бәхиллек биргән җырлар...

Булды – яраткан кырларың
Буш торды еллар буе.
Карабодай, бодай кая?!
Булды чүп үлән туе...

Барысын да күрде авылым,
Татыды барысын да.
Чүп үстермәде җанына,
Ышаныч, намусына!..

Утыз ел үткән, утыз ел!
Эх, кайтса, күрсә иде
Кырык бердә калган ирләр
Бүгенге авыл, илен.

...Караган киткән юлыннан
Каерылып әткәй һаман.
Кырларга мәңге яшәргә
Васыятен әйткән сыман
Соңгы җырының моңнары...

Ап-ак кыр. Карабодай...
Зәңгәр күктән аяз көндә
Зәп-зәңгәр күзләре белән
Әткәем карый бугай!

## ТАТАР КИТАБЫ

*Хатип Госманга*

Киштәсендә, хәтерендә илнең
Бабамнарның күпме китабы!
Пергаментлар, кулъязмалар сөйли –
Гасырларның безгә хитабы.

Сөйлә, китап! Болгар чорларыннан,
Тарихыңнан «аять» сөйлә, әйдә:
Телгә килсен Якуб улы Йосыф,
Һәйкәл булып бассын Зөләйха.

Сөйлә:
Фани дөнья сүзен, сөю җырын
Борынгылар ничек үз иткән,
«Мәхәббәтнамә»ләр нигә һаман
Алмаз кашлар – шигъри йөзектә?

Сөйлә, китап! Сәйф Сараилар,
«Гөлстан»нар ничек калганнар?
Янган калалардан исән-имин
Чордан чорга күчеп барганнар?

Казан зират карауччысы түгел,
Бер атаклы улы халыкның,
Мөхәммәдъяр – безнең күңелгә яр,
Ничек чорлар аша калыктың?!

Сөйлә, китап! Нинди хикмәтле җыр –
Мәүла Колый, Утыз Имәни?
Нинди кыйссаларга тап булганбыз
Акмуллалар телен өйрәнеп?

Сөйлә, китап, нинди гамьнәр кичеп,
Төрле илләр үтеп, шулай да
Бирдең алмаз телебез ачкычларын,
Бабамнарның газиз тавышларын
Ишеттердең ничек Тукайга?!

Асыл мираслары заманнарның,
Гасырларның оран-хитабы
Хәтерләрдә булсын!
Сөйлә әйдә
Син, үлемсез халык китабы!
Сөйлә...

* * *

Күр, ап-актан агачларым күптән,
Шау чәчәктә бакчам.
Матурлыгын күреп, аңларсызмы,
Капкаларын ачсам?

Күр, әкияттән күчкән төсле гөлләр,
Чәчәк таҗын ачкан...
Бал кортлары гөжли, күбәләкләр...
Нурда уйный бакчам.

Күр, чишмәләр күпме – вак-вак таштан
Челтерәп, көлеп аккан.
Җыр-авазлар белән тулы һәрчак
Шаулап торган бакчам.

Утызынчы язны каршыладык.
(Шау чәчәктә бакчам!)

Көзгә ерак әле... Җәй, кояшка
Капкаларым ачам.

**ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН**

Яңа ел җитте! Яңа ел!
Кышы, язы, җәе, көзе –
Барсы белән дә яңа ул.

Ә иске ел ерак китте,
Киткән чакта елап китте.

– Ул соң ниләр алып китте
Һәм ниләр калдырып китте?
– Фәндә, көндә яңалыклар,
Яңа бәхет, яңа йортлар,
Көне-төне янган утлар,
Гөлбакчалар, яңа җырлар
Китерде ул, һәрбер көне
Бизәп үтте туган илне –
Ил күгендә мәңге балкыр
Йолдызлар яндырып китте.
Нык сакларга кушып, безгә
Җирне, Кояшны, Дөньяны –
Барсын да калдырып китте...
Үзен генә алып китте.

Яңа ел! Яңа ел җитте!

## салаваткa шигырьләр

**ЗӘҢГӘР ИЛ – БАЛАЧАК ИЛЕ**

Туган илем – илләр иле;
Туган җирем – җирләр җире, –
Бәхет җире, нур җире.
Мәңге яңгырар җыр иле.
Әйдә җырлыйк яңа бер җыр:
– Илемдә бар иң матур ил,
Исеме – Балачак иле.
Ямьле Балачак иле,
Зәңгәр Балачак иле;
Аяз күгең, якты көнең, –
Кем генә белми сине?
Җилләрнең иң-иң җылысы
Исә синдә, зәңгәр илем!
Гөлләрнең дә иң гүзәле
Үсә синдә, бәхет иле –
Хыяллар һәм чынлык җире!
Татулык, Дуслык, Туганлык,
Матурлык, Сафлык, Уңганлык –
Байрагыңда шулар синең,
Зәңгәр күкле Туган илем!
Серләр тулы – утрау түгел,
Әкиятләр күп – тормыш үзе,
Бакча кебек – төрле төсле
Матур ил – Балачак иле!

Бу илдә үткән балачак,
Җыр булып әйдәп барачак:
Ямьле Балачак иле,
Зәңгәр Балачак иле.
Аяз күгең, якты көнең, –
Кем генә белми сине!

**САЛАВАТ АТЛЫ МАЛАЙ**

Салават дигән малай
Бик шаян икән, ай-яй!
Бер урында тик тормас,
«Койрыгын» да тоттырмас
Чикерткә кебек малай...
Чыгармасмы яманат? –
Үсәрме бер Салават?!

Юк, уйламагыз берүк
Ул начар малай диеп;
Ашкына күккә карап,
Ул таза, шат-сәламәт.
Дөнья аңа – тулпар ат,
Ул дөньядан канәгать!

Батыр мәргән шикелле,
Ак болытка угың ат,
Урманда йөр, комда ят,
Йөзеп, дулкыннар тарат –
Тик тору аңарга ят! –
Шундый малай Салават!

Әйбәт малай Салават!
Ул чыгармас яманат:
Тыңлар олылар сүзен,
Танытыр әле үзен.
Хыялдан тормышкача
Юл үтәр, еллар аша
Омтылыр матурлыкка,
Ил кушкан батырлыкка.
...Хәзергә бераз шаян, –
Әйтер әле берзаман:
Үткән эшкә салават,
Дияр безнең Салават!

**ИСЕМЕМ ГӨЛДӘР МИНЕМ**

Тирә-юнем – гөлләр генә,
Дусларым гөлләр минем.
Гөлләргә апа булам мин:
Исемем Гөлдәр минем!

Урманнарда, болыннарда
Өйрәндем гөлләр телен!
Сезнең белән сөйләшеп һич
Туймыйм, сеңелләр, димен.

Сезнең белән бергә җырлыйм,
Әй, Розалар, Миләүшәләр,
Ләйләгөлләр – төн гөлләре,
Нәркис, Сөмбелләр, димен.

Ромашка, Кыңгырау чәчәк,
Сезне, Күгәрчен күзен,
Шигырь сөйләргә чакырам –
Мактарга гөлләр илен.

Гөл илендә кунакта мин,
Сердәшем – гөлләр, димен.
Сезнең белән бергә үсәм,
Исемем Гөлдәр минем!

## *IV. Бөекләр язган хатлардан*
***(1963–1971)***

**Һенрих Һейнедан**

* * *

Һәр иртәдә мин тын йортың
Яныннан узып китәм.
Тәрәзәдә күренсәң син,
Авырмам кебек бүтән...
Кара күзең карашында
Сорау бар әйтелмәгән:
– Кем син? Ни кирәк соң монда
Сиңа, әй, сырхау адәм?!
– Сеңлем! Мин бер шагыйрь, мине
Беләләр үз илемдә.
Шагыйрьләр исемен сана,
Син атарсың мине дә!
Ә сырхавым? Нәкъ Мәҗнүнчә
Авыруы шагыйрьнең дә.
Уйла: тиз табарсың исмен
Минем авыруның да!

* * *

Диңгез ярында мин, кыя ташта,
Ак күбекле дулкын өстендә.
Диңгез шаулый. Акчарлаклар оча,
Һәм җил исә бөтен көченә.
Күп иде бит җирдә дусларым, әй,
Кайда алар, кайда соң хәзер?
Монда дулкын, монда җил тавышы.
Дулкын әйтер, бәлки? Җил әйтер?!

* * *

Күпме гасыр инде мең-мең йолдыз
Яна җиргә карап.
Аларда бит бер-берсенә дә, күр,
Нинди назлы караш!

Сөйләшәләр һаман әкрен генә
Аңлашылмас телдә.
Гаҗәеп бай, серле бу телне соң
Кайсы галим белә?
Һичкем! Җирдә бу телне өйрәнгән

Мин бердәнбер кеше:
Өйрәтте аны миңа ярымның бит
Тиңсез ике күзе!

* * *

Миңа иргә чыга калсаң әгәр,
Дус кызларың шартлар ачудан –
Безнең тормыш тоташ бәйрәм булыр:
Театрлар, күңел ачулар.
Тиргә, җаным кыйна: һич сүз әйтмәм,
Туктатырмын сине мин үбеп –
Тик... шигырьләремне мактамасаң,
Аерылышу безнең көн кебек!

* * *

Хатыгыз белән мине сез
Һич тә хурлый алмадыгыз:
Сөймисез хәзер, аңладым,
Ә ник бер том ялганыгыз?

Тик антлар тулы хатыгыз
Нәкъ алты бит! Әйтү җиңел.
Ташлавыңны аңлатырга
Ул кадәр сүз кирәк түгел!

* * *

Син мине, мин сине башта никтер
Аңлый алмый озак саташтык.
Тик егылгач бергә баткакка, без
Нигәдер бик җиңел аңлаштык.

**Роберт Бернстан**

**ДЖОН АНДЕРСОН, ПЕЛӘШ ДУСТЫМ...**

Джон Андерсон, Джон дустым,
Әле күптәнме, кара,
Чигә чәчең кара иде,
Сумала кебек кара!
Хәзер карлар яуган аңа...
Күп буран күргән чәчең.
Бәхетле бул ләкин, Джон
Андерсон, шат пеләшем!
Джон Андерсон, кайчан гына
Без менә идек тауга? –
Шатландык без югарыда,
Иркенлек табып җанга.
Ә хәзер юл – түбән таба...
Аерылмабыз, ахры, без.
Керик бергә җир куенына,
Джон Андерсон, тугры дус!

* * *

Син мине ташладың, Джеми,
Мине ташладың.
Гомергә ташладың, Джеми,
Әйе, ташладың.

Син шаяртып кына йөрдең,
Бәгърем, алдадың.
Мәңге сөяргә сүз бирдең,
Аннан ташладың, Джеми,
Аннан ташладың.
Без бергә булмабыз, Джеми,
Булмабыз бергә.
Беркайчан да без, Джеми,
Булмабыз бергә.
Тизрәк салсын иде мине
Үлем кабергә.
Мин йомар идем күземне,
Мин йомар идем, Джеми,
Гомер-гомергә!

* * *

Кырларның яңгыр, карларын
Сиңа тидермәм,
Дустым, тидермәм.
Җиләнем белән каплармын
Кышкы җиленнән,
Зәмһәриреннән.

Әгәр газаплар китерсә
Язмышың синең,
Язмышың синең,
Мин әзермен бүлешергә,
Җан дустым минем,
Җан дустым минем.

Калсам да киң далаларда
Караңгы төндә,
Караңгы төндә,
Кояш табармын анда да,
Без булсак бергә,
Без булсак бергә.
Ник бирмиләр миңа шунда
Бөтен Җир шарын,
Бөтен Җир шарын.
Мин тик синең белән генә
Бәхетле, ярым,
Бәхетле, ярым.

**ЙОКЫСЫЗЛАР КОЯШЫ**

*Джордж Байроннан*

Әй, моңсу йолдыз, син – төн кояшы!
Нурыңда күпме йокысыз яше!
Янсаң да, китми кара төн һаман,
Искә төшә тик узган шат заман.

Тормыш төнендә үткәннән безгә
Килсә дә якты, ул соң ни бирә? –
Нәкъ шушы йолдыз, җылытмый хәтта,
Ул салкын. Матур – ләкин еракта...

## ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ

*Джон Китстан*

*(Сонет)*

Якты йолдыз! Сиңа охшаш булсам иде.
Төннең данлы биек чарлагыннан карап,
Һәрчак ачык керфекләрем аша Җирне
Күзәтергә димим… тынгач бөтен тараф –

Күреп дулкыннарның ярга кагылганын,
Җирне юып, күзләп аяз киңлекне дә
Һәм яшь карның ак киеме ябылганын
Үзәннәргә яки биек тау битенә…

Юк! Синең күк һаман уяу – түзем белән,
Татлы йокы кундырмыйча күзләремә,
Торыр идем яр йокысын саклап гелән:

Башым куеп аның калку күкрәгенә,
Тыңлар идем: дулкын кайчан килә, китә…
Риза булып шулай яшәү һәм үлемнән!

## САУМЫ, САГЫШ!

*Поль Элюардан*

Йә, хуш, Сагыш...
Һәм исәнме, Сагыш!
Күрәм сине сызык-сызык түшәмемдә,
Язылгансың сөйгәнемнең күзләрендә.
Сагыш,
        Син түгел ич кайгы! –
Син иң моңсу Кешенең дә
Иреннәренә кагылып,
            бары елмайтасың аны.
Шуңа да син – иң-иң якын таныш.
Дәшәм сиңа:
– Хуш киләсең, Сагыш!
Бер-беренә омтылган җан һәм тән өчен
Син – зур сөю агышы.
Синдә зур наз күрәм,
Җисемсез бер заттай,
Башын артка чөйгән, көләч,
Якты йөзле сагышым!

**НӘСИМИ ГАЗӘЛЛӘРЕ**

* * *

Яндыра җанны кайгы, моң, юк шунда да янда дус,
Эш эзлибез ике кулга, әмма урын тапмабыз.

«Дус» диеп эндәшә күпләр, тик беләбез, шунсы хак:
Кыен сәгатьләрдә иңдә дуслар кулын тапмабыз.

Гашыйк булып, тапшырабыз йөрәкне ят кулына,
Ул мәңгегә кала... ә яр? Ярның үзен тапмабыз.

Бар шундыйлар: иң-иң хак дип, дингә вәгазьли сине,
Тик аларда хәтта тәре йөртер урын тапмабыз.

Сәләтсез, намуссыз кеше хәзер һәркайда түрә,
Дөньяның хезмәткә хөрмәт биргән җирен тапмабыз.

Күпләрнең өендә чапан да башында чалмасы,
Тик башы да булган зур, чын динлеләрне тапмабыз.

Һич гаҗәп түгел, киемеңне синең урлап китсәләр,
Чөнки уяу булган аздыр... меңгә берне тапмабыз.

Кайгы китәр, газап үтәр, барчасы – вакытлыча,
Әмма җанның сусавын бер басар җирне тапмабыз.

Мәкерле, икейөзлеләр изәләр гыйлем халкын,
Галимнәргә, хәкимнәргә лаек илне тапмабыз.

...Нәсими, кирәкми, ачма ятларга җаның, сереӊ,
Ышанырдай, риясыз чын тугры ирне тапмабыз!

* * *

Шундый гүзәл кем сурәте? Алиһәме югыйсә?
Шундый якты, нурлы энҗе... кабырчыктамы үсә?

Юк, Адәм кызы түгел син, күктән иңгәнсең, шаять,
Бу матурлык булса – төштә, өндә булмастыр һич тә.

Һичкемгә ачылмас сер бу, мәңге ул калыр шулай,
Бәлки, бу хыялдыр бары – югалыр эреп кичтә!

Ай күк йөзеңне ачма син, пәрәнҗәң пәрдәләсен,
Җир гашыйк булып үзеңә, бер-бер зилзилә килсә?!

Аерырга безне болай нигә язмышның ue?
Күзләрем мәңгегә синдә – сурәтеңдә югыйсә!

Шәм кебек эрим утта мин, йөрәкнең авыр хәле!
Очрата алмаса сине, ул нишләр? Ялкын үсә.

Гыйбадәт кылыйммы әллә, алдыма иңсен диеп,
Утыңда янсам янармын,– түгел лә гади мичтә.

...Тыңлагыз Нәсими сүзен, ул чынны, хакны сөйли,
Күкләр дә телсез, нишләсен хәлсез гашыйклар исә?!

**МӘРЬЯМ***

*Авар шагыйре Мәхмуттән*

Әй, шундый яндыра йөрәкне сагышлар!
Болытлар, сез дуслар, алыгыз «уф»ларым.
Сөйләгез, үтенәм, барын да аңарга,
Ялкында янам ла, янудан тукталмыйм.

Җанымны яндыра көчле ут, шаштыра,
Тау җиле! Сөйлә син дөньяга шул хакта.
Ал таңга җиткер син, упкынга үтеп кер, –
Белсеннәр бу хакта һәр җирдә, һәр якта.

...Сөйкемле җәйраным! Син сөйлә барсына,
Бу карлы тауларда калдырдың бит үзең.
Тур, алтын мөгезле үгезем! Син сөйлә –
Ник тирән чокырда калдырдың мине син?

Бик авыр язмышым: урманда ялгыз мин,
Кермимме шул килеш, әйт, синең төшеңә?
Сахрада мин яшим күрмичә һичкемне,
Уемда тик синсең – көнемдә, кичемдә.

...Янымда кәгазь бар. Тик кемнәр тапшырыр,
Мәхәббәт аңлатып әгәр мин хат язсам?
Тик болан таулардан бирегә еш килә,
Хәлеңне сорашам һәрвакыт аңардан.

Артыңнан йөрим мин – ялыкмыйм, арымыйм,
Әкият күк кердем мин халкымның теленә.
Ни булды, әй, сиңа? Чыгып бас баскычка,
Бер хат яз гашыйкка – ай чыксын төнемә.

Мин әле күземне бер кабат йоммадым,
– Сау бул! – дип, авылдан киткәнгә шактый ук.
Кая ул ял, йокы! Киткәндә әйтте лә:
– Ярыңнан башка, – дип, – йокыга хакың юк.

Тау иле... Адашса җәнлекләр синдә бер,
Сукмакмы табар ул эзләнеп, үлемме?
Тау кызы! Сөйгәнең язны соң күрерме,
Кочармы бер сине йә гүргә керерме?!

Кайда соң җилферди күлмәгең итәге,
Яулыгың ал кулга, йөзеңне ач миңа, –
Хыялда кил миңа, тавыш бир тавышыма,
Үлгәннәр терелсен синең бер «аһ»ыңа.

...Сугышны патшалар, корольләр чыгарган;
Дәшәләр яуга дип улларын җиремнең.
Мин исә табынам тик сиңа, сагынам,
Сиңа – бар уйларым, киләчәк гомерем.

Ал кояш нурлары төшәдер йортыңа.
Нинди күз белән соң үтәли карарга? –
Сөйлисең булыр син, җыр кебек сүзләрең,
Йөрәгем, колак сал ерактан аларга!

Салкын кыш урынына яз килер дөньяга –

Күз сирпеп, елмаеп, бер генә кара син.
Батса да бу Кояш, җиремә төн килмәс,
Таратыр карасын гаҗәеп карашың.

Ай кебек чыктың да син качып кинәттән,
Йөрәккә, ярага сиптеңме бер агу?
Ул – дару, әгәр син калсаң тик янымда,
Ләкин, юк, син киттең... мин янам, мин – авыру.
Син юксың, ә дөнья – бер кабер. Юксың син,
Син кайда – оҗмахым, тәхетем шул җирдә.
Башкасы кирәкми! Тик сакля-йортыңның идәне,
Ул – оҗмах һәркайчан, ул – бакчам гомергә.

...Күп җирләр айкадым яу белән йөргәндә
Һәм сине эзләдем, эзләдем рәсемеңне.
Тапмадым мин һаман, дөньяны урап та...
Югыйсә җанымны бирергә әзермен.

Фарсылар базарын урадым һәр көнне,
Карадым җентекләп яһүдләр товарын.
Ефәген, атласын... Карадым, тапмадым,
Күрмәдем һичнидә син – ярым образын.

Театр. Актриса – мең анда. Ә син – юк.
Синематографта да булдым мин беркөнне.
Анда да күп сурәт, тик син юк, кадерлем,
Эзләдем, тапмадым синең бер рәсемеңне.

Акылсыз бу хисләр, мәхәббәт – саташу,
Тик нигә көчле ул шулкадәр, белмим мин.
Син – биктә. Син – эчтә. Күрүче юк сине.
(Рәсемеңне ясасын, күрмәгәч, бездә кем?)

Тик бәйрәм көнендә чыгасың урамга,
Анда да торасың бер мизгел. Күз тия!
...Кайчанга кадәр соң йөрермен тапмыйча?
Тоела бар дөнья буш базар кук гүя...

Рус җирен уздым яуларда йөреп мин,
Бүген мин җирәннәр – Австрия илендә,
Һәм... таптым шушында мин сине – яшисең
Икән син һәркемнең өендә-түрендә.
Һәр өйдә сурәт бар. Синеке, тау кызым,
Карыймын... чынлап та! Бу шулай.
Көлүе, карашы – барысы да синеке,
Йә Ходай, бир түзем! Саташаммы болай?

Болында иң матур чәчәк кук... бу син бит? –
Кич җитте. Караңгы. Мин һаман каршыңда.
Көч бетте. Акылдан шашып мин шул вакыт
Тилмереп һәм елап сорадым барсыннан.

– Бу кемнең рәсеме эленгән диварга?
Әйттеләр: ул – Мәрьям анабыз. Изге кыз,
Гөнаһсыз булганга, Гайсәне тудырган...
Ишетеп шуларны, калдым мин һуш-иссез.

Маңгае, балкыган күзләре – синеке!
Урыннан кузгалмыйм, тик бу син, ялгышмыйм:
Кашлары – синеке! Елмаю-көлүе... Барсы да!
Сөйләшә башласын – яңгырар тавышың.

Ике җан охшаса охшарга мөмкиндер,
Тик ничек охшаш соң тәнегез, йөзегез?
Иреннәр, күзләр дә охшарга мөмкиннәр,
Игезәктәй ләкин сез ничек пар килдегез?

...Бәлки, бу – өметнең тагын бер алдавы;
Килмәстер тиз генә сине бер күрер көн.
Гомергә булмастыр – бәхетем йолдызы
Нурында балкытып, шатлыкка күмәр көн.

Бал корты болынның хуш исле чәчкәсен
Ерактан күрә бит – ул шунда талпына.
Мин уйда күзлимен сине гел, югалтмыйм,
Көндәшне дәшәмен хисләрнең явына.
...Христиан уллары табыналар сиңа,
Тәресен тидереп маңгай йә күкрәккә.
Почмакта шәм ягып, һәммәсе төртенә,
Армыйча, талмыйча хөрмәтен күрсәтә.

Һәм мин дә басканмын сурәтең каршына,
Иелмим алар күк, җиңелчә баш иям.
Җансыз да сурәтең, барыбер аңа мин
Мәхәббәт аңлатам, мәңгелек ант бирәм.

...Йөрсә дә рельстан, кагып күк төтенен,
Бер туктый вокзалга бәхетле паровоз.
Без исә – солдатлар – бер алга, бер артка
Туктаусыз атлыйбыз, туктаусыз барабыз.

«Шулай ул, сугыш бу, түземле бул», – диләр,
Түзәмен... Тик тагын күпкәме түзәргә?
Ярымнан килсәйде тик бер хат, бер хәбәр...
Җанымны кем аңлар, кемгә соң сөйләргә?

# ДАГСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ИҖАТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

## БИЕК ТАУЛАР

*Лезгинчадан*

Туган якның биек таулары,
Итәгендә – чишмә сулары,
И, матур таулар!
Ул тауларда – йөзем бакчасы,
Ә бакчада – минем җанашым!
И, бәхетле таулар!
Ерак таулар,
Биек таулар,
Матур таулар,
Бәхетле таулар.

Ташкын сулар бигрәк салкын ла
Күләгәдән аккан чагында.
И, матур таулар!

Әнием бирми мине ярыма,
Сөймәгәнгә ничек барырга?

И, бәхетле таулар!
Кешеләрдә кайгы аз түгел.
Иң зур кайгы йөртә бу күңел.
И, матур таулар!
Күпме кара бу ак дөньяда,
Мәхәббәт бар, бәхет юк анда.
И, бәхетле таулар!
Ерак таулар!
Биек таулар!
Матур таулар!
Бәхетле таулар!
* * *

*Лакчадан*

Мактанма, ир, син үзеңнең туның белән,
Ут шикелле ярсу чапкын атың белән.
Хатын гына ирне чын ир итә ала,
Мактаналсаң мактан яхшы хатын белән!

## АНА ҺӘМ КЫЗ

*Аварчадан*

– Әни, әни, уян әле,
Бер гаҗәп хәлгә кара:
Яшел үлән үскән әнә
Тирә-юньдәге карда.

Әни, түбәгә күтәрел,
Бер сәер хәлгә кара:
Тауларда бозларны каплап,
Чәчәкләр үсеп бара.

– Кызым, калын кар астыннан
Калкып чыгалмый үлән.
Син яз күрәсең, яз кебек
Бик яшь булганга күрә.

Кызым! Чәчәкләр үсми бит
Тауларда кыш аенда,
Син гашыйк, – шуңа чәчәкләр
Күрәсең хыялыңда.

* * *

Хатыннар, сез тудырмагыз куркак уллар!
Кайгы булыр андый улның булуы.
Һәм тапмагыз сез, хатыннар, батыр уллар,
Бик зур кайгы андый улның үлүе!

## БЕТТЕ МИНЕМ ҖЫРЫМ!

*Нугайчадан*

Бер яшемдә – ак тирмәдә тәпи йөрдем,
Ике яшьтә – сөйләштем мин, «әни» дидем.
Өч яшемдә – дуслар белән уйнап йөрдем,
Дүрттә – туктаттылар уенымнан минем.
Биш яшемдә – алтын белән чигү чиктем,
Алты яшьтә – матур дигән исем йөрттем.
Сигез яшьтә – ясанырга өйрәттеләр,
Ә тугызда – җанда кайгы көйрәттеләр.
Ун яшемдә – ярык аша күзләде бай,
Унбер яшьтә – яучы килде, Раббым, Ходай!
Уникедә – миңа калым килеп җитте...
Унөч яшьтә – алып китте – җырым бетте.

## КУРКАКЛАР

*Комыкчадан*

Тирә-якта тынлык –
Ә куркаклар шаулый...
Яу шау-шуы купса –
Куркак якын бармый...

Кайда туй мәҗлесе –
Куркак чыга алга...
Яуга дәшкән чакта,
Куркак чигә артка.

Ашап-эчкән чакта,
Кызыл йөзле куркак,
Уклар очкан чакта,
Куркак йөзе – ап-ак...

Мактана бит куркак:
– Мин, – ди ул, – чын батыр!
Яуда кача үзе,
Сайлый таулар артын.

## КӘЛӘШ ҖЫРЫ

*Татчадан*

Бу төндә һәркем йокысыз.
Туктамый-тынмый елый кыз:
Әй, дәдә! Әй!
Әтисенә текте бүрек,
Булмады тегеп бетереп.
Әй, дәдә! Әй!
Энесенә яулык чикте.
Чигелми калды бер чите.
Әй, дәдә! Әй!
Нәкышләре чуар иде...
Иртүк йортка яучы килде.
Әй, дәдә! Әй!
Инде эшне, әни, апа,
Төгәлләргә сезгә кала.
Әй, дәдә! Әй!

## СЕБЕРГӘ СӨРЕЛГӘН УЛЫНА АНА ҖЫРЫ

*Даргинчадан*

Син яшәгән якта, улым,
Төшәме томан түбән?
Әгәр син яшәгән якта
Түбәндә булса томан,
Бел, улым, шушы томан –
Әниең сагышыннан.

Син яшәгән якта, улым,
Күк күкриме җәй көне?
Әгәр күкләр күкри икән
Җир өстендә кай көнне,
Бел, улым, бу – әниеңнең
Кайгыдан салган өне!

Син яшәгән якта яңгыр
Явамы кайчакларда?
Әгәр дә яңгырлар яуса
Син яшәгәнякларда,
Бел, күктән төшкән тамчы –
Ике сеңлеңнең яше!

* * *

Син диңгез ярында –
Җиде төсле чәчәк.
Бер төсле булсаң син,
Сине кем сөячәк?!

* * *

Мин мавыккан кебек, беркөн
Мавыксаң әгәр син дә,
Елганы боз каплар иде
Җәйнең кызу көнендә.

Мин яраткан кебек сине,
Ярата алсаң син дә,
Бозда үлән үсәр иде
Бик салкын кышкы көндә.

* * *

Күкрәгемдә ут йөртәм мин,
Урманнарны яндырыр ул.
Белмим, кайчан үземне дә
Шулай көлгә калдырыр ул?!

Таулар-ташларны җимерер көч –
Давыл йөртәм күзләремдә.
Белмим, кайчан үземне дә
Очырыр ул җилләрендә?!

* * *

Кара урманда күк бүре,
Юлдашым булчы минем.
Кеше күзеннән качыйм мин
Сукмагың белән синең.

Күктәге кара карчыга,
Син дустым булсаң минем,
Эзләремне калдырмыйча
Авыллар үтәр идем.

* * *

Диңгез артыннан калыккан
Кояштай чыксаң өйдән,
Су өстендәге камыштай
Калтырар минем тәнем.

Тау артыннан чыккан айдай,
Тәрәзәдән карасаң,
Камышлыктагы кош кебек
Сискәнер минем җаным!

## ЭЧТӘЛЕК


Затлы шигърият иясе *Х.Миңнегулов* ..................

**I. Гөлләр су сорый**

Җилкән .....................................
Кеше – гашыйк ................................
Төнге романтика ...............................
Диңгезгә ....................................
«Яз!..» .....................................
Студент хаты .................................
«Таллы алан. Чыклы үлән...» .......................
Кайту *(Юл эскизлары)*............................
Шагыйрь язмышы ..............................
«Матурлыкны, үзенә тарту көчен...» ...................
«Урамыннан күпме үткәнем бар...» ...................
«–Яннарына барма, күрмә...» .......................
«Кайчак артык эзләгәнгә бугай...» ....................
«Үткәннәр белән араны өзәргә!..» ....................
Җиде төн ....................................
Печән өсте ...................................
Башак ......................................
Мин дөресен сөйлим .............................
Әткәйгә хат ...................................
Мәхәббәт турында баллада .........................
Төш һәм өн ..................................
«Кичәге көн үтеп киткән инде...» .....................
«Без – кешеләр...» ..............................
«Тиле йөрәк! Аңа ялкын...» ........................
«Хәл белергә килеп чыктың безгә...» ..................
«Мин бу юлга ялга тукталдым...» ....................
«Онытылган» исем ..............................
«Йомшаклыгың, назларың өчен яраттым мин сине!..» .........
Сәгыйть Рәмиевнең бунт-монологлары ..................
Туганнар каберлегендә ............................
Кызлар бии ...................................
«Киткәнеңне белеп, азмы җилләр...» ...................
«Дусларымның бер дусы мин...» .....................
Вәгъдә ......................................
Укытучы ....................................
«Миңа: «Мәңге шат син...» .........................
Кешеләр ....................................
«Биек камышлы тирән күл...» .......................
«Малай идем...» ................................

«Ничә тапкыр инде йөрәк мине...» ....................
Айны тапмадылар ..............................
«Янган йөрәк, сузылган кул...» ......................
«Аның белән көлеп сүз башладым...» ..................
Роль биргәннәр ................................
«Башта сине мин сөймәдем әле...» ....................
«Әгәр мәхәббәт эшендә...» .........................
«Еллар буе сөеп, күзләреңә...» .......................
Кайт кире! ..................................
Сораулар ...................................
Таулар турында уйлар ............................
Төш .......................................
«Тагын бер төш: мин үлгәнмен...» ....................
«Гөлләр көзен орлык чәчә җиргә...» ...................
Кое .......................................
Кыз җавабы .................................
Буран хикәясе ................................
«Бүгенге көн – кичәгенең дәвамы, ул...» .................
«Шулай тиеш идеме, очраклымы?» ....................
Көтә беләм ..................................
Исемнәр ....................................
Безнең Одиссея ................................
Яратам бугай... ...............................
Дуска хат ...................................
Су бирүче кызга ................................
Сабырлыклар бирсен .............................
Чакыру .....................................
Үпкә ......................................
«Бөеклек» турында ..............................
Без күрмибез ..................................
Шат күңелләләр җыры ...........................
Малайлар ...................................
Кырык яшьлек дуска ............................
Ирләр булыйк .................................

**II. Мәхәббәтнамә**

Егерме дүрт йолдыз һәм унҗиде диңгез .................

**III. «Уел»га юл**

« – Нарасый кояш!» .............................
«Сездә көннәр шулай матур булса, абый...» ..............
«Әтиемне юксынам...» ............................
Кыз сурәте ..................................
«Син йөрәккә минем кинәт кердең...» ..................
«Мин» дип, бәлки, күбрәк сөйлибез...» ..................
Гадиләр ....................................
« – Елавыңны күргәнем юк, дисең...» ..................
«Кадерлем, Кояш кызы син...» ......................
Рәхмәт, Тормыш! ...............................
«Сеңлем!..» .................................
«Мин...» ...................................
«Сочи матурлыгын син сөйләмә миңа!..» ................
«...Әй ул кичтә!..» ..............................
«Нинди матур син, әй, хыял!..» ......................
«Чәчләреңне синең юган...» ........................
«Син хаклы! Әйе, мин бала...» .......................
«Мин сагыну фәнен беләм...» .......................
«Авыру чагым – авыр чагым...» .....................
« – Гадисең дип уйламаган идем сине...» ................
«Очрашасы иде...» ..............................
«Буй-буй кофта... зәңгәр күлмәк...» ...................
«Кайларда йөрмәдем...» ..........................
Бу хиссият... ................................
«Гомер бакый булган – ышанганнар...» .................
«Сөйлә!..» ..................................
Кыз һәм чияләр ................................
Кыз хәтере ..................................
Лирик аллитерация ..............................
«Мин таныдым аны...» ...........................
«Мин бер малай, ә ул буй кыз иде...» ..................
«Гаҗәп соң син, тормыш!..» ........................
Тик бер адым... ...............................
Адәм улы ...................................
«Киноларда кайчак шундый кадр...» ..................

« – Иртә әле безгә...» ............................
«Яратырга телим...» .............................
Кич турында иртәнге уй ...........................
Шагыйрь Зыя Ярмәки каберендә .....................
Безнең гаеп ...................................
Кала .......................................
Арыш дулкынлана ..............................
«Нигә килгән монда? Нәрсә эзли?» ....................
Идел-йортка чакыру .............................
Сальери турында ...............................
Җанның кайчак... ..............................
Иске китапка зимагор бабайлар язган җыр ...............
Тәрҗемә, тәҗрибә ..............................
«Бер як читтән торып карый алсам...» ..................
Яшәүнең бер моңы ..............................
«Бишташ» уены ................................
«Ерак Марс авылы! Башлап...» ......................
«Әй, күңелнең көче!..» ............................
Усаллана кеше... ...............................
Ышандырыйк! .................................
Иске сүздән яңа мәгънә ...........................
Җырның – җире... ..............................
Йолдыз җиле ..................................
Кар астында – гөлләр ............................
«Су астында калган кыйтгам...» ......................
Карабодай ....................................
Татар китабы ..................................
«Күр, ап-актан агачларым күптән...» ...................
Яңа ел белән ..................................

**Салаваткa шигырьләр**

Зәңгәр ил – Балачак иле ..........................
Салават атлы малай .............................
Исемем Гөлдәр минем ............................

**IV. Бөекләр язган хатлардан**

Һенрих Һейнедан ...............................
«Һәр иртәдә мин тын йортың...» .................
«Диңгез ярында мин, кыя ташта...» ................
«Күпме гасыр инде мең-мең йолдыз...» .............
«Миңа иргә чыга калсаң әгәр...» .................
«Хатыгыз белән мине сез...» ....................
«Син мине, мин сине башта никтер...» ..............
Роберт Бернстан ................................
«Джон Андерсон, пеләш дустым...» ................
«Син мине ташладың, Джеми...» .................
«Кырларның яңгыр, карларын...» ................
Йокысызлар кояшы *(Джордж Байроннан)* ...............
Якты йолдыз *(Джон Китстан)* .......................
Саумы, сагыш! *(Поль Элюардан)* .....................
Нәсими газәлләре ...............................
«Яндыра җанны кайгы, моң...» ..................
«Шундый гүзәл кем сурәте?» ....................
Мәрьям *(Авар шагыйре Мәхмуттән)* ..................

**Дагстан халыклары иҗатыннан үрнәкләр**

Биек таулар ..................................
«Мактанма, ир, син үзеңнең туның белән...» ..............
Ана һәм кыз ..................................
«Хатыннар, сез тудырмагыз куркак уллар!..» .............
Бетте минем җырым! .............................
Куркаклар ...................................
Кәләш җыры ..................................
Себергә сөрелгән улына ана җыры ....................
«Син диңгез ярында...» ...........................
«Мин мавыккан кебек, беркөн...» .....................
«Күкрәгемдә ут йөртәм мин...» ......................
«Кара урманда күк бүре...» ........................
«Диңгез артыннан калыккан...» ......................

Литературно-художественное издание

**Гаташ** Радиф
**(Гатауллин** Радиф Кашфуллович)

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

**В трех томах**

**Том 1**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Гаташ** Рәдиф
**(Гатауллин** Рәдиф Кәшфулла улы)

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

**Өч томда**

**1 том**

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Л.З.Әүхәдиева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2009.
Форматы 70г108 1/32. Шартлы басма табагы 12,60.
Тиражы 2000 д. Заказ О-8.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.